1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
2021 ОКТЯБРЬ № 10

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ДЕМЕНЦИЯ
аннан
качып буламы

Зөлфирә һәм Алмаз
МИРЗАЯНОВЛАР
кем беренче, кем...

кабактан
уңдык
КЫШКА
ӘЗЕРЛИБЕЗ

Сәлимә ГАБИДУЛЛИНА: «Бөтен барлыгым белән татар мин!»

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!
Мин әни булдым, әни!

Шушы сүзне әйткән мизгелдә барысы да үзгәрә! Аралар тагын да якыная, җылына, күңелләр бер-берсен сүзсез дә аңлый... Бер үк кичерешләр аша узганнарның якынлыгы башка аның. Сүзләр, хәрәкәтләр, теләкләр бөтенләй үзгә төсмер ала. «Менә әни ни өчен ул вакытта шулай дигән, шулай эшләгән (яки эшләмәгән) икән», – дип уйлыйсың... Барысы да мәңгелекнең үзе кебек гап-гади, чөнки син – Әни! Ә Әниләр инде бер телдә сөйләшә...

Өр-яңа проект башлыйбыз. «Мин әни булдым, әни!» дип атала ул. Бер фоторәсемдә өч буын – әниегез, сез һәм кызыгыз (улыгыз): буыннар чылбыры шулай тезелә!

Җылылык, яктылык, нур бөркеп торган мондый фотосурәтләр сездә дә бардыр – кушылыгыз!

Гөлназ ГАРИПОВА



* * *

Әниемнең өч кызы без:
Айгөл, Алсу, Айсылу.
Бәхет – Әнигә – өч кызлы,
Безгә – Әниле булу.

Әниемнең өч кызы без:
Өчебезгә – өч язмыш.
Апа очты мәңгелеккә –
Төссез калды бу тормыш.

Үстек... Без дә әни булдык:
Кызлы йортлар – нур тулы.
Бергәләшеп үстерәбез
Айнә белән Арзуны.

Әниемнең күп кызы без –
Җанга-җан һәм кулга-кул...
Күз карашыннан аңлашу
Үзе олы бәхет ул!

■ Махсус язылган бу шигырьдә барысы да күренә – гаиләбезнең табышлары һәм югалтулары, галәмгә сыймаслык ана-бала мәхәббәте һәм араларыбызны бәйләп торган кадер хисе дә! Әниебезнең яратып пешергән чәе һәм җылы кочагы, сүзсез дә аңлашыла торган карашы... Шулкадәр кадерле! Кояш гомере телибез, әниебез, Сиңа!

Алсу ГАЛИМОВА

Фото: Анна Исмәгыйлева

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2021



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронннoе периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Сәлимә Габидуллина
Фото: Юлия Вохминцева

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Виталий Матвеев

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 4.10.2021 ел.
Чыгу көне: 14.10.2021 ел.
Заказ Е-3335
Тираж 10467

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: ПО279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+




Фото: Анна Арахамия

Ильмира ГЫЙМАЕВА

Саубуллашу вальсы

Артык серле бүген көзге көн,
Җылытадыр тәнне вә җанны.
Туктап калган гүя шушы мәл,
Илаһи моң кочкан җиһанны.

Артык серле бүген көзге көн,
Елмая сөйкемле баладай.
Иркәлисе килә дөньяны,
Бар табигать пешкән алмадай.

Артык серле бүген көзге көн,
Оялчан килендәй тын калган.
Муллык исе тулган һава да
Мәхәббәткә, назга уралган.

Артык серле бүген көзге көн,
Мөлаем хатындай бик тыйнак.
Җил дә юк, очмый бер яфрак, –
Көн пөхтә, самими һәм җыйнак.

Артык серле бүген көзге көн,
Йомшак куллы газиз әнидәй.
Көмеш җепле алтын бишектә
Тирбәләсе килә бәбидәй.

Әбекәем үргән бишектер, –
Әбиләр чуагы дөньяда.
Әбиемнең көмеш чәчләре –
Әйтерсең Кояшта уңганга.

Артык серле бүген көзге көн, –
Чәчәк аткан гөләп куагы.
Сары майдай җанны дәвалый
Көзге җәй – әбиләр чуагы.

Артык серле бүген көзге көн,
Әрсез пәрәвезләр бәйләнә.
Җәй белән көз бакча түрендә
Саубуллашу вальсы әйләнә.

Безнең тышлыкта



«Һәр килүемдә Кремльгә барырга җай тапмый калмыйм. Ак диварларына кулымны куеп торам. Сөембикә манарасы ташларына кагылам... Тарихи Ватаныннан читтә яшәүчеләр генә аңлар моны.»



12 Бер учакның җылысы
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без

6 Чуалу
Чулпан Галиәхмәтова



10 «Яшел гаилә»
Гөлнур Хәсәншина



16 Тау артында таулар бар
Эльмира Закирова



20 Икесе — бербөтен
Чулпан Галиәхмәтова

Э Ч Т Ә Л Е К

Татар дөньясы



22 Оясында ни күрсә
Ландыш Нәсыйхова

26 Сөен-бикә
Һади Атласи

Мәдәни тормыш



30 «Сөеклем» дип язарга ярыймы?
Эльмира Закирова



36 Гөл апа
Нәбирә Гыйматдинова

Яшәеш

42 Фидакарьлек
Роза Камалетдинова



44 «Бу – мәхәббәттер...»
Гөлнур Сафиуллина

48 Күңелебезгә ак нур сипкәнсез...
Алсу Шакирова



50 Урал тау уртасында
Лилия Фәттахова

Хуҗабикә

59 Гуаша массажы
Чулпан Юнысова



60 Кабак кексы

»

PRESSA



ЧУАЛУ

Бу авыру турында безнең җәмгыятьтә сөйләргә яратмыйлар. Әмма ул эпидемиягә әйләнеп бара. Сүз картлык деменциясе турында. Бәлки, бу терминны ишеткәнегез дә юктыр. Халыкта аны гади итеп кенә «алмашына башлады», «башы китте», диләр. Җәмгыятьтә карт әби-бабайларның хәтере югалуы нормаль күренеш кебек кабул ителә. Картлыктан тагын нәрсә көтәсең диючеләр дә табылыр. Әмма өлкәннәрнең зиһене чуала башлау гадәти күренеш түгел. Моның белән килешергә ярамый. Бу проблема белән очрашмас өчен, чаң сугып, бүген үк уйлана башларга, чарасын күрергә кирәк. Әлеге авырудан өлкән кеше үзе генә түгел, аның якыннары да җәфа чигә.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

«Әни мине танымый...»

Социаль челтәрләрдә хәзер көндәлекләр алып барырга яратабыз. Очрашу, гаилә кору, бала туу, аның мәктәпкә китүен тасвирлап язылган аккаунтлар бик күп. Мактанырга рәхәт шул. Әмма бик азлар үз башына төшкән проблеманы зур аудитория белән бүлешә. Оят чөнки! Җитмәсә, социаль челтәрләрне күңел ачу өчен генә кулланган халыкның күңелсез тарихлар укып утырасы килми. «Кеше кайгысы кайгы түгел, үз башыңа төшмәсә», дигән борынгылар. Хак! Минем тормышта ул проблема булмаячак дип ышанып яшибез шул без. Чөнки ул без, алар түгел! Якыннары деменция белән очрашкан кешеләр блок алып бара микән дип озак эзләдем социаль челтәрләрдән. Юк! Бу хакта язмыйлар да, сөйләмиләр дә, фотога да төшермиләр. Бердәнбер кеше таптым – Түмән өлкәсеннән Ирина авыру әнисен карый. Һәр көнне диярлек пост куя. Аңа йөзәрләгән кеше шәрехләмә яза. Димәк, бу проблема белән очрашучылар күп, әмма беренче булып сүз башларга кыенсыналар. Ирина әнисен ничек каравын, аның хәлен, авыру барышын бераз булса да әкренәйтү өчен нәрсәләр эшләве турында яза. Зарлану түгел бу – җан авазы.

@irina.shesh.tmn «Бер төн эчендә дөньямның асты өскә килде. Хәер, моңа әзер дә кебек идем, әнинең проблемасы буенча психиатрга да бардым. Әмма әнине болай кабул итәргә әзер булмаганмын икән. Төнлә күршесе шалтырата. Бу – тормышымдагы иң куркыныч шалтырату иде. Телефон экранында күрше исемен күргәч, йөрәгем томырылып тибә башлады. Әни төнлә муенса сатып алырга уйлаган һәм.... кибеткә бармаган, күршесенә кергән. Ярый төнлә кайткан күрше кызы ишеген бикләргә оныткан булган. Ә бит шул көнне көндез әни кибеттән сөт алып кайтуын, бераздан даруханәгә барып кайтачагын шалтыратып әйткән иде. Төнлә ирем белән әнине үзебезгә алып кайттык. Мин беренче мәлгә кирәк булган киемнәрне сумкага салам, әни кире шкафка алып куя. «Үз өемнән беркая да китмим», – дип елый ук башлады. Әмма аны ялгызын калдыру куркыныч иде. Без аны мәҗбүриләп машинага утырттык. Өч атна җәһәннәмдә яшәгән кебек яшәдек. Без бөтенләй дә әзер булмаганбыз икән. Нәрсә эшләргә белмибез. Тәүлек буе йокламыйбыз. Әнинең хәле тагын да начарланды. Бүлмәдән бүлмәгә йөрде, кайтам дип бәргәләнде, тәртипсезләнде... Ул мине – бердәнбер кызын танымады...»

@irina.shesh.tmn «Әни аерым яшәгән чакта һәр көн янына барып йөрдем. Ул вакытта ук анда сәерлекләр сиздем. Әмма акылы зәгыйфьләнер дип башыма да китермәдем. Деменция сүзен белми дә идем. Кайткан саен кызыма: «Минем белән берәр хәл булса, зинһар, әбиеңне калдырма», – дип әйтә идем. Хәзер аңлыйм, минем белән бернәрсә дә булырга тиеш түгел! Деменцияле авыруны карау бик зур йөк. Бу бик куркыныч авыру. Нәрсәләр генә эшләсәм дә, авыруны туктатып булмый. Мин әнигә нәкъ менә хәзер бик кирәк. Аның өчен яшим!..»

@irina.shesh.tmn «Әнигә бу очрашуның ничек тәэсир итәсен күз алдыма да китерә алмадым, әмма ниятләдем. Бертуганнары белән очраштырдым. Нәрсә генә булуга карамастан, туганнар аралашырга тиеш! Инде бөтенесе дә гомер көзендә булган бертуганнар бик күп сөйләште. Әни җанланып киткәндәй булды, хәтта нидер сөйләде. Китәм дип бәргәләнмәде, үзен бик тыныч тотты. Туганнарының янында булганын сизде бугай. Ә бүген герантология үзәгеннән дәресләрдән кайткач, машинадан төшәргә теләмәде. «Мине хәзер әти янына алып барачаклар. Мин төшмим», – ди. Кич тынычсыз үтәчәк икән. Көйләп машинадан төшердем дә, әкрен генә урамда йөрдек, эскәмиядә утырып тордык. Әни башка йортта яшәүләрен, минем белән беркая да бармаячагын кабатлады да кабатлады. «Әни, машина иртәгә килә, әтиең янына иртәгә барырсың», – дип көч хәл белән өйгә алып кердем. Әмма өйгә кергәч тә бәргәләнүдән туктамады, урамга чыгам, дип, гел ванна бүлмәсенә керергә талпынды... Әни мине бүген танымады...»

@irina.shesh.tmn «Ирина, бу мәшәкатьләрдә үземне югалтудан куркам», – дип язасыз. Әйе, бик авыр миңа. Әмма моның белән яшәргә һәм үзеңне югалтмаска кирәк. Минем никадәр ирек яратучы кеше булуымны күз алдына да китерә алмыйсыздыр. Шуңа хәтта балам да берәү генә, ул кечкенәдән мөстәкыйль булып үсте. Гомерем буе иректә булып яшәдем. Нәрсә теләсәм, шуны эшләдем. Башкалар кебек эшкә дә бәйле түгел идем. Теләсәм эшләдем, кызыгы бетсә, тоттым да башкасына күчтем. Теләгәндә дуслар белән очраштым, теләгәндә башка шәһәргә булса да сәяхәткә чыгып киттем. Гаиләм бармаса, берүзем дә китә идем. Өйдәгеләр мине ничек бар шулай кабул итәләр, үпкәләмәделәр. Ә хәзер мин бәдрәфкә дә тынычлап бара алмыйм... Акыл белән эш итеп яшәсәм дә, эчемдә нинди буран уйнаганын үзем генә беләм. Мин бәйле. Әнигә бәйле. Әмма ул – ӘНИ! Аның бик тә сәламәт һәм бәхетле булып яшәвен телим. Беренчесе миннән генә тормый, ә бәхетле итә алам. Хәтта елмаеп эндәшүем дә аны бәхетле итә кебек...»



В. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсенең психиатрия паллиатив бүлеге мөдире Елена ПЛАТОВА: «Карт инде мин, шуңа ялгызым, дип әйтү – тамырдан дөрес түгел».

@irina.shesh.tmn «Күрәсең, баш мие белән ашказаны арасындагы элемтә беренчеләрдән булып югала. Чөнки әнидә туклану хисе юк. Ул өстәл артында утырганда гел нәрсәдер ашый. Шуңа күрә алдына куелган порциясен ашап бетерүгә, кухнядан алып чыгып китәм. Юкса ашаганын онытып, тагын сораячак. «Син тукмы?» – дип сорыйм. «Юк. Ашатачакламы?» – ди ул, кухнядан чыгып киткәнче үк. Йә бүлмәсенә барган җирдән борылып чәй сорый. «Әни, син бит инде ике чынаяк чәй эчтең», – дим. «Юк, син миңа ярты стакан гына чәй салдың», – ди...»

@irina.shesh.tmn Әни өчен эшләгәннәрне иң элек үзем өчен эшлим бугай. Аңа инде тегә беләме, укый беләме, тапкырлау таблицасын беләме – барыбер. Ә минем өчен бу бик мөһим! Әнинең ниндидер функциясен йә һөнәрен югалтуын күрү миңа тагын да авыр. Күрәсең, аның авыруын тулысынча һаман кабул итеп бетерә алмыйм. Шуңа күрә көн саен сәгатьләр буе укыйбыз, тегәбез, язабыз. Опекунлыкны рәсмиләштерергә кирәк, диләр. Ничек итеп үз

Фото: www.pixabay.com



Деменцияне ачыклау буенча иң яхшы тест – кәгазьдә хәтердән түгәрәк сәгать рәсеме ясау.

кулларым белән әнине акылга зәгыйфь дип языйм. Мин моны булдыра алмыйм. Минем әни бит ул!..»

@irina.shesh.tmn «Кичә кич табиб язып биргән даруны беренче тапкыр әнигә эчерергә онытканмын. Моны төн уртасында гына аңладым. Кызым төнге икедә безнең янга кереп, әнинең бүлмәсендә ут януын әйтте. Янына кергәндә ул инде яртылаш киенеп беткән иде. Йокым туйды, хәзер аш пешерәм», – ди. Көйләп-җайлап әнине чишендереп яткырдым. Үзем дә аны кочаклап яттым. Ул һаман торырга тели. Берничә сәгать шулай ятканнан соң түзмәдем, ярты сәдәф дару бирдем. Иртән әнине уятуы бик авыр буласын, эшкә соңга каласымны уйлап, әнине кочаклап йоклап киткәнмен...»

@irina.shesh.tmn «Мин – әнинең берданбер кызы. Әнине карау бары минем өстә. Баштарак: «Их, туганнарым булган булса», – дип уйлый идем. Әмма кешеләр белән аралаша торгач, ярый әле берүзем генә дип сөенәм. Күп булсак, бер-беребезгә өметләнер идек. «Мин карадым, хәзер син кара», – дия башлар идек. Аннан китәр иде үпкәләшү, ызгышу... Ә авыру ата-аналар моны сизә. Аларның бит кыска хәтерләре генә юк, ә хисләр шулай ук калган. Балалар арасындагы үпкәләшүгә сәбәпче булганын сизеп, хәле начарланыр, көйсезләнә башлар иде. Авыру әти-әниеңне бер-береңә төрткәләгәнче, якыннарымның хәлен яхшыртыр өчен нишли алам дип уйларга кирәктер. Сезнең шулай дип уйлавыгыздан да аңа рәхәт булачак. Намусыгыз да чиста булыр. Ә үзләре үлгәнче үк авыру әтиәнинең өен бүлешеп тавыш чыгару бөтенләй мантыйкка сыймый торган хәл...»

@irina.shesh.tmn Җыеп куйган караватөстенә утырырга, ятарга әни бервакытта да рөхсәт итми иде. Гомумән, ятып торуны яратмады ул. Ашау да безнең аш бүлмәсендә генә булды. Ризык ташуны җене сөймәде. Өйдә тузан һәм чүп булырга тиеш түгел иде. Әни һәрвакыт пөхтә булды. Ә хәзер... Соңгы айларда ул урынын җыймый башлады. Әйтсәм дә җыймый. Әнинең функцияләре югалуны күрү бик авыр... Ә кичә йоклар вакыт җиткәч, салфеткаларны вак итеп ерткалап, чылатып идән юарга керешә. Имеш, идән тулы чүп. Ә минем өйдә бер тузан бөртеге дә юк. Кечкенәдән шулай өйрәтелгән... Кичә дә йокларга әни белән яттым...»

@irina.shesh.tmn «Кичләрдән курка башладым. Соңгы ике көндә әни үзен бик тынычсыз тота. Һава торышы тәэсир итә, диләр. Ярый әле нянька бар. Көндез мин эштә чакта ул карый. Ә күпләр бит тәүлек буе авыру янында үзләре генә. Акылдан шашарга мөмкин...»

@irina.shesh.tmn «Кичә кич буе әни өенә кайтырга җыенды. Аптырагач, киемнәрен яшереп куйдым. Аның кызы икәнемне бик сирәк кенә хәтеренә төшерә. Ул хәзер күбрәк – балачагында, туган өендә, абыйэнеләре янында...»

@irina.shesh.tmn «Әнидәге сәерлекләрне элек сизә идем. Табибларга йөрттем, төрле диагностика үттек. Әмма бер табиб та безне кирәкле белгеч – психиатрга җибәрмәде. Вакытында! Чөнки никадәр иртәрәк барсаң, шулкадәр яхшырак. Деменциянең башлангыч стадияләрендә кирәкле дарулар эчсәң, авыру әкренәя. Әмма, кызганыч, аны дәвалап булмый. Авыру агышын бераз туктатып тору да зур бәхет ул...»

Куркыныч статистика

Бу авыру буенча реаль статистика алып бару җиңелләрдән түгел. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы саннарына ышансак, Россиядә ике миллион кешенең акылында зәгыйфьлек бар. Шул рәвешле ил – Җир шарында алтынчы урында. Бу авыру елдан-ел арта. Моны гомер озынлыгы арту белән бәйләп тә аңлатырга мөмкин. «Альцрус» деменцияле кешеләргә һәм гаиләләренә ярдәм итү фонды мәгълүматларына караганда, җирдә әлеге авыру белән интегүчеләр саны 2050 елга 131 миллионга җитәчәк. Шулай ук сораштырулардан күренгәнчә, деменцияле кешеләрнең яртысының туганнары авыруның беренче билгеләре турында белмәгән. Деменция, нигездә, 65 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдә күренә башлый. Аны 60–70 процент очракта Альцгеймер китереп чыгара. Калган сәбәпләр: Пик авыруы, инсульт, баш миендә кан әйләнеше үзгәрү. Авыру күбрәк хатын-кызларда очрый. Белгечләр әйтүенчә, Россиядә өлкәннәрнең дүрттән өчендә күпмедер күләмдә деменция билгеләре бар. Иң куркынычы – күбесе авырый башлаганнарын аңламый. Бу саннарны Memini социаль проекты ачыклаган. Авыруларның күбесе табибларга

КЫЗЫКЛЫ МӘГЪЛҮМАТ

«Lancet» медицина журналы узган ел деменция авыруына кагылышлы тикшеренүләр үткәреп, нәтиҗәсен таратты. Белгечләр авыру китереп чыгаруга китергән 12 сәбәпне ачыклаган. Ул факторларны бетерсәң, авырып китү мөмкинлеге 40 процентка кими:

- югары кан басымы;
- тазару;
- шикәр авыруы;
- саңгыраулану;
- баш сөяге травмалары;
- депрессия;
- тәмәке тарту;
- спиртлы эчемлекләр эчү;
- физик активлык аз булу;
- кешеләр белән аз аралашу;
- гыйлемсезлек;
- әйләнә-тирә пычрану.

күренми. Үзе дә, туганнары да моны кирәк санамый. Чөнки безнең җәмгыятьтә карт кеше оныта инде ул, холкы да яманрак дигән караш яши. Аннан соң Россиядә герантология дигән медицина тармагы юк дәрәҗәсендә диярлек. Дөрес, «Демография» илкүләм проекты кысаларында «Өлкән буын» программасы гамәлгә ашырыла. Аның нигезендә 65 яшьтән өлкәнрәкләрне гериатр тикшерергә, кирәк икән – махсус тестлар үткәрергә тиеш. Әмма бу тикшеренү, нигездә, гәүдә авырлыгы, авырулар турында сораштырып, кәгазь тутыруга кайтып кала. Әлеге эшне гадәттә участок терапевтлары алып бара. Димәк, тест уздырып утырырга аның вакыты да җитми дигән сүз.

Картлыкка сылтау дөресме?

В. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсенең психиатрия паллиатив бүлеге мөдире Елена Платова әйтүенчә, деменциягә, ягъни кешенең танып-белү функцияләре, хәтере бозылуга нәселдәнлек һәм тышкы факторлар сәбәпче. Кызганыч, пациентлар табибка 3–5 елга соңарып мөрәҗәгать итә икән. Нигездә, карт ата-аналары ялгыз яши алмый башлагач кына якыннары хастаханә юлын таптарга тотына. Моннан кала, өлкән кеше үзе дә: «Мин уш-зиһенемдә, җүләргә чыгарырга ашыкмагыз әле», – дип киреләнергә мөмкин. Ә беренче кыңгырау инде күптән шалтыраган була. Кеше аны үзе үк сизә ала. Кичә булган хәлне исенә төшерә алмый интегә, яңа мәгълүматны авыр кабул итә башлый, ориентлашу авырлаша...

– Деменция нормаль картлык күренеше була алмый. Әле бүген генә бер пациентны кабул иттем. «Авыруның беренче билгеләре кайчан башланды?» дигән соравыма туганнары: «Берничә ай элек», – ди. «Ә аңа кадәр ничек иде», – дип сорыйм. «Бөтен картлардагы кебек, оныту гадәте бар иде инде», – диләр. Бик киң таралган ялгышлык. Бу гөнаһ медицина хезмәткәрләре арасында да бар. Бөтен картлар да онытмый, бары тик авырый башлаганнар гына оныта! Әгәр дә әби күзлеген кая куйганын онытып, даими эзләп йөри икән, аның урамда адашып өйгә кайта алмый йөргәнен көтәргә кирәк түгел. Деменция турында язган порталлардан тест үтеп карагыз. Шунда барысы да ачыкланачак. Әгәр дә башлангыч вакытында терапия үткәрергә өлгерәсез икән, зиһенле гомер озаккарак сузылачак. Әйе, деменцияне дәвалап булмый, әмма актив тормыш алып баруга нокта куелмаячак, – ди Елена Платова.

Безнең җәмгыятьтә ярлык тагу киң таралган. Психиатрга мөрәҗәгать иткән, димәк, җүләр. Авыру үзе дә, якыннары да соңга кадәр табибка бармый йөри. Шуңа күрә дә иң элек якыннар бу авыруны кабул итәргә әзер булырга тиеш. Бөтен кеше дә үз ишегә белән психиатр ишеген ачып керми, билгеле. Авыру билгеләре сизелгән өлкәннәр белән утырып сөйләшү зарур. Кычкырмыйча, аларга басым ясамыйча гына табибка барырга күндерергә кирәк, ди белгечләр.

Деменция белән авыручыларның күпчелеге өйләрендә дәвалана. Димәк, гаиләдә бер кеше тәүлек дәвамында аның янында булырга тиеш дигән сүз. Авыруны карап, янында утыручы хезмәте күпләр өчен кыйммәт. Гадәттә, алар сәгатенә 150–200 сум сорый. Дөрес, Татарстанда Сәламәтлек саклау министрлыгы белән бергә Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы озакка сузылган өйдә карау программасын гамәлгә ашыра, әмма ул бар авыруларны колачлый алмый. Узган ел гына Татарстанда ике меңгә якын өлкән кешегә деменция диагнозы куелган. Әле аларның хастаханәгә килеп җитмәгәннәре йә шәхси клиникага мөрәҗәгать иткәннәре күпме. Елена Платова әйтүенчә, бүгенге көндә ул эшләгән хастаханәдәге ике бүлектә дә урын юк. Шәхси дәвалау учреждениеләре дә авыруларга кытлык кичерми. Соңгысына, билгеле, бар кешеләрнең финанс мөмкинлеге дә җитми. Шуңа күрә дә якыннары авыру белән ялгызы гына кала.

МОНЫ БЕЛҮ ФАЙДАЛЫ

Деменциядән профилактиканы яшьтән үк башларга кирәк. Әмма шуны да онытмагыз: сакланырга беркайчан да соң түгел. Алда язылачак пунктларны даими үтәсәгез, картлык көнендә алмашыну мөмкинлеге бик аз.

- Уку, кроссвордлар чишү, яңа һөнәрләр өйрәнү.
- Йөзү йә һавада йөрү.
- Бакчада эшләү.
- Дөрес туклану – күбрәк диңгез продуктлары, алма, чикләвек, кара шоколад куллану, яшел чәйгә өстенлек бирү, майлы ит һәм камыр ризыкларын азрак ашау.
- Кан басымын, шикәр дәрәҗәсен контрольдә тоту.
- Гадәтләрне үзгәртү – мәсәлән, кибеткә яңа маршрут белән бару.
- Аралашу мохитен зурайту.
- Лаеклы ялга соңрак чыгу.
- Һәрвакыт тынычлык саклау.

«Кызганыч, бездә туу культурасы бар, ә үлем культурасы юк. Кешене туганда ничек кадерлиләр?! Бала табу йорты, әнисенә ярдәм итәләр, өйрәтәләр, белгечләр тикшерә. Үләргә яткан кешене карарга өйрәтмиләр менә. Ә бу бик мөһим! Ә бит без барыбыз да шуңа кайтабыз», – ди табиб. Деменцияле пациентлар өчен беренче хоспис Мәскәүдә әле ачылырга гына тора. Ә бу диагноз белән, нигездә, 10–15 ел яшиләр. Деменциянең соңгы стадиясенә җиткәннәрне, гадәттә, психоневрология интернатларына җибәрәләр. Бар кеше дә карт әнисен йә әтисен андый учреждениеләргә җибәрә алмый. Безнең халык, шөкер, башкачарак холыклы. Гөрләтеп яшәгән әниеңнең көннәрдән бер көнне алмаша башлаган авыру карчыкка әйләнүен кабул итү бик авырдыр, билгеле. Акыллы кеше кылмаган гамәлләр эшләгәндә, әрләргә ашыкмагыз. Үзебезнең дә картаясы бар. Ә картлыкта ни язганын бер Ходай үзе генә белә. Дисбе тартып утырган өлкәннәрнең: «Ходаем, якты дөньякай белән үз акылымда булганда хушлаштыр», – дип теләк теләвен яшь барган саен гына аңлыйсың икән...

PRESSA

«ЯШЕЛ ГАИЛӘ»

– Шимбә-якшәмбеләрдә дә: «Бу ял көннәре кайчан бетә инде?» – дип яшәгән кеше мин. Эшемне шулкадәр яраттым! Балалар бакчасында сабыйларга бик озак еллар татар теле укыттым. Аларны ничек сагынуымны белсәгез иде?! Дәрескә тезелешеп кереп утырулары, «Хәерле көн! Хәлләрегез ничек?» – дип сораулары күз алларыма килә...囧Эштән бер ел элек киттем. Балаларны яшь, үзләре янып, энтузиазмнары ташып торган ханымнар укытырга тиеш, дидем. Киттем дә, дөньям шунда ук бушап калды. Беренче мәлләрдә бигрәк күңелсез, ямансу булды. Вакыт күп – аны кая куярга, нишләргә белмәдем...

Роза ханым Акбәрова «Яшел фитнес»ка бер ел элек килеп кушылган. Проект бүген фитнесның нинди генә заманча юнәлешләрен берләштерми Әлмәттә: гимнастика, йога, цигун, воркаут, капоэйра, кроссфит, пилатес, йөгерү, велосипедларда шөгыльләнү, бию... Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен аерым тренировкалар оештырыла. Быел программада бу исемлеккә бик модалы бер юнәлеш – сапбордлардагы йога өстәлгән. (Сапборд – су өстендә шөгыльләнергә мөмкинлек бирә торган махсус такта. Әлмәтлеләр ул яктан бәхетле – үз пляжлары бар.)

– Мин башта аэробика төркеменә генә йөрдем. Спортны үзем өчен яңалык дия алмыйм. Гомер буена шөгыльләндем мин аның белән. Йөзәргә йөрдем – салкын суга да керә алам. Чаңгыда да еш шуам. Шәһәребездә зур шугалак төзеп куйгач, өлкәнәеп бетсәм дә, тимераякка да бастым... Үземне гел карарга, гәүдә авырлыгын бер тирәдә тотарга тырыштым. Яшь барган саен хатын-кызның организмы үзгәрә бит аның – артык килограммнар өстәлә. Килограммнар булмаса – граммнар. Ә барлы-юклы 100 граммны да өстәве генә ансат, ә алып ташлавы җиңел түгел...

Ә «Яшел фитнес» – бөтенләй башка ул. Беренчедән, профессиональ тренер белән шөгыльләнәбез: Рәмия Чирскова безгә нинди күнегүләр кирәген үзебездән яхшырак белә. Төркемгә кушылу өчен беребездән дә махсус әзерлек таләп ителми, яшь буенча да чикләүләр юк. Бездә күбрәк минем кебек – инде лаеклы ялга чыгучы ханымнар йөри. Ир-атларыбыз да бар. Төркемдә шөгыльләнү күпкә отышлырак: монда сиңа кешедән калышасы килмәү теләге дә кушыла...

Аэробикадан тыш, Роза ханым йогага да йөрергә карар итә. Үзе әйтмешли, шундый мөмкинлек бар икән, нигә йөрмәскә? Йога – Әлмәттә иң популяр юнәлешләрнең берсе. Аңа яшьләр дә тартыла. Тренерлары Нил Тахауовның да өлеше зурдыр – ул Әлмәттәге иң яхшы белгечләрнең берсе санала. Күнегүләр «Сәламәтлек» паркында иртәнге җиденче яртыда ук башлана – халык шул вакытка инде җыелып өлгерә. Алай гына түгел, иртәнге бишенче яртыда «Әлмәт» иҗтимагый-мәдәни үзәгенең җәйге террасасында – түбәсендә узган күнегүләргә дә йөргәннәр әле.

– Зумба белән дә шөгыльләндем. Паркның иң зур сәхнәсендә оештыралар аны. Рәт-рәт тезелеп басалар – шундый матур... Башта читтән генә карап тордым – миннән булмас шикелле иде. Аннан тәвәккәлләдем. Бөтенләй бии белмәсәң дә, зумбага кушыла аласың: фитнестагы традицион күнегүләр комплексына сальса, хип-хоп, реггетон кебек бию элементлары өстәлә анда. Бөтен нәрсә онытыла – ниндидер бәйрәмдә рәхәтләнеп күңел ачып кайткан хис кенә кала.

Ә быел Роза ханым үзе өчен яңа юнәлеш тапкан – пилатес. Аны тренер Анджелла Шәйхетдинова алып бара. Гәүдәнең сыгылмалылыгын саклау өчен иң кирәк күнегүләр шушында дип саный. Инде хәл итеп тә куйган: җәйге бушлай тренировкалар тәмамлануга түләүлегә күчәчәк.

– «Яшел фитнес» тормышымны бик нык үзгәртте, – ди ул. – Күреп торасыз, үземдә яңа мөмкинлекләр ачтым. Һәм барысы да бушка бит! Минем кебек өлкәннәр өчен аның бу ягы да бик мөһим... Парк, өй янындагы скверга үзең генә дә чыгып шөгыльләнергә була, әлбәттә. Әмма безнең барыбызга да ялкаулык хас. Янындагылар: «Ярар, бүген чыгып торма инде, көн бигрәк кызу (салкын, җилле)», – дип торса – бигрәк тә. Ә «Яшел фитнес» шул ялкаулыкны җиңәргә, үзалдыңа максат куеп яшәргә өйрәтә. Яшәү дәрте өсти! Сәламәтлек өчен файдасын әйтмим дә... Аннан проектка кушылу – аралашу дигән сүз дә бит әле. Бу яшькә җиткәч андый ихтыяҗ да бар икән... Һәм ул бик күпләребезгә кагыла икән... Гомернең күп өлеше инде узылган: алга атлыйсы юл артта калганыннан кыскарак. Шуның өчен дә аякларым йөреп торганда, башым эшләгәндә, үзем өчен күбрәк яңалык ачарга, актив тормыш белән яшәргә тырышам. Безгә шундый мөмкинлек һәм шартлар тудырган өчен шәһәр администрациясенә, ветераннар үзәгенә һәм иң мөһиме – «Татнефть» җитәкчеләренә бик рәхмәтлемен. Теләгең булып та, велосипедың, скандинавия таягың яки гантельләрең юк икән – һәммәсен арендага биреп торалар. Шуларына кадәр уйланган!

Әйе, барысы да уйланган. Хәтта проектта актив катнашучыларга бүләккә кадәр. Килеп шөгыльләнәсең икән – сиңа баллар языла. Алар җыелып бара. Әйтик, балларың 50 гә тула икән, ноутбук, электросамокат, телевизор кебек бүләкләр оту мөмкинлегең бар. Баллар күбрәк булган саен – шанслар арта. Тагын бу баллар кафеларда, күңел ачу үзәкләрендә ташламалар да алырга ярдәм итә әле.

Әлмәт, Казанны узып, «Яшел фитнес» күптән республика буйлап таралды, илнең алтмыштан артык башка төбәкләренә барып җитте – социаль-спорт хәрәкәтенә әйләнде инде. Оештыручыларның максаты – күнегүләрне даими итү һәм аларга 1 миллион кешене тарту.

Ә нигә «яшел гаилә»ме? Проект программаларында катнашып, күнегүләр тәмамланганнан соң да аралашуларын дәвам итүчеләрне «green family» дип атыйлар. Әлмәт «яшел гаилә»гә әйләнергә өлгергән дә инде.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

2015 елның апреле. Бер төркем студентлар Горький паркында ачык һавада тренировкага чыга. Музыка астында күнегүләр ясаган яшьләргә шул көнне үк иллеләп кеше кушыла... «Яшел фитнес» проектының идея авторы Мурат Димитров әйтүенчә, барысы да шулай башлана. Ә 2016 елда бу идеяне «Татнефть» компаниясе күтәреп ала: ачык һавада спорт белән шөгыльләнергә теләүче әлмәтлеләрне шәһәр паркларына чакыра. Катнашучылар саны инде йөзләр-меңнәр белән исәпләнә башлый. Шул елны ук «Татнефть»нең бу социаль проекты «Eventiada Awards» Халыкара коммуникацион проектлар конкурсында, «Сәламәт тормыш рәвешен халык арасында тарату буенча иң яхшы проект» номинациясендә җиңеп чыга.

Ә бүген... Бүген бу проект инде Россия Федерациясенең Президент грантлары фонды һәм Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы ярдәмендә гамәлгә ашырыла. Проектның генераль партнеры гына үзгәргәне юк: «Татнефть» компаниясе «Яшел фитнес» аша социаль мәсьәләләрне ничек хәл итү үрнәген күрсәтүен дәвам итә.



Фото: Анна Арахамия



БЕР УЧАКНЫҢ ҖЫЛЫСЫ



Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Үз-үземә: «Мин булмасам, кем эшләр соң моны?» – дим дә, кабат җиң сызганып эшкә тотынам... Сүзләремне дөрес аңлагыз. Һич тә мактану, масаю дип кабул итмәгез. Артист та, укытучы да, китапханәче дә түгелмен – матур сүзләр сөйли белмим. Күп төбәкләрдә татар иҗтимагый хәрәкәтләрен шул һөнәр ияләре җитәкли бит. Ә мин... Мин гап-гади җир кешесе... Эш кушалар икән, аны җиренә җиткереп үтәргә кирәк дип кенә беләм...

Татар теле, татар милләте югалмасын – бу иң зур теләгем.

– Мин Чиләбе өлкәсенең Кунашак районы Кунашак авылында туып-үстем. Без – татарлар аны Конашак дип йөртәбез. Әти-әнием дә шушында дөньяга килгән. Ә әби-бабаларым – Татарстаннан. Бу якларга сөргенгә сөрелгән булганнар. Тамырларыбыз Татарстанның кайсы төбәгенә, нинди авылга барып тоташа – берсен дә белмим... Әбиләр исән чакта кечкенә идек, ә әниләрдән сорашып калу турында уйламаганбыз...

Чиләбе өлкә татар Конгрессының Конашак район бүлеге рәисе Сәлимә Мәүләви кызы Габидуллина белән әңгәмәне шулай ерактан башлыйбыз. Башлангыч сыйныфлар укытучысы булган әнисе кызының да үз юлыннан китүен тели, әлбәттә. Ә ул... агроном һөнәрен сайлый. Район үзәгендә үскән кыз бала! «Җир тартты – шуңа бардым», – дип аңлата ул кыска гына итеп.

Курган авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап кайта да, район авыл хуҗалыгы идарәсенә орлыкчылык белгече булып урнаша. Һәм гомерлеккә шунда кала. Үсемлекләрне саклау буенча квалификациясен күтәрү өчен Ленинградка барып белем ала. «Үсемлекләр табибы мин», – дип балкып елмая ул. Күренеп тора – эшен ярата!

– Кан алучы лаборатория белән чагыштырырга буладыр безне. Бик кызык эш бу! Үсемлекләр тишелеп чыкканчы ук анализлар ала башлыйбыз. Орлык нәрсә белән чирле – шуны ачыклыйбыз. Аннан диагноз куйгач, дару язабыз... Игеннәр тишелгәч, кырдан кайтмыйбыз да диярлек. Шимбә дә юк, якшәмбе дә. Тамырлары исәнсаумы, бөҗәкләр зыян салмыймы – барысы да күз уңында булырга тиеш. Тиешле дәваны вакытында һәм дөрес билгеләргә кирәк... Кышын да эш җитәрлек – чәчү орлыкларының сыйфатын тикшерәбез.

Мин идарәгә эшкә килгән мәлләрдә безнең эштә кызлар юк диярлек иде – барысы да олы-олы абзыйлар гына. Әмма минем остазым хатын-кыз булды: Ләйсән Фәлах кызы Габбасова. Татарстанның Сарман районыннан иде ул. Утызынчы елларда репрессияләнеп килгәннәр. Җирне яратуны минем канга ул да сеңдергәндер... «Чәчкечкә үзең утыр, чәч орлыкны!» – дия иде ул. «Нигә мин утырырга тиеш?» – дип аптырый идем. Ә ул тагын кабатлый: «Утыр! Яхшы агроном булырга телисең икән, утырасың чәчкечкә. Комбайнга да! Син бар эшне дә башкара белергә тиешсең!» Мин аңа хәзергәчә рәхмәтле...

2008 елда ике райондагы – Конашак һәм Кислинскидагы орлыкчылык һәм үсемлекләрне саклау инспекцияләрен берләштереп, яңа оешма төзелә. «Россельхозцентр»ның Конашак районы бүлеге җитәкчесе итеп Сәлимә ханым билгеләнә. Унга якын эш урыны дигән сүз бу. Аларның сакланып калуы да Сәлимә Мәүләвиевнаның тынгысызлыгы белән бәйле: Чиләбе өлкәсендә беренчеләрдән булып «Планриз» дигән биологик препаратны алар чыгара башлый. Бөртеклеләрне төрле чирләрдән саклауда бу препаратка тиңләшерлек химик чара юк.

Кыскасы, эше шактый авыр һәм катлаулы аның – мәшәкатьләре болай да җитәрлек булган. Ә ул, үзе теләп, әнә нинди иҗтимагый эшкә тотынган. 2009 елда Чиләбе өлкә татар Конгрессының Конашак район бүлеген җитәкләргә тәкъдим итәләр аңа. Ул ризалаша. Бу эшнең бөтен җаваплылыгын тойган хәлдә ризалаша.

– Конашак – Чиләбе өлкәсендә татарлар күпләп яши торган районнарның берсе. Бездә бүген 14 меңнән артык милләттәшебез гомер итә. Алар башлыча дүрт авылда – Мөслимдә, Үзбәгәрәктә, Карабулкада, Конашакта яши. Бу зур авылларның һәрберсендә элек татар мәктәпләре булган. Хәтта бөтен фәннәргә кадәр татарча укытылган. Безнең әти-әниләргә бу бәхет эләккән әле – алар ул чакларны әле дә сагынып сөйлиләр. Ә без инде башка чорда үстек. Әти белән әнигә рәхмәт – ярый әле туган телне көнкүреш дәрәҗәсендә булса да өйрәткәннәр. Әби белән үстек – ул да безнең белән бары тик татарча гына аралашты. Яшьтәшләрнең күбесенә анысы да эләкмәгән бит... Ирем дә татар. Ул да Конашак егете. Аның да бабалары Татарстаннан. Ничек табыштыкмы? Элек танцылар була иде бит – шунда... Безнең гаиләдә катнаш никахлар юк: өч кыз туганым да, бер ир туганым да – барысы да үзебезнекеләр белән кавышты. Туйлар да татарча узды: җыр-биюләр дә татарча булды.
Бу мәсьәләдә әти шактый кырыс иде безнең: «Бары тик татарга гына чыгасыз!» – диде. Элек әтиләр шулай каты иде бит – без аның күз карашыннан да курка идек...

Әйе, татарча сөйләшәм. Әмма матур итеп, әдәби телдә сөйләшә алмыйм. Моның өчен борчылу күңелдә гел бар иде. Борчу гына да түгел әле ул: «Безне нинди мөмкинлектән мәхрүм иткәннәр бит», – дигән үпкә дә хәтта... Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Чиләбе өлкәсенә эшлекле сәфәр белән килгәндә, безнең белән – татар милли хәрәкәтендә катнашучылар белән дә очрашты. «Татарча чиста итеп сөйләшә алмыйм, шуңа кыенсынам», – дигәч, ул: «Ничек сөйләшә аласың – шулай сөйләш! Сөйләш кенә!» – дигән иде. Тырышам менә...

Иң мөһиме – үзе генә тырышып калмый, башкаларны да тырыштыра Сәлимә ханым. Чөнки оешманы җитәкләргә алынган беренче көнне үк үз алдына максат куя: ничек тә бозны кузгатырга кирәк!

Балалар бакчасыннан башлыйлар.

Район үзәгендә урнашкан «Березка» балалар бакчасында туган телне өйрәтү түгәрәге оештырып җибәрәләр. Әйтергә генә җиңел... Оештырганчы, башта аңа рөхсәт аласы бар бит әле. Сәлимә ханым бәхетенә (һәм аныкына гына да түгел!) Конашак районына яңа җитәкче килә: Сибагатулла Нурулла улы Әминов нинди генә үтенеч белән керсәләр дә, кире борып чыгармый. Ярый, монысы булды да ди. Ә бит татар теле укытучысы табу – үзе бер чишелмәслек проблема. Үзбәгәрәктән кала – ә анда татар теле атнага ике сәгать булса да укытыла әле – башка бер авылда да татар теле укытучылары инде юк. Татарстаннан республика җитәкчеләре бер килгәндә

Фото: Юлия Вохминцева

Дин саклана бездә: бик зур, бик матур мәчетебез бар.



Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кулыннан бүләк алу мизгелләре.

бу мәсьәләне дә хәл итүгә ирешәләр: укытучыларны Казан онлайн рәвештә әзерли башлый. Җиңел сулап куялар: берәр елга укырга җибәрергә кеше таба алырлар идеме икән әле – хатын-кызның кайсысы шулкадәр озакка өйдән китеп тора алсын?!

– Телне, беренче чиратта, гаиләдә өйрәтергә диләр… Килешмим. Бүгенге әти-әниләр ничек өйрәтсен аны – үзләре белми, яшьләр әби-бабайлар белән дә бергә тормый хәзер. Бәйрәм вакытларында балалар бакчасында ата-аналар белән очрашканда гел әйтәм: «Улларыгыз, кызларыгыз аша сез дә менә хәзер туган телегезне беләчәксез», – дим. Бу, чынлап та, шулай…

«Березка»га йөрүчеләр татарча шигырьләр сөйли башлыйлар, җырлыйлар, бииләр. Чиләбе өлкә Татар конгрессы җитәкчесе Лена Колесникова аларга милли костюмнар тектерергә ярдәм итә… Сәлимә ханымның күңеленә исә яңа борчу керә: ә мәктәпкә киткәч нишләр бу балалар? Андагы мохиттә кабат телне онытырлармы? Туган телне өйрәнү өзлексез система булырга тиеш бит ул – бер җырлап-биеп кенә һәм шуңа куанып кул чабып кына булмый әле.

Районның татар авылларындагы мәктәпләрдә татар теле түгәрәкләре эшли башлый. Конашакта бүген ул түгәрәккә 38 бала йөри. Мөслимдә – 32, Үзбәгәрәктә – 80. Уен аша туган телләрендә сөйләшергә өйрәнәләр. Дәреслекләр җитәрлек – Бөтендөнья татар конгрессы җибәреп тора. Яңа ел җиттеме, Сәлимә ханым, бүләкләр күтәреп (анысы өчен спонсорларга рәхмәт!), мәктәпләргә китә – Кыш бабай исеменнән бүләкләр тапшырырга: тырышлыкны күрә белергә дә кирәк! Бигрәк тә – балаларныкын.

Ә күңелдә канәгатьлек хисе һаман юк… Конашакта яңа мәктәп салып яталар – татар телен тирәнтен өйрәнүче бер сыйныф булсын иде анда дип хыяллана ул. Балалар бакчасының татар төркеменнән балалар туптуры шул сыйныфка – татар мохитенә барып керсен иде. Чиләбедә Тукайга һәйкәл ачкан көнне җитәкчеләргә тапшырырга дип, өч көн эчендә җиде йөзгә якын имза җыялар: халыкның бу үтенечен югарыдагыларга башкача ничек җиткерәсең? Әлегә уңай җавап кына алганнары юк… Андый чакта канатлар салынуы гаҗәп түгел. Сүзне башкага борам. Уңышларга!

Ел саен укучы балаларны Татарстанга – Актаныштагы лагерьга җибәрәләр: түгәрәкләрдә өйрәнгәнне ныгытырга, туган телдәге сүзләргә баеп кайтырга.

Өлкәдә узган «Нәни энҗеләр» бәйгесендә Конашакларның катнашмыйча калганнары юк. Нәниләр дә, аларның әти-әниләре дә бик теләп баралар ди. Ә аннан ул кызлар үсеп җитәләр дә, «Татар кызы» Халыкара бәйгесе сәхнәсенә күтәреләләр: конкурста катнашучылар арасында Конашак туташлары булмаган ел юк әле.

Конашак районының иң матур урынында – Чебакүл дип аталган тозлы күл буенда ел саен этномәдәни лагерь эшли. Сәлимә ханым ел саен анда татар төркеме җыя. Балалар бөтен өлкәдән килә! Әлбәттә, тел өйрәнергә! Укытучылары – бөтен Чиләбе татарларына билгеле атаклы татар теле укытучысы Сания Вахит кызы Шевченко! Вожатыйлары – «Сәләт» лагере әйдаманнары! Чиләбе татар конгрессы җитәкчесе Лена Колесниковага рәхмәт – әйдаманнарны Казаннан ук китертә. Смена ахырына татар төркеме тирәсенә бөтен лагерь җыела: аларда кызыграк!

Ай саен Чиләбедән кадәр алып кайтып, өлкәдә чыгучы «Хәзинә» газетасын таратталар. 1200 данә! (Артыграк алып кайтырга да мөмкин, тик ул: «Җитәрҗитмәс булсын», – дигән фикердә. Татар сүзе кадердә йөрсен!) Үзе әйтмешли, бер карасаң, әзер газетаны нигә таратмаска? Икенче карасаң… Чиләбенең үзеннән үк кайтартырга, Конашак буйлап таратырга, һәр оешмага, һәр татарга җиткерергә… Кемнәндер үтенергә, көйләргә, җайларга… «Син бит татар, милләт хакына эшләргә кирәк моны дип сорыйм», – дип елмая ул. Хәер, читләр түгел, күбрәк үзенекеләр булыша – ире, улы. Сәлимә ханым хаклы: өйдәгеләрең сине аңламаса, терәк булмаса, иҗтимагый хәрәкәттә катнаша алмыйсың.

Сабантуй. Татарның бу матур бәйрәме Конашакта гомер-гомергә узган. Сәлимә ханым балачактагы Сабантуйларын да хәтерли: «Элек тә Чебакүл янындагы мәйданда уза иде. Гаилә, бөтен туганнар белән чыгабыз. Әниләр самавыр куя, учак аса… Якын кешеләр белән очрашу, аралашу көне була иде». Конашакның бүгенге Сабантуемы? Ул да бик матур үтә икән. Балалар һәм зурлар өчен ике мәйдан оештырыла. Җыр-бию тынмый, милли уеннар гөрли. Аерым бер шатерда татар милли ризыкларыннан гына табын корыла: Сабантуй кунаклары безнең аш-сулардан авыз итсен, аның нинди бай икәнен күрсен! Ә кунаклар – мәйдан тулы: Конашак районында 48 милләт вәкиле яши. Татарлар аларның барысы белән дә дус, тату көн итә.

Конашакта үткән бөтен татар чараларын санап чыга алмам – күп алар. Һәрберсе бер максат белән оештыры-

ла: кем икәнлекләрен белсеннәр, тамырларын онытмасыннар, татар сүзе ишетсеннәр...

– Бер нәрсә куандыра – мин берүзем генә түгел. Фикердәшләрем байтак. Венера Нуретдинова бар менә. Ул безнең җирле шагыйрәбез. Чыгышы белән Татарстаннан. Ирен безгә юллама белән агроном итеп җибәргәннәр иде – төпләнеп калдылар. Университет тәмамлаган, гомер буе рус теле һәм әдәбиятын, татар телен укытты. Конашакта, Үзбәгәрәктә: ирен кая эшкә билгеләделәр – шунда... Наилә Гыйльфанова бар. Ул Конашак мәктәбендә татар теле түгәрәге алып бара. Үзбәгәрәкнең татар теле укытучысы Лариса Радиковна бар. Бик тырыш, җаваплы... Миңа булышучылар күп алар: ир-атлар, хатын-кызлар. Ир-атлары шул хатын-кызларның ирләре, уллары инде... Гадәттә, гаилә-гаилә киләләр безнең оешмага. Үзебез үткәргән чаралардан гел рухланып кайтам. Бигрәк тә балалар өчен уздырган кичәләрдән. Алар белән эшләргә бик яратам. Татарча исәнләшсәләр, берәр сүз әйтсәләр дә йөрәгемә сары май булып ята...

Аннан Сәлимә ханым спонсорларны саный: совхоз директоры Дамир Джалилов, эшмәкәрләр Артур Хәлилов, Зөфәр Насыйров, Идеал Шиһапов... Алар да таяныч!

Сүзебез кабат тел мәсьәләсенә күчә: нишләтәсең – авырткан җирдән кул китми шул.

– Бөтендөнья татар конгрессы оештырган чараларга килгәләргә туры килә. Казан безнең өчен изге җир инде ул... Һәр килүемдә Кремльгә барырга җай тапмый калмыйм. Ак диварларына кулымны куеп торам. Сөембикә манарасы ташларына кагылам... Тарихи Ватаныннан читтә яшәүчеләр генә аңлар моны. Бөтенроссия татар авыллары Сабан туе Чиләбе өлкәсендә узганда Рөстәм Миңнеханов безгә микроавтобус бүләк итте. Шуның



■ Оныгы Карина – Сәлимә ханымның иң зур горурлыгы. Оешма үткәргән чараларның һәрвакыт үзәгендә кайный ул.

белән халыкны Казанга экскурсиягә алып килгәләдек. Барысы да мин кичергән шушы хисләрне кичерде...

Тик сүзем башка нәрсә хакында иде. Форумҗыеннарда яңгыраган чыгышларның 70 процентын гына аңлаганмындыр беренче килүләрдә. Ә хәзер 90 процентын дип әйтә алам. Делегациябездә телне начаррак белүчеләр булса, аларга тәрҗемә итеп утырам әле. Ничек өйрәндемме? Бер сере юк. Хатын-кызның күп гомере аш бүлмәсендә уза бит аның. Телевизорым гел эшләп тора – һәрвакыт «Татарстан–Яңа гасыр» телеканалын гына карыйм. Башкаларга да шулай киңәш итәм хәзер – булыша. Бездә сәгать Казан вакытыннан аерыла: Чиләбе вакыты белән иртәнге сәгать 8 дә һәм көндезге 2 дә Татарстан гимны яңгырый. Йөрәгем әллә нишли шул чакта... Башкорт оешмалары чакыра: «Безгә күч, бергә эшлик!» – диләр. Юк, китә алмыйм! Татар бит мин, бөтен барлыгым белән татар! «Татарча диктант» акциясендә катнашабыз менә. Килүчеләр елдан-ел күбәя дип сөенәм. Укучы балалар ел саен һичьюгы ун сүзне генә истә калдырса да, сүз запаслары арта бара бит.

Сөйли-сөйли дә, үртәлеп, тагын бер үк сүзләрне кабатлый:

– Барысына да безнең буын гаепледер... Эштән башканы белмәдек – мөмкинлекләрне кулдан ычкындырдык шул... Бер ун яшькә яшьрәк буласы иде хәзер!

Улы Руслан белән кызы Эльвинаны гына күз алдында тотып әйтми ул – бөтен якташлары турында уйлый. Ә үзенекеләр, шөкер, туган телләрен белә, аңлый, сөйләшә. Әмма иң куанычлысы – туган телдә оныклар сөйләшә! Карина әнә татарча үткән барлык чараларда катнаша – җырлый. Казанда узган җыр-бию сәнгате буенча «Казан сөлгесе» Халыкара фестиваленнән беренче дәрәҗә лауреат исеме алып кайткан. Сәхнәдә чыгыш ясау өчен Каринага махсус милли бизәкле костюм тектергәннәр. Инде шундый ук күлмәкне аның сеңлесе Айлинә сорый.

Барысы бергә җыелганда чәкчәк пешерергә яраталар: кызлар камырны кисеп тора, Сәлимә нәнәйләре пешерә. Кыстыбый, бәлеш, кош теле... Милли хисләр милли ризыклар аша да сеңә дип саный ул. «Татар кызы токмач басып, токмач кисә белергә тиеш», – дип өйрәтә оныкларын.

Менә шулай яши Конашакның, үзе әйткәндәй, гапгади Сәлимәсе. Ул җитәкләгән район оешмасы Чиләбе өлкәсенең Златоуст, Миасс, Озерск, Магнитогорск шәһәрләре татар оешмалары белән беррәттән мактала. Чиләбе татар конгрессы Башкарма комитеты әгъзасы да әле ул: җитәкчеләре Лена ханым Колесникова тынгысыз җан – гел яңа идеяләр белән яна һәм аларны да үзе артыннан ияртә.

– «Нәрсәгә кирәк сиңа боларның барысы да?» – дип әйтүчеләр дус-танышлар арасында да очрый хәтта кайчак. Сүзне озынга сузмыйм. «Кемдер эшләргә тиеш бит», – дим...

...Бер кеше яккан учактан дөнья җылынмый, дисезме? Ә сез кабызып карагыз!





Татарстанның
халык язучысы
Марсель ГАЛИЕВнең
тормыш кагыйдәләре

ТАУ АРТЫНДА ТАУЛАР БАР

ТУГАН ТӨБӘГЕМДӘ ТАБИГАТЬНЕҢ ҮЗЕ ШИКЕЛЛЕ ГАДЕЛ КАРАШЛЫ КЕШЕЛӘР БЕЛӘН АРАЛАШЫП ҮСҮЕМНЕ БӘХЕТ ДИП САНЫЙМ. Юк, бәләкәйдән үк Парижларны күрергә, дөньялар гизәргә насыйп булмады. Әмма язмышыма үпкәләмим. Ярлы бала чагым күңелле узды. Аздан да канәгатьлек алу – миңа нәселдән бирелгән сыйфаттыр, мөгаен. Минем өчен Эйфель манарасы авылымның пожар каланчасы иде. Тегермән шарлавыгы – Ниагара, аръяк болын түмгәклегендә үскән аксыргаклар – бала чагым пальмалары, шул тугайлар өстеннән сыктап әйләнгән тәкәрлекләр адашып калган диңгез акчарлаклары иде. Туган ягымдагы инеш-күл, тау-үзән исемнәрен әйткән чакта, җан рәхәт сулкылдый. Алар туган як шәмаиленә язылган догалыкның аерым бер сүзләре кебек.

ТЕЛ КОЕЛАРЫМ САЕГЫП, СИРТМӘСЕ ШЫГЫРДЫЙ БАШЛАСА, ТУГАН ЯКНЫ ЮКСЫНУДАН ҖИРСҮ БИЛӘП АЛА. Сүзгә сусап кайтам. Бу – минем туган җирем генә түгел, Сүзнең дә туган төбәге. Тәүге сүз – әнкәм сүзе – зиһенемне иркәләп уяткан. Балачак иленең капкалары бикле. Сим-Симнан ачтырыр идең – пароле онытылган... Туган як киңлекләренә күз текәп, үзалдыма пышылдыйм: «Сагындым...» Мин, үзем дә сизмичә, тылсымлы парольне әйтәм шулай, күзгә күренмәс җарияләр капкаларны киереп ачалар.

Туган авылымның исеме – Балтач. Борынгы заманда Балтачы дигән атаклы кеше булган. **ҺӘЙКӘЛЛӘРНЕҢ ГОМЕРЕ КЫСКА БУЛУЫН ЧАМАЛАП, ШӘҺӘР-АВЫЛЛАРГА КЕШЕ ИСЕМНӘРЕН КУШЫП КАЛДЫРУ – ТӨРКИ БАБАЛАРЫБЫЗДАН КИЛӘ.** Менә ни өчен Көнчыгыш Европа, Украина, Идел-Урал төбәгендә, Себердә Балтач исеме белән аталган авыл-посёлоклар бихисап.

КӨТҮ КӨТКӘНДӘ ВАКЫТНЫҢ КЕРЕШ КЕБЕК СУЗЫЛГАНЫН БЕЛӘМ МИН. Күктә кояш гел бер урында үшәнләнеп тора, урман артына тәгәрәп төшәргә һич ашыкмый. Бездә бит сыерлар урман-аланнарда аерым көтелә, ә сарыкларның яраткан үләне тауларда. Сыерлар, кигәвенгә түзә алмыйча, койрыкларын байрак итеп болгыйлар. Сарыкларның мондый эсседә аңы парга әйләнә. Менә шушы ике төрле холыкның җаена төшеп берләштерү көтүче вазыйфасы инде.

Мәктәп – авылның күз карасы. Тәрәзәләрен балкытып, ул бөтен өйләрдән биек булып утыра. Олы урам, тыкрыкларын ияртеп, мәктәпкә алып килә. Капкасы да мәгънәле шыгырдап ачыла. **МӘКТӘПТӘ БАР ДА БЕЛМӘВЕҢНЕ БЕЛҮГӘ КОРЫЛГАН.** 6 яшьтә үк кызыгып мәктәпкә килдем дә зур коридорда югалып калдым. Укытучы Фатыйма апа тукталып: «Әллә укыйсың киләме?» – дип сорады. «Үлеп укыйсым килә!» – дим. Көлеп җибәрде. Минем «үлеп» дигән сүздән көлүе икән. Җитмәсә, әле яныннан үтеп барган укытучы абыйга да әйтеп көлдерде. Нәрсәсе кызык тоелгандыр. «Үлеп ашыйсым килә», «Үлеп йоклыйсым килә» дип сөйләшәбез бит инде.

Әдәбияттан «өчле» алдым мин мәктәптә. Укытучы шулай куйды инде 11 нче класста. Китап күп укый идем укуын. **ӘММА УКЫТУ СИСТЕМАСЫ ДӨРЕС ТҮГЕЛ ИДЕ БИТ.** Бер кызык мәгълүмат юк. Кайчан партиягә кергән язучы? Шуларны белми идем. Шуңа күрә «өчле» куеп чыгарды инде. Соңыннан уңайсызланып, үкенеп тә йөрде әле. «Сезнең бер гаеп тә юк, мин чынлап та дөрес җавап бирә алмадым», – дидем. Әдәби әсәр укып кына булмый бит инде. Уңай герой, тискәре геройлар анда... Мәктәпкә кергәнче үк укый белә идем югыйсә. 4 нче класста авыл китапханәсендәге бөтен татарча китапны укып чыктым.

Сугыш турында булмаса, авылда кино карап вакланмый да идек. Без караган фильмнардагы сугыш вакыйгаларында кырылган немецларның исәбе-хисабы юк иде. Фильм төшерүчеләр шулкадәр арттырып җибәрә!.. Хыялда кырганбыз икән фашистларны. Сугыш беткәч санап карасалар, әллә ничә ил белән сугышып та, алар сигез миллионга якын корбан биргәннәр. Ә безнекеләрнең әле дә очына чыга алганнары юк... Утызмы, илleme миллион... **МИНЕМ ТӨШКӘ 50 ЕЛГА ЯКЫН ГЕЛ СУГЫШ КҮРЕНЕШЛӘРЕ КЕРЕП ҖӘФАЛАДЫ.**

Танцыдан соң, төнге Азнакай урамын бер итеп кайтып киләбез. Тугызынчы «А», «Б», «В» классыннан чибәр өч кызны сайлап алганмын. Берсен генә култыкласам, калган икесе үпкәли, икесен култыкласам, берсе артып кала. Өчесе дә ошый бит әле боларның. Сөйләшергә җиңел, уенчак холыклы кызлар. Менә шулай...
ГАШЫЙКЛЫКНЫҢ БӘГЫРЬГӘ СЫЗЫП ТӨШМИ ТОРГАН, ӨСТӘН ГЕНӘ СИРПЕЛЕП АЛГАН ЮКА КАТЛАМЫ ДА БУЛА ИКӘН...

КЕШЕ МАЙМЫЛГА КАЙТЫП БАРА БИТ ӘКРЕН ГЕНӘ. Мәскәүдә, Кремльдә Ленин кабинетындагы өстәлдә торган бер скульптура шаккаттырган иде мине. 1921 елда Америка миллиардеры Хаммер Ленинга бронзадан коелган

Фото: Анна Арахамия

скульптура бүләк итә. Дарвин китаплары өстендә утырган маймыл кулына кешенең баш сөяген тоткан. Ирония белән карап утыра. Миңа калса, бик тирән мәгънә салынган аңа. Әллә ниләр уйларга була... Кешедән көлгән дә кебек ул маймыл, менә кая барып чыктың син, дип, кисәткән дә кебек... Менә шул маймыл хәленә килдек бугай инде, китаплар өстендә маймыл утырыр вакытка җиттек...

Беркөн телевизордан «Суперигра» тапшыруы бара. Ксения Собчак «Орёл и решка»ны алып баручы Анастасия Ивлеевага мәктәп программасы буенча сораулар яудыра. Петр I ничәнче гасырда идарә иткән? «Отцы и дети» романын кем язган?.. «Джугашвили фамилиясе нәрсә аңлата?» – дип тә сорады. Тегесе белми. Собчак Сталин фамилиясе икәнен әйтте инде соңыннан. Уйлап куйдым: бу бит белемгә керми. Информация генә бит бу. **БАШЛЫЛЫККА ДА КЕРМИ УЛ. БАШЛЫЛЫК БИТ УЛ БАШКА ӘЙБЕР – АНАЛИЗ ЯСЫЙ БЕЛҮ.**

Чатыр тауга менгән кеше юк иде әле элек. Мин 33 яшемдә мендем. Анда бернинди кеше эзе дә юк иде. Бу биеклекнең илаһи тәэсиреннән шаккатып калдым. Һәм аны ярату хисен үз күңелемдә генә күмеп калдырмыйча, башкаларга таратасым килде. Ел саен кайта, тауга менә башладык егетләр белән. Югарыдан бөтен тирә-як күренә. Башкортстан, Бакалы районнары уч төбендә сыман... **ТУГАН ҖИРНЕҢ НИНДИДЕР БЕР КЕНДЕГЕ БУЛЫРГА ТИЕШ ИНДЕ БҮТӘН РАЙОННАРДАН АЕРЫП КУЯ ТОРГАН...** Чатыр тауны гел күреп үстем. Капкадан чыгуга еракта ук зәңгәр булып күренә иде ул. Менмәгән килеш: «Зур җәнлек сыртыннан барган кебек... Ул ауныр да калкыныр шикелле», – дип язганмын. Һәм чынлап та шулай.

Бер кайтуда көне буе берүзем суырларны видеокамерага төшереп йөрдем. Гаҗәп кызык җан ияләре: кешегә ияләшкәч, гаиләләре белән чыгып яталар; курыкмаска кирәген бер-берсенә хәбәр итәләр; бу абый безгә тими, дип, сызгырып сөйләшәләр. Бу җәнлекнең нәсел шәҗәрәсе ерак гасырларга барып тоташа. Геродот безнең эрага кадәр 450 ел элек Һималай таулары арасында алтын эзләүче кырмыскалар барлыгын язып калдырган. Бу хәбәр легендага әверелеп, төрле кыйтгаларга таралган. Хәтта Александр Македонский да гаскәриләреннән эзләтеп караган... Узган гасырның 80 нче елларында француз галиме Мишель Пессель тибет телен өйрәнеп, Һималайга сәяхәт кыла, минаро дигән халык яшәгән авылларга барып чыга. Тау яссылыгында суыр ояларын күреп шакката. Болар чынлыкта алтын эзләми, ә җирне казып оя ясый. Ә җир тирәнлегеннән чыккан туфракны аралап, кешеләр алтын бөртекләре эзли икән. Минаролар бу җәнлекне нәкъ безнеңчә байбак дип атый. Русчасы – сурок, монголчасы – тарабаган. **ЧАТЫР ТАУНЫ ҮЗ ИТКӘН СУЫРБАЙБАКЛАРНЫҢ НӘСЕЛ ТАМЫРЫ ҺИМАЛАЙ КЫЯЛАРЫНА БАРЫП ТОТАША.**

Сөтле чәй кебек нурлы йөзле әбиләр, чуклы шәлъяулыкларын иңенә салып, төркем-төркем булып ашка баралар. Чирәмле капка төбендәге утыргычта – илләр гизеп кайткан ирләр. **ТҮБӘН ОЧ ПАРЛАМЕНТЫ БЕЗНЕҢ КАПКА ТӨБЕНДӘ УТЫРУДАН БАШЛАНА...** Кайда соң ул илленче елларның салам түбәле өйләре, авылның эчкерсез кунакчыллыгы, гадел ярлылыгы?! Ике-өч ел элек әйләнеп чыктым авылны – бөтенләй башка! Матур итеп кирпечтән салынган йортлар, шәп коймалар... Ләкин алар мине кызгатмый. Мин белгән авыл юк инде хәзер! 70 ел эчендә бетә икән авыл. Инде өченче буын китеп бара...

Автобуста алты илдә булып кайтканнан соң, дөресен әйткәндә, җирдән чиркана башладым. Анда җирнең һәр карышы кешенеке – эшкәртелгән, чиста, матур... Ә бездә – печән чабылмыйча кыргыйга әйләнгән болыннар, кура булып каралып утырган былтыр калган үләннәр... **БАЛАЧАКТАГЫ АВЫЛНЫ ГЫНА САГЫНАМ. ХӘЗЕР ЯГЫМСЫЗ УЛ АВЫЛ.** Анда кеше күрмисең хәзер. Капка төбендә утырулар кая киткәндер... Мин армиядән кайтан елны кунакка чакырып, чират тезелгән иде. Әле якын туган дип тә әйтеп булмый бит күбесен. Хәзер андый нәрсә юк авылда. Телевизор бетергәндер дим мин. Кеше кешегә мохтаҗ түгел. Элек бит кешеләр киңәшләшә иде. Хәзер телевизор каршында АКШ президенты белән утырган кебек була да ул, аралашырга теләге калмый. Без барын да беләбез дип уйлый. Сурәтле экран зиһен-ми эшчәнлеген ялкауландыра, күзаллау, хыял мөмкинлеген чикли...

Берәү сөйли. Шундый бер кисмәк була икән: шунда салып, 50 елдан, 100 елдан соң сине терелтәләр, имеш. 100 елдан соң терелеп кая барасың инде?! Анда инде типкәләп кенә ыргытачаклар, беркемгә кирәгең калмаячак. Бу нинди мәгънәсез уй микән дип уйлап куйдым. **ҮЗ ЧОРЫҢ БЕЛӘН ГЕНӘ ЯШИ АЛАСЫҢ СИН, ҮЗ ЧОРДАШЛАРЫҢ БЕЛӘН ГЕНӘ!** Гомәр абый Бәширов 90 ны узгач, күңелсез йөри иде. Аңларга була: яшьтәшләре китеп бетте бит...

Ирония белән генә: «Идея – татлы имезлек», – дип язган идем. Шуны тормышта кичерергә туры килде: идея алмашынуга эләктек без. Ышанып, коммунизм төзибез дип йөрдек тә бит... Ә шуны үзгәртү шулкадәр авыр бирелә кешегә... Мин, ярый, коммунизмга ышанмадым, үзгәрешләргә эчтән әзер идем. Ләкин барыбер бөтен яшәеш шуңа корылган булгач, күп якларын тиз генә кабул итеп тә булмады... **КЕШЕЛӘРНЕҢ ҮЗГӘРҮЕН КҮРҮ БИК АВЫР ТӘЭСИР ИТТЕ. АЛАР КҮЗ АЛДЫНДА ТӨС АЛМАШТЫРДЫЛАР.** Руслар чукынып йөри башлады. Безнекеләр намазлыкка басты. Бөтенесе ялган... Кичә коммунист, парторг булып йөргән кешеләрнең үзгәрүен күрү бик сәер икән ул.

ПРОЗАДА ИСНЕ, ТӘМНЕ БИРӘ БЕЛҮ, ПОРТРЕТЛАРНЫ ЯЗУ... МИН УЙЛАП ЧЫГАРГАН ӘЙБЕР ТҮГЕЛ, ӘДӘБИЯТ ФӘНЕНДӘ БАР УЛ. Кем күрә ала, кем юк инде – шул гына. Әйтик, Мәһдиевтә бар иде исне бирә белү. Безнең прозада исне бирә белмиләр бит. Максим Горькийда портретларны сурәтләү көчле. Әдәби портретлары

гаҗәп! Аның кебек язган кеше юк. Бездә портрет дигән әйбер хәзер генә күренә башлады. Моңарчы шул «Тукайның борыны тирли», – дигән бер җөмлә күрдем мин «Тукай турында замандашлары» дигән китапта. Тукай нинди булган, ничек сөйләшкән – бернәрсә юк. Кешене ярату юк микән бездә... Аптырадым. Шуннан тугандыр инде ул портретларны бирергә тырышу.

Хәзер илһам килгәнне көтеп утырып булмый инде. Бигрәк тә прозада. Шигырь күктән төшкән кебек ул. **КАЯ, ШИГЫРЬ ЯЗЫЙМ ӘЛЕ, ДИП, БЕРКАЙЧАН ЯЗГАН БУЛМАДЫ МИНЕМ.** Ә прозада утырырга кирәк. Үзеңне мәҗбүр итеп утырырга... Кара эш дип атыйм мин аны. Ә шигырь... килсә – килә, килмәсә – юк инде. Миңа минем бер елдан артык шигырь язган юк. Һәм язасы да килми. Шигырь заманы түгел хәзер. Проза заманы да түгелдер әле, бәлки. Әдәбиятның йогынтысы бетте бит.

РӨСТӘМ КУТУЙ – МИН СОКЛАНГАН КЕШЕ. ШАГЫЙРЬ БУЛАРАК ТҮГЕЛ, ПРОЗАДА БУ. КҮП НӘРСӘГӘ АҢАРДАН ӨЙРӘНДЕМ. Аның кебек сыгылмалы матур тел белән образлы итеп язган кеше юк иде. Зур әйберләр дә язмады кебек... Әмма һәрберсе ювелирларча эшләнгән иде. «Домик» дигән кечкенә генә бер әйберен хәтерлим. Укып шаккаткан идем. Малай уйный: идәнгә утырган да, шакмаклар тезеп йорт кора. Ә әти кеше чемодан өстендә утыра. Хатын каядыр тәрәзәгә караган. Аерылышу мизгеле. Соңгы җөмләсе ничек бит аның! «Отец поднял чемодан, и дом рухнул» – малайның шакмаклары җимерелеп төшә! Шундый тирән әйберләре күп иде аның.

ХӘЗЕР ЮМОР ЮК – ЧӨНКИ АРАЛАШУ ЮК. Аралашканда үзеннән-үзе килеп чыга ул. Күңелсезлек дөньяда. Әйткәннәр иде аны ул чир башланганда: «Мир будет другим», дип. Дөнья башка хәзер. Кешене үзгәртеп була икән дип, алдан ук уйлаганнар инде. Кешенең кадере бетте бит. Хәзер танышың очраса, килеп күрешмәсә ярар иде, чир йоктырыр, дигән бер уй килеп куя. Бернәрсәнең кадере калмады: әдәбиятның, культураның, сәнгатьнең...

ИҢ КЫЕН НӘРСӘ – ЯЛГЫЗ КАЛУ. Дуслар бик юк бит инде... Ялгыз калудан курку бар.

ИҢ РӘХӘТ ЯЛ – ТАУЛАРДА! Көннәр буе карап йөрсәң дә туймыйсың. Тау артында таулар бар дигәнгә мин юл йөреп, үз күзләрем белән күреп ышандым. Соңгы елларда Алтайга баруны гадәткә кертә башладым. Андагы тауларны карап бетерә торган түгел. Иксез-чиксез!.. Кырымда, Алуштадагы таулар да шаккатмалы! Ул ташлар! Ул табигать ясаган скульптуралар!.. Ләкин автобус белән барып, фотога төшереп булмый анда. Теләсә кайда туктар өчен, такси ялларга кирәк. Миңа бүген фейсбукка ике фотоны куйдым әле: Төркиядәге һәм Алтайдагы тауларны.

ХАТЫНЫМ – БАШЛЫ КЕШЕ, АНЫҢ БЕЛӘН КИҢӘШЕП БУЛА. Аналитика күчлерәк анда тарихка карата. Безнең өйдә – ике галимә, алар янәшәсендә авыррак, әлбәттә. Хатыным Динә – университет доценты, тарих фәннәре кандидаты, кызыбыз Зөлфия кардиология буенча медицина фәннәре кандидаты, доцент.

Җир йөзендә кешелек тарихында гамәлгә кергән бәйрәмнәрнең иң күркәме – Җыен, Сабантуй бәйрәме булыр. Татар халкы дөньяга китергән шушы нурлы бәйрәм Кояшның, Җирнең үзе кебек түгәрәк мәйданда үткәрелә. **ТҮГӘРӘКНЕҢ ТӨРЕ БУЛМЫЙ.** Мәйданның кайсы тарафында булсаң да, үзеңне үзәктә итеп тоясың. Халкыбыз монда бер йөрәк булып тибә.

ДӘҮЛӘТЛЕ ХАЛЫКЛАР ЗУР ШӘҺӘР МӘЙДАННАРЫНДА АТКА ҺӘЙКӘЛ КУЯ. Алар йә бронзадан, йә мәрмәрдән, йә чуеннан биек постаментка бастырыла. Бу дөньяда яшәвенә рәхмәтле милләт атка һәйкәл куеп, үз-үзен санлавын раслый шулай. Әмма без хәтта Казан ханлыгын нигезләгән Олы Мөхәммәт ханга да атлы һәйкәл куя алмадык.

Коръәннең аять-сүрәләре күктән нәкъ менә гарәп телендә иңдерелүе табигый сайланыштандыр. Бу бөек телдәге сүзләрнең бер-берсенә үрелеп, чигелешле яңгырашы, күпме мәчетләр, хан-солтан сарайларының дивар ташына уелып, такыялы бизәкләр рәвешендә сурәтле язылышы – искиткеч сәнгатьлелекнең кабатланмас үрнәге. **ИСЛАМ ДИНЕ БЕЗГӘ СҮЗ АША ТҮГЕЛ, ИҢ ӘҮВӘЛ МОҢ АША КЕРГӘНДЕР.**

АНА ТЕЛЕ – ШУЛ ТЕЛДӘ СӨЙЛӘШҮЧЕ КЕШЕНЕҢ ЙӨЗ-КЫЯФӘТЕНДӘГЕ МИМИКАНЫ, КҮЗ КАРАШЫН, ТАВЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН, ҖЫР-МОҢЫН БИЛГЕЛИ. Мин кая гына барсам да, үз милләттәшләремне елдам-кайнар күз карашыннан, тавыш тембрыннан танып алам. Ялгышам икән, димәк, ул кешенең нәсел агачының кайсыдыр тамыры татар канына барып тоташа... һәм ул аны үзе дә белми...

Дөньяда Йолдызнамә дигән фән барлыгын, туган көнеңә-аеңа карап, кайсы йолдызлык астында тууыңны белеп, шуннан холык-фигылеңне ачыклап була икәнне ишеткәнем дә юк иде. Мең еллар буена күзәтү, тәҗрибә туплап эшләнгән бу хикмәти фалда әйтелгәннәр тач туры килә икәнгә мин шактый еллар үткәч кенә инандым. Мин, Үлчәү йолдызлыгы астында туып, әллә нинди күркәм сыйфатларга ирешәчәк икәнмен. **ҮЛЧӘҮЛӘРНЕҢ ИҢ ТӨП СЫЙФАТЫ – КАТМАРЛЫ ТОРМЫШ ХӘЛЛӘРЕНДӘ ҮЛЧӘҮ ТӘЛИНКӘЛӘРЕН ГАДЕЛ ЯССЫЛЫКТА, ТИГЕЗ ТОТАРГА ТЫРЫШУ ИКӘН.** Миңа төрле низагларны җайлап, йомшартып, килештереп, гомер бизмәненең ике тәлинкәсен дә бер җиңеллектә яисә бер авырлыкта тоту насыйп ителгән.

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.

P. S. Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Масель ГАЛИЕВне 75 яшьлек юбилее белән котлыйбыз! Иҗат уңышлары телибез!

ИКЕСЕ – БЕРБӨТЕН

Алар – татар эстрадасының иң матур парларының берсе. Сәхнәдә бер-берсен тулыландырып, бербөтен булып иҗат итәләр. Берсе – моңлы тавышлы җырчы, икенчесе – нәфис сүз остасы. Концертлары – җылы атмосферасы, ихласлыгы, гадилеге белән аерылып тора, чөнки ул чын күңелдән, пафоссыз. Тормышта да шундый икән Алмаз Мирзаянов белән Зөлфирә Шәйдуллина. Бер-берсенә үрелеп яшәгән бу парны аерым күз алдына китерү бик кыен.

Сезнең иҗат тандемында кем баш?

Зөлфирә: Алмаз!

Алмаз: Тормышта – Зөлфирә. Иҗатта кем дә булса җитәкчелек итәргә тиеш инде. Әмма ике тәкә башы бер казанга сыймый, диләр бит. Шуңа, ир-ат буларак, ул авыр йөк миндә булырга тиештер. Концертларыбызның беренче сезонын үзем башлап йөрдем. Зөлфирәнең дә оештырып карау теләге бар. «Сиңа кирәк түгел ул», – дим. Ул – җырчы. Берни турында борчылмыйча, сәхнәгә чыгып җырларга тиеш.

Татар эстрадасында гаиләле җырчылар бик күп. Гадәттә, хатыннарының көчле тавышы, харизмасы янында ирләре төссезләнеп кала. Син курыкмыйсыңмы, Алмаз?

Алмаз: Юк, курыкмыйм. Безнең эстрада да шундый парлар бар икән, димәк, иренә шулай уңайлы. Ә мин үзем теләсәм генә, икенче планга күчә алам. Әгәр теләгем булмый икән, моны беркем эшли алмый. Мин – үз жанрымда, Зөлфирә үзенекендә көчле.

Алмаз, шоу-бизнеста шигырьләргә урын юк кебек. Ә сез концертларыгызны нәфис сүз белән үреп алып барасыз...

– Әнием шигырьләр яза. Нигезе шулдыр. Рәшит абый Сабировның килеп эндәшүе дә зур этәргеч булды. «Энем, шигырьләр яратасың икән, шигъриятне эстрадада популярлаштыр», – дип, үз фатихасын бирде. Бу – зур бурыч. Сезнең белән килешә алмыйм. Хәзер концертларда шигырь сөйләү модага кереп бара.



Зөлфирә: Моннан берничә ел элек нәфис сүзнең нәрсә икәнен дә белмиләр иде. Алмаз үрнәк булды дип саныйм. Алмаз шигырьне сәхнәгә алып менде. Әнгам Атнабаевны популярлаштырды. Быелгы сезонда ул шагыйрь иҗатына аерым бүлек багышларга исәпләп торабыз. Шунысы да кызык, Алмазча шигырь сөйләргә тырышучылар да күбәя башлады.

Үзеңне кабатлаганнарга ачуың килмиме?

– Юк, әлбәттә. Димәк, иҗатым буш түгел. Кеше миннән күреп, шигърияткә тартыла икән, ничек начар булсын инде ул. Гомумән, җыр бүлешеп талашкан җырчыларга шаккатам. Моны хайп өчен эшлиләр микән?! Җыр бит ул матурлыкка өнди, талашу чыганагы булырга тиеш түгел.

Алмаз, син сәхнәгә юлны тамадалыктан башладың дип әйтсәм, килешәсеңме?

– Килешә алмыйм. Әйе, җанын биреп эшләүче тамада мин, әмма инде сәхнәдә бик күптәннән. Күп җырчылар белән эшләдем. Сәхнә иҗаты башка ул. Клибыңны чыгарып, җырларыңны радиоларга ротациягә биреп, образыңны тудырасың. Тамадалык белән популярлык казанып булмый. Ә менә популярлык казану өчен акча эшләргә була. Тамада булып эшләгән акчаны иҗатка кертә ул артистлар. Сәхнә күп чыгым сорый.

Зөлфирә, син инде күптән сәхнәдә. Хәтта Россия Президенты гранты откан җырчы.

– Мин инде кечкенәдән җырлыйм. Әни белән әти мәҗбүриләп җырлата башлады дисәм дә була. Башта яратмадым, әмма бәйгеләрдә җиңә башлагач, шул өлкәдә дуслар тапкач, үз иттем. «Йолдызлык–Созвездие»дә берничә ел катнаштым. Шушы фестивальдә грантка ия булдым. Алар үзләре мине тәкъдим иткән. Башта – Татарстан, аннан соң Россия Президенты грантын алдым.

Сезнең яшь аермасы – ун ел. Гаилә тормышында кем күбрәк юл куя?

Зөлфирә: Мин күбрәк куямдыр. Алмазны терәк итеп кабул иттем. Ул елны әтине югалткан идем. Минем өчен Алмаз – теләсә нинди хәлдән чыгу юлы таба белүче. Уйларыбыз да, тормыш кыйммәтләребез дә бер безнең. Яши-яши барыбер дә ун яшь аермасы сизелә. Әмма ул бик сирәк була.

Алмаз: Ул бит яшь аермасыннан түгел. Анысы – ир белән хатын мөнәсәбәтләре ул. Без бит бергә концертлар куеп йөрдек. Зөлфирә белән очраша башлаганчы, яшь аермасы зур дигән курку бар иде. Әмма аның миңа таба беренче адымнары шикләремне коеп төшерде. Ул тәвәккәлләмәгән булса, батырчылык итмәгән дә булыр идем.

Бер-берегезнең иң шәп биш сыйфатын әйтегез әле...

Алмаз: (*Зөлфирә: «Башта син әйт», – дип әйтергә өлгерә.*) Эшчән, минем әнигә охшап хыялый, үпкәләве тиз бетә, кызык итеп сөйли белә, юмор хисе бик көчле.

Зөлфирә: Ярата һәм яраттыра белә, оста киңәшче, туган җанлы, сезнеке, безнеке дип аермый ул, дөньяны, кешеләрне ярата. Бик киң күңелле ул минем...

Алмаз, Зөлфирәгә җырчы буларак хөрмәтең бик зур икәне сизелә. Син аның талантына сокланасың, әйеме?

Алмаз: Әлбәттә! Аңа тавыш Аллаһы Тәгаләдән бирелгән. Җырлый белмәгән кеше җырлаганда авызыннан сүзтезмә чыга, ә Зөлфирәдән моң агыла. Аны тыңлыйсы гына килеп тора.

Хыялыгыз бармы?

Зөлфирә: Мирзаяновлар мәктәбен булдырасым килә. Мин – вокалдан, Алмаз сөйләм теленнән дәресләр бирер иде. Әмма мин җырлый беләм, мин сөйли беләм, дип кенә мәктәп ачып булмый. Бу эшкә тотыныр өчен белемле булырга кирәклеген, моның өчен вакыт һәм чыгым күп таләп ителүен дә аңлыйм. Әмма без икебез дә педагог белемле. Димәк, нигез бар. Нигә әле бу хыялны чынга ашырмаска?! Киләчәктә үзебезне сәхнә әһелләре итеп кенә түгел, үсеп килүче буынга белем бирүче укытучылар итеп тә күрәм.

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА.
Фото: Анна АРАХАМИЯ. Видео: Булат ГАЗИЗУЛЛИН.
Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.



ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ



Ландыш НӘСЫЙХОВА

…Очканында шул булыр. Халкыбызның буыннан-буынга күчеп килгән әлеге мәкале бүген дә үзенең актуальлеген югалтмый. Ә очар өчен һәр кешегә ныклы канатлар, кайтырын сагынып көтә торган нигез кирәк. Бала өчен ул башта ата-ана йорты булса, үсә төшеп насыйбын очраткач, үз өенә әверелә. Бүгенге геройларыбыз Земфира һәм Рамил Әхмәтшиннарның йорты да хәзер туганнарны гына түгел, балаларны, оныкларны бергә туплый торган җылы учак булып тора.





Ана сөте белән кергән

Ә бергә тергезгән гаилә учагын сүндермичә саклау вазыйфасы тормыш кануннары белән хатын-кызга бирелгән. Бу учакта һәркемгә җылы һәм уңайлы булсын өчен нәкъ менә аңа зур рухи һәм физик көч куярга туры килә. Тәүлектә егерме дүрт сәгатьтән күбрәк вакыт булса да, Земфира ханым үзенә дә, башкаларга да шөгыль табар иде, мөгаен. Активлыгына шаклар катарлык.

– Башка хатын-кызлар кебек үк, тормышымда шактый күптөрле рольләр башкарырга туры килә. Тәмле ашлар пешереп иремне эштән каршы алучы хатын да, газизләрем өчен җанымны фида кылырга әзер ана да, сеңлемә апа да, иртән яраткан эшемә ашыгып чыгып йөгерүче дә мин. Ләкин, иң беренче чиратта, бүгенгә кадәр бала булып кала алуым белән горурланам, – ди ул. – Аллага шөкер, икебезнең дә әти-әниләребез исәнсау. Шатлыкларыбызны уртаклашыр, авыр чакта киңәш сорап мөрәҗәгать итәр якын кешеләребез булуны зур бәхет дип саныйм.

– Эштән бушаган арада, әти-әнигә шалтыратып, телефонның икенче очында кадерле тавышларны ишеткәч тә Аллаһыма рәхмәт укыйм, исәнсаулар дип шөкрана итәм, – ди Рамил әфәнде дә.

Әти-әнисеннән күреп, балалар да көнаралаш дәү әни-дәү әтиләренә шалтыратып хәл белешә.

Тумышлары белән бер авылдан алар. Алексеевский районында урнашкан Зур Тигәнәленең Ташчишмә суын эчеп, Өчкүлендә коенып, саф һавасын сулап үскән Земфира белән Рамил бүген район үзәгендә яши. Авыл тормышының рәтен, җаен, рәхәтен, авырлыгын белүче, икесе дә күп балалы гаиләдә үскән әлеге пар эштән курыкмый. Тырышлык-үҗәтлекләренә, дөньяга карашларына исләр китәрлек. Бар ирешкәннәре хәләл тырышлыклары белән килгән. Ә иң зур уңышлары – әлбәттә, моннан 28 ел элек нигез салган гаиләләре.

– Безнең ишекнең бикле чагы булмады. Иптәшем Зөфәр белән иртән торып эшкә йөгерсәк тә, күңел тыныч иде. Чөнки балалар дәү әниләре белән кала. Димәк, өс-башлары бөтен, тамаклары тук булачагына шик юк. Моның өчен әнигә рәхмәтем зур, – дип сүзгә кушыла Земфира ханымның әнисе Нәкыя апа. – Балалар хезмәттә үсте, кечкенәдән көчләре җитә алырлык эш кушу – олы тормышка әзерләүнең нигезе ул. Кызларыбыз хезмәттән тарсынып тормады: йортта да эшләде, су да ташыды. Шөкер, бүген дә алынган эшләрен җиренә җиткермичә тукталмыйлар.

– Эшкә дә бит алар тегеләй ит, болай эшлә дип түгел, үз үрнәкләре аша өйрәтте. Әтием Дамир, мәсәлән, балта остасы да, әйбәт машина йөртүче дә. Утын кискәндә бүрәнәнең бер башын әти үзе тотса, икенче башына үзеннән-үзе минем куллар үрелде. Мине гел үзе белән йөртте. Кечкенәдән әтиемә сокландым, аңа охшарга тырыштым.

Ата-ул дуслыгы бүгенге көндә Әхмәтшиннарның дәвамчылары белән ике арада да нык. Ранил дә, Камил дә әтиләре белән киңәшмичә яңа эшкә тотынмый, аның киңәшен, хуплавын көтә. «Бергә эшләү бит ул нәрсәдер ясауга гына кайтып калмый, шул арада төрле темаларга сөйләшәбез, укуда йә эштә килеп чыккан хәлләрне анализлыйбыз», – ди ата кеше.

– Безнең әтиебез кебек сабыр ир-ат тагын бар микән Җир йөзендә?! Әти-әнисен хөрмәт иткәне, гаиләбез өчен җан атып торганы өчен яратабыз аны. Ул беркайчан да тавыш күтәрми, дөнья яңалыклары, эш мәшәкатьләре турында сөйләүне бүлдермичә генә тыңлый. Ә соңыннан үз фикерен әйтә, төпле киңәшләрен бирә. Андый очракларда бит иң мөһиме киңәш тә түгел, ә сине тыңлаучы, хәлеңә керүче булуы кадерле, – ди ире хакында Земфира ханым.

Бу җәһәттән өй эчендәге ремонттан калган артык төзелеш материалларына урын табылуны да горурланып сөйли ул. Әтисен шатландырырга теләгән Камил, шул такта-кадакларны тотып, ишегалдына чыгып киткән. Эштән кайткан әтисе исә кече улына сокланып карап торган-торган да булышырга булган. Ике көн дигәндә ишегалдында эскәмия, кое һәм тегермәннән торган матур композиция үткән-сүткәннәрне таң калдырып басып тора.



■ «Әтиемнең әнием Флерага карата керсез мәхәббәтен күрү чын хисләрнең еллар узгач та сүрелмәвен тагын бер кат раслый. Кайчак бит сүзләр дә артык, күзләр, ым белән дә күп нәрсәне аңлап, аңлатып була».



■ «Минем бәхеткә шундый ир тәрбияләгәннәре өчен әни белән әтигә бик рәхмәтлемен».



■ «Әти-әниләр безне ничек тәрбияләгән, ничек күрсәткән, көзге шикелле шуны ук кабатлыйбыз».

– Макаренко, Сухомлинскийлар кебек, андый кагыйдә бар, мондый бар, дип тормадык. Балаларны китапча тәрбияләмәдек, – ди дүрт бала әнисе Земфира ханым. – Без үскәндә чикләүләр булуын хәтерләмим, шулай да без «ярамый» сүзен белеп үстек. Әтигә хөрмәтне исә әни тәрбияләде. Нинди эшкә генә тотынсак та, әни: «Әтиегездән сорадыгызмы?», «Әтиегез ни әйтер?» дияр иде. Шул сүзләре белән үк әнием ир-атка хөрмәт тәрбияләгән инде. Әни аш-суга, сабырлыкка

Фото: Анна Арахамия



■ Земфира ханым татар әдипләре иҗатына багышлап теккән китапчыкларга һәм башка төрле эшләнмәләргә нәниләр генә түгел, олылар да соклана.



■ Ял көннәрендә йорт тирәсендә ярдәм итәргә дип, авылга ашыга алар.



■ Алма агачыннан ерак төшми. Шуңа күрә дә ата-ана үзе тәрбияле булырга тиеш.

өйрәтсә, эти машина белән дуслаштырды. Бөтен мәсьәләдә аның белән киңәшләшә идем. Хәзер инде үз балаларым да шундый: этиләрен күз карашыннан аңлыйлар. Олы улыбыз Ранил, инде үзе дә эти кеше булуга карамастан, хәзер дә Рамил янына ашыга.

– Балаларны тәрбияләгәндә, тегеләй эшлә, мондый бул дип өйрәтергә кирәкми, минемчә. Аллаһы Тәгалә биргән күзләре, колаклары бар. Берберебезгә, өлкәннәргә, тирә-юньдәгеләргә карата мөнәсәбәтләрне күреп, ишетеп үсәләр, күңелләренә салып баралар дип уйлыйм, – дип сүзгә кушыла гаилә башлыгы.

– Кияүгә чыккансың икән, иреңне, аның туганнарын ихтирам итеп, санлап торырга кирәк. Шул чакта үзең дә кадер-хөрмәттә яшәрсең. – Үзе дә 25 ел кайнана белән яшәгән Нәкыя апаның олы тормышка аяк атларга әзерләнүче кызына җиткергән нәсыйхәте бу. – Шөкер, кияү дә, кода-кодагыйлар да кызымнан канәгать.

– Әтиләре кайтмыйча, өстәл артына утырмыйбыз. Кунак килсә, чакырмыйча торып, балалар бүлмәләреннән дә чыкмый. Ә без өйдә булмаганда, килгән кешене чәй эчермичә җибәрмиләр инде, – ди Земфира ханым.

Хәрәкәттә – бәрәкәт

Әхмәтшиннар белән аралашкан чакта татар халык мәкальләрен шактый искә төшердек. Бусы аерым бер спорт төре белән шөгыльләнүне генә күз алдында тотмый. Гомумән, тормыштагы мобильлекне, хәрәкәтчән булуны хуплау аша күзаллана. Дөрес, спортны да ярата алар. Ранил кечкенәдән тхэквондо белән шөгыльләнгән. Земфира ханым белән Камил энә, ГТО нормативларын уңышлы тапшырып, алтын билгегә лаек булганнар. Тырышуның нәтиҗәсе дә бар: мәктәп тәмамлап укырга кергән чакта Камилгә өстәмә балл язылган. Камил мәктәптә укыган чакта шулай ук районның баскетбол буенча җыелма командасы белән республика күләмендә дә уңышлы чыгышлар ясаган. Буш вакытларында бергәләп өстәл теннисы уйныйлар. «Үзең дә тынгысыз, башкаларга да тыныч утырырга бирмисең дип көләләр миннән, – ди Земфира ханым. – Җай чыктымы, кышын – чаңгыда, җәен велосипедта йөрергә чыгабыз, бергәләп бассейнга йә Камага су коенырга йөрибез. Бу да бит гаиләне берләштерә торган бер алым».

Спортны гына түгел, иҗатны да үз итүче әлеге гаилә район, республика күләмендә үткәрелә торган төрле бәйге-чараларда да актив катнаша, үзләренең бердәм булуларын күрсәтә. Берничә ел элек «Нечкәбил» бәйгесендә – «Иң тату гаилә», «Күркәм гаилә»дә «Күп балалы гаилә» номинациясендә җиңү яулаулары да шуны раслый. Ә бит Рамил әфәнденең эше җаваплы, ул бүгенге көндә республиканы кирпеч белән тәэмин итү өлкәсендә җаваплы вазыйфа били. Шулай да хәләл җефетенең омтылышларын, үтенечен беркайчан да игътибарсыз калдырмый, һәр чарада катнашырга җай таба. Гармунын сузып сәхнәгә кергән Рамил әфәндене күргән тамашачы аның әле генә рульдә җилдереп килгәнен күп очракта сизми дә кала. Иң мөһиме – нәтиҗә!

Җиңүләр җиңел генә бирелми. Һәр чара тырышлык, осталык, күп очракта үҗәтлек тә таләп итә. Мондый сыйфатлар бүгенге геройларыбызда җитәрлек. Катнашкан һәр бәйгедә алар игътибарсыз һәм бүләксез калмый.

– Сәхнәдә басып торган шат күңелле әнибезгә карап, сеңелләрем Зилә белән Диләдә: «Үсеп җиткәч, безнең дә матур гаиләләребез булачак. Без дә «Нечкәбил»дә катнашачакбыз», – дигәннәре әле дә хәтердә. – Камилнең әлеге истәлекләре аерым бер горурлык белән яңгырый.

– Никадәр генә баналь яңгырамасын, әмма һәр гаилә – ул аерым бер дәүләт. Аның үз кануннары бар. Бу дәүләттә яшәү һәркем өчен дә уңайлы, җайлы булырга тиеш. Әлбәттә, һәр баланың үз юлы. Әмма гаиләдә алган үрнәк, тәртипләр, традицияләр аны гомере буе озатып барачак. Шуңа күрә аларны төрле яклап үстерергә тырышабыз да инде. Ә иң мөһиме – мөмкин кадәр күбрәк бергә булырга омтылабыз. Балалар кечерәк чакта кичләрен бергәләп китап укый, төрле башваткычлар чишә идек. Рамилем бик матур итеп җырлый, гармунда уйный. Кызлар кечерәк чакта аңа кушылып биергә яраттылар. Хәзер исә кулдан эш китте. Без кайтканчы өйдәге эшләрне балалар бетереп куя.

Земфира ханымның яңа уку елы башында игълан ителгән район башлыгының үсеп килүче буынны тәрбияләү һәм ата-аналар белән уңышлы эшләү өлкәсендә казанышлары өчен грантына лаек булуында да гаиләсенең өлеше бар.

– Эшемне бик яратам. Күңел байлыгымны, иҗади осталыгымны үстерүдә балалар бакчасында эшләвем дә ярдәм итәдер дип уйлыйм, – ди 6 яше тулыр-тулмас мәктәпкә керергә

ашыккан, соңрак Казан педагогика көллиятендә тәрбияче һөнәрен үзләштергән героем.

Бәхетле гаилә – зур хезмәт

– Әүвәлге байлык – балалар, ди өлкәннәр. Килешәм, һәр бала дөньяга үз ризыгы белән килә. Ышанычлы ныклы җилкәң булганда, парлап, бергәләп тәрбияләгәндә кыенлыгы сизелми дә. Бездән күреп, олылары кечеләренә күз-колак булды, бер-берсен үстерешергә булышты. Ишле гаиләнең рәхәтен һәр җирдә яңгыраган балалар тавышыннан тоям. Көнем алар белән башлана, алар белән уза. Эштә дә төркемдәге егерме биш сабый белән рәхәтләнеп уйныйм, – ди җай чыккан саен, районның «Кайгырту» балалар приютына барып, анда тәрбияләнүче үксезләрнең күңелен күрергә ашыккан Земфира ханым һәм балачагы хатирәләре белән уртаклаша. – Кечкенәдән рольгә кереп уйнарга яраттым. Ул заманда уенчыклар хәзергедәй күп түгел. Дәү әнинең сөлгеләрне төреп курчаклар ясап биргәнен әле дә хәтерлим. Шуларны бер-бер артлы тезеп утырта, ашата, укыта идем. Дәү әнинең: «Аллаһы Тәгалә сине балага күмәме, бөтенләй баласыз калдырамы инде», – дип борчылып сөйләнгәне истә калган. Биргәненә мең шөкер, дәвамчыларыбыз бар. Хәзер дә тәрбия уен аша бара. Кәрзингә ашау-эчү кирәк-яраклары салып, пикникка барып кайтабыз. Йә булмаса, туп, ракетка алып, спорт мәйданчыгын әйләнәбез. Бу тынгысыз заманда да бар нәрсәгә вакыт та, җай да табыла, теләк кенә кирәк.

Бүгенге көндә әти-әниләре янында төпчекләр – Зилә белән Дилә яши. Мәктәпне тәмамлаганнан соң хәрби бурычын үтәп кайткан Ранил инде башлы-күзле булган. Шул ук Алексеевский бистәсендә яшиләр. Тормыш иптәше Камилә белән уллары Сәмирне тәрбиялиләр. Тиздән дөнья ямьләндереп тагын бер бәби алып кайтырга җыеналар. Камил исә шәфкатьле һөнәр сайлаган. Бүгенге көндә ул – Чуаш дәүләт университетының медицина факультеты студенты, булачак хирург. Җай чыккан саен әти-әнисе, туганнары янына ашыга.

– Дилә белән Зилә – әтиләренең иркә кызлары. Дүрт яшьләреннән биергә илттем. Бер көн дә бармыйбыз дигәннәре юк. Быел тугызынчыда укыйлар, имтиханнарга әзерләнергә кирәк. «Әни, өлгерәбез», – диләр. Шуңа каршы килмибез инде. Гитарада уйнарга өйрәнәләр, җырлыйлар, инглиз телен чарлыйлар. Җай булганда һөнәр өйрәнергә тырышуны хуплыйбыз гына, тормышта бар нәрсәнең кирәге чыгарга мөмкин бит.

Традиция дигәннән, гаиләдә барлык дини бәйрәмнәр дә үткәрелеп килә. Корбан чалалар, Мәүлет ашы, гаетләр уздыралар. Әтиләре белән малайлар мәчеткә чыгып киткәч тә, кызлар торып коймак пешерә, өстәл әзерли. Инде берничә ел дәвамында бистәдә оештырыла тораган мөселман лагерена йөргән малай һәм кызлар әби-бабайдан килгән гореф-гадәтләрне хөрмәт итәргә кирәклеген дә әти-әни үрнәгендә күрә.

Өйдә хөрмәт итә, күз карасыдай кадерлеп саклый торган тагын бер тарихи истәлек – 1880 елда чыккан дога китабы. Рамил әфәнде тарафыннан карт әбисенә бүләк ителгән әлеге үзенчәлекле мирас Коръәннәр белән бергә өй түрендә кадерләп саклана. Еллар битләрен бераз таушатса да, ут та яндыра алмаган әлеге китапны буыннан-буынга тапшыруны үз бурычлары дип саный Әхмәтшиннар.

Алдагы җөмләдә Коръәннәр дип күплек санда әйтүем хата түгел. Бу гаиләдә һәр кешенең үз Коръәне бар. Тәүге бала – Ранил тугач: «Баш очына куегыз, күз тиюдән саклар», – дип, Нәкыя апаның Коръән алып килүеннән башланган әлеге күркәм гадәт бүген дә дәвам итә. Һәр туган балага яшел тышлы изге китап бүләк ителә. «Һәрберсе Коръәннең урынын белә, кадерләп саклый. Яшьтән дога ишетеп үскән балаларыбыз начар юлга кереп китмәс, йөзебезгә кызыллык китермәс, иншаллаһ», – ди Земфира ханым һәм сүзен дәвам итә. – Күпләр миннән «Бәхетлеме син?» – дип сорый. Бу сорауга әбиемнән калган нәсыйхәт белән җавап бирергә яратам. Өч бертуган чокырда утыручы Бәхетне күргәннәр. Иң өлкән туган Бәхеттән акча сораган. Бәхет аны акчага коендырган. Тегесе, үзен бик тә

> // **Земфира Әхмәтшина:**
>
> **Районда күпчелек рус телендә аралаша. Шуңа күрә мин русча «белмим», өлкәннәребез дә «аңламый». Өйдә туган телдә генә сөйләшәбез. Телгә мәхәббәт тәрбияләүдә «Сәләт» хәрәкәтенең дә роле зур дип саныйм. Кызлар аңа икенче сыйныфтан үк кушылды.**

бәхетле санап, юлын дәвам иткән. Уртанчы туган Бәхеттән бик тә чибәр хатын сораган. Янында пәйда булган чибәркәйне күргәннән соң, сөенеченнән кая басканын да белмичә, хәләлен җитәкләп китеп барган. Кече энеләре чокыр янына килеп тезләнгәч, Бәхет аннан: «Ә сиңа ни кирәк, егет?» – дип сораган. Егет: «Ә синең үзеңә ни кирәк соң?» – дип, сорауга каршы сорау биргән. «Мине моннан тартып чыгарсаң иде», – дип үтенгән Бәхет. Егет аны чокырдан тартып алган да үз юлы белән китеп барган. Бәхет исә гел аның артыннан йөргән. Бәхет ул беркайчан да күктән төшми. Ул – кешенең үз кулында һәм акылында. Һәркем үз бәхетенә үзе сәбәпче. Үзең тапкан бәхет кадерле, диләр. Минемчә, табигать хатын-кызга ана булу, кешелекне дәвам иттерү вазыйфасын биргән. Такташ сүзләре белән әйтсәк, нәрсә җитә ана булуга?! Ә яхшы әни булу өчен, янда ныклы җилкә – әти кирәк. Без бергә, бердәм булганда гына бала-оныкларыбыз бәхетле булачак.

Төрле сынаулар, югалтулар аша узарга туры килсә дә, дөнья мәшәкатьләренә бирешмичә, иңне-иңгә куеп, тормыш сукмагыннан бергә атлаучылар гына бәхеткә лаек. Әхмәтшиннарның да бәхете дәвамлы булсын, туган ояларыннан канат ныгытып очып киткән кошчыклар үзләрен көтеп торучы әти-әниләрен онытмасын, уңышлары белән шатландырып торсыннар.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Видео: Анна Арахамия.

Һади
АТЛАСИ

Сөембикә-ханбикә... Халкыбызның җан авыртуы, әрнүе, үкенече... Ачы язмышы... Өзелгән хыяллары... Газиз халкы өчен җанын да бирергә әзер торган бу шәхеснең тууына быел 500 ел була. Ә аның исеме әле дә телдә – ул буыннардан-буыннарга тапшырылып килә. Без хәтта аның җанындагы газапларга кадәр тоябыз: яраткан ирен югалту ачысын, дәүләтеннән аерылу фаҗигасен, улы өчен өзгәләнүләрен... Әйе, хәтер – үлемсез... Сөембикә рухының безнең арада бүген дә яшәвенең зур мәгънәсе бар: аның исемен киләчәккә булган өмет-ышанычларыбыз да яшәтә.

СӨЕН-БИКӘ

(әсәрдән өзек)

Казанлыларга руслар янына барып ярлыкау сораудан башка чара калмаганга күрә, алар, Зөядә торучы Шәехгали һәм дә рус башлыкларына илчеләр җибәреп, үзләрен олугъ князьнең багышлавын, гөнаһларын гафу итеп, аларны тоткын иттермәвен, Казанга хан буларак Шәехгалине җибәрүен, Сөен-бикә илә Үтәмешгәрәйне Мәскәүгә алдыруын үтенделәр...

Юлбарыс мирза Мәскәүгә барып, бөтен Казан йорты исеменнән Иванга ялынычлы ярлык тапшырды. Ул ярлыкта: «Бөтен Русьнең олугъ падишаһысы, олугъ князе булган Иван Васильевичка, башларында Ходайкол углан һәм Мурали бәк булдыгы хәлдә, бөтен Казан йорты, муллалары, сәетләре, шәехләре, шәехзадәләре, муллазадәләре, имамнары, хаҗилары, хафизлары, бәкләре, угланнары, мирзалары, эчкеләре, йорттагы һәм йортның тышындагы казаклары, шулай ук чуаш, чирмеш, мукшы, тархан, мишәрләре вә бөтен Казан җире син олугъ падишаһның аларны багышлап, аларга булган ачуыңны бетерүең, Казанга хан итеп Шәехгалине җибәрүең, Үтәмешгәрәй ханны исә анасы илә бергә алуың турында сиңа багыналар; рус тоткыннарын коткарып, кырымлыларның Казанда калганнарын, шулай ук аларның хатын һәм балаларын олугъ князьгә бирергә булалар; шулай итеп падишаһ аларны багышласа иде, шул хакта алар табыналар», дип язылган иде.

Иван, казанлыларның ялынычлы ярлыкларын ишеткәч тә, Юлбарыс мирзага җавап бирергә кушты. Ул җавап: Үтәмешгәрәй илә Сөен-бикә, шулай ук кырымлыларның барчасы олугъ князьгә тапшырылганда, Иван Казан йортын багышлаячак; казанлылар рус тоткыннарын һичбер вакыт кулларында тотмаенча, аларның барчасын азат итәргә, бәкләр һәм үз кулларында булган рус тоткыннарының барчасын Казан елгасының тамагына китереп, аларны шунда рус боярларына тапшырырга, калган тоткыннарны исә, Шәехгали падишаһ булгач та, барысын да коткарып, казанлылар кулында рус тоткыннары һичбер кеше калмаска, дигән сүзләрдән гыйбарәт иде. Юлбарыс мирза, Иванның җавабын ишеткәч тә: «Һәр эш падишаһның ирегендә, ул аларны ничек багышласа, барысы да шулай булыр», – диде. Шуннан соң Иван Юлбарыс мирзаны Казанга кайтарып, теге сүзләрне Казан бәкләренә сөйләргә боерды. Шәехгали, шулай ук рус башлыклары янына Алексей Адашев исемле кешене җибәреп, аның аркылы тегеләргә ничек эш итәргә кирәклек турында боерык язды. Иванның бу боерыгы Казан ханлыгы өчен чиктән тыш зарарлы булдыгы кеби, Сөен-бикә өчен дә шулчаклы зарарлы иде.

Иванның боерыгында казанлылар өчен бик авыр шартлар булганга күрә, аларның күбесе ул шартларны кабул итәселәре килмәде. Казанлылар боярлар илә бик озак сатулашып карасалар да, аларга руслар тарафыннан һичбер йомшаклык күрсәтелмәде.

Иванның боерыгында: әгәр дә казанлылар аның теләгәннәрен булдырмасалар, ул шушы көзне Казан өстенә барачак, диелгән булганга күрә, казанлылар ирексездән руслар теләгәнчә эш итмәкче булдылар. Боярлар илә казанлылар арасында сөйләгән сүзләргә бинаән, соңгылар Үтәмешгәрәй илә анасы Сөен-бикәне, шулай ук Казанда калган кырымлыларны Зөя каласына китереп русларга тапшырырга, рус тоткыннарының барчасын азат итәргә, бәкләр исә үзләренең кулларында булган тоткын русларны Казан суының тамагына китереп бирергә, Шәехгали боярлар илә Казан елгасының тамагына килеп, шунда казанлылар илә сөйләнми калган нәрсәләрне сөйләргә, аны бөтен Казан йорты шул урында каршы алырга тиешле иде. Инде казанлылар, рус тоткыннарының кайсыларын азат итми калдыралар икән, ул чагында олугъ князь үзе теләгәнчә эш итәр, диелгән иде. Августның 11 нче көнендә казанлылар Ходайкол угълан, Мурали бәк, Аңкилде абызны Шәехгали янына җибәреп, Үтәмешгәрәй илә Сөен-бикәне русларга тапшырачак идекләрен белдерделәр. Шуларны каршы алырга кешеләр җибәрүен Шәехгали илә боярлардан үтенделәр. Шәехгали рус башлыклары илә киңәшкәннән соңра, Сөен-бикәне Казаннан алып



«Сөембикә белән хушлашу». Фиринат Халиков эше.

кайтыр өчен Петр Серебряныйны җибәрде. Аның янында байтак кына бояр балалары һәм укчылар бар иде. Кайсыбер елъязмаларның сүзләренә караганда, аларның саны дүрт мең иде. Казан татарлары Сөен-бикәне русларга тапшырырга булсалар да, Сөен-бикәнең ул эштән хәбәре юк иде. Петр Серебряный, Казан олугълары илә, Сөен-бикәнең сараена барып керде. Ул чагында Сөен-бикә биек урындык өстендә иде. Петр Серебряный Сарайга кергәч, бүреген салып, Сөен-бикәне алырга килгән икәнлеген сөйләде. Тизлек илә китәргә тиешлелеген белдереп, Сөен-бикәгә хәзерләнергә кушты. Серебряныйның бу сүзе Сөен-бикәгә бик авыр тоелып, утырган урынында катып калды.

Акрын гына тавыш илә: «Тәңренең язмышы, Мәскәү падишаһысының теләгәне булсын», – диде. Сөен-бикәнең хәлсезләнгәнлеге сарай кәнизәкләренә дә сизелерлек булганлыгы өчен, аны култык астыннан тотып торалар иде. Теге сүзне әйтүе илә Сөен-бикә бөтенләй хәлсезләнеп китте. Ачы тавыш илә кычкырып җиргә егылды. Аның болай булуы бөтен сарай кешеләренә тәэсир итеп, андагы кешеләрнең берсе дә егъламый калмады. Сарайның сөйкемле хатыннары, матур кызлары ачы тавыш илә егълыйлар, битләрен тырныйлар, сачларын йолкыйлар, кулларын чәйниләр иде. Боларның тавышлары сарайның тышына да ишетелеп, хан йортындагы кешеләр дә егълый башлады. Хан сарае илә хан йорты канлы яшьләр агызыла торган урын булып калды. Егълау тавышы шәһәр халкына да ишетелеп, алар хан йортына килә башлады. Казанлыларның кайсылары русларны кырмакчы булып, кулларына ташлар алганнар иде. Ләкин Казан башлыклары аларга ирек куймадылар. Таяклар илә куалап, хан йорты яныннан өйләренә җибәрделәр. Бу чакта Сөен-бикә егылган җиреннән тормаган иде. Бераздан соң аны күтәреп торгыздылар. Аңа үлек төсе кергән иде. Казан елгасының тамагында рус көймәсе күптән Сөен-бикәне көтеп торганга күрә, Петр Серебряный аны Идел кырыена алып китте. Ул үзе алдан, Сөен-бикә арттан барадыр иде. Сөен-бикәнең йөрерлек хәле бул-

маганлыктан, аны сарайдан күтәреп чыгардылар. Үтәмешгәрәйне исә сарай кешеләре кулларында күтәреп баралар иде. Сөен-бикә ире Сафагәрәй ханның кабере янына барып хушлашырга Петр Серебряныйдан рөхсәт сорады.

Сафагәрәй хан Казан мәсҗедләренең берсе янына күмелгән иде. Петр Серебряный Сөен-бикәнең үтенечен тыңлап, аңа ире илә хушлашырга ирек куйды. Шулай булса да, аны саклар өчен ничәләп каравылчылар җибәрде. Үзе исә ишек төбенда карап торды. Сөен-бикә кабер янына җиткәч, башындагы алтын башлыгын алып ташлады. Моңлы тавыш илә егълап: «Әй минем сөекле падишаһым Сафагәрәй! Күрәсеңме бөтен хатыннарыңнан артык яраткан хатыныңны? Хәзерендә мин сөекле угълың илә рус йортына тоткын булып китәмен. Синең илә озак ханлык итмәдем... Күп яши алмадым. Син ник миннан вакытсыз аерылдың? Ни өчен мине тол, сөекле угълыңны үксез калдырып кара җир астына киттең? Син кайда торасың? Мин да синең яныңа барыймчы, икәүләп бергә торыйкчы! Ни өчен син мине монда калдырып киттең? Күрмисеңме, синең бикәң үзебезнең мәңгелек дошманыбыз булган Мәскәү падишаһысының кулына биреләдер. Мин ялгызым гына аңа каршы тора алмадым, үземә ярдәм итүче кеше таба алмаенча, ирексез аңа биреләмен. Әгәр дә тел һәм динебез бер булган падишаһ кулына тоткын ителгән булсам иде, мин һич кайгырмаган булыр, шатланып кына барыр идем. Сөекле падишаһым! Минем ачы егълауларымны ишетсәнә! Үзеңнең караңгы ләхетеңне ачып, мине үзеңнең яныңа алсана! Синең ләхетең сиңа һәм миңа хан урындыгы, якты сарай булсыннар, әй сөйкемле падишаһым! Кайсы чакта мин рәнҗеп, сиңа «үлүчеләр илә тугъмаучыларга куаныч булыр», дия идем түгелме? Шул мин әйткәнчә булмадымы? Син шуларны белмәдең, менә безгә хәзерендә тере көенчә кайгы һәм рәнҗү килде. Сөйкемле падишаһым, үзеңнең яшь һам матур бикәңне кабул итсәнә! Мине харап итмәсәнә! Минем матурлыгым илә дошманнар файдаланмасыннар иде. Мин синнән аерылмыйм, көлке һәм мыскыл ителер өчен, телләре һәм диннәре башка булган ят җиргә китмим. Сөекле падишаһым! Кем анда килеп минем егълавымны басылдырыр, кем минем ачы яшьләремне туктатыр, кем минем җанымның кайгыларын таратыр, кем минем яныма килер? Миңа һичкем юк... Мин кайгымны кемгә сөйлим: угълыма сөйлимме, ул сөттән аерылмаган; атама сөйлимме, ул моннан бик ерак; казанлыларга сөйлимме, алар бит үз ирекләре илә ант итеп мине русларга бирделар. Әй сөекле падишаһым Сафагәрәй! Ник син миңа җавап бирмисең, ни өчен үзеңнең сөекле бикәңнең ачы яшьләрен ишетмисең? Менә монда, ишек төбендә, мәрхәмәтсез гаскәрләр торалар, алар мине, ерткычлар кыр кәҗәсен алып киткән кебек, синең яныңнан алып китмәкче булалар. Бер чагында синең хатының булган, бөтен Казан падишаһлыгының бикәсе саналган кеше хәзерендә кызганыч тоткын, ярлы һам арык кол булып калды. Борынгыдагы куанычлар, андагы кәеф-сафалар өчен хәзерендә егышулар, ачы күз яшьләре килде. Электәге ханлык шатлыклары урынына мине рәнҗүләр, кайгылар, бәлаләр чормады. Мин хәзерендә егълый да алмыйм, күземнән яшьләрем дә чыкмый. Бетми торган ачы яшьләр илә минем күзләрем сукырайды. Күп кычкырудан тавышларым кысылды...» – диде. Сөен-бикә шул сүзләрне сөйләгәч тә, кычкырып, Сафагәрәй ханның каберенә егылды. Ике сәгать чамасы урыныннан кузгала алмады. Сөен-бикәнең моңлы тавышлары илә сулкылдап егълаулары рус башлыгының да күңелен йомшартты. Ничаклы угъланнар, мирзалар бар исә, барысы да кычкырып елый башладылар. Петр Серебряныйга Сөен-бикәне көтеп тору авыр тоелды. Үзенең кешеләреннән берсен җибәреп, Сөен-бикәне алып чыгарга боерды. Теге кешенең кушуы буенча, сарай егетләре илә сарай кызлары Сөен-бикәне җирдән күтәрделәр. Шул чагында аның хәле киткән, йөзе сулган, башы ачылган, бите ерткаланган иде. Петр Серебряныйның кешесе Сөен-бикә янына килеп: «Бикә, син курыкма, елавыңнан тукта! Син бит мыскыл ителергә, үләргә бармыйсьң. Сине Мәскәүгә олы сый өчен алып барабыз. Казанда ничек булган булсаң, анда да шулай булырсың. Олылыгың илә ирегең синнән алынмас. Ирекле падишаһ сиңа зур сый күрсәтер. Ул, һәр кешегә мәрхәмәтле булып, синең падишаһыңның начарлыкларын искә төшермәс. Сине бигрәк тә яратып, Казан урынына сиңа рус йортында шәһәр бирер. Сине кайгы һәм сагышта калдырмаенча, аларны шатлыкка алмаштырыр. Мәскәүдә, Шәехгалидән башка, яшь падишаһлар, сиңа тиңдәшләр күп. Әгәр теләсәң, шуларның үзеңә охшаганына барырсың. Шәехгали синең атаң вә яхуд бабаң шикелле карт. Син матур чәчкә, пешкән җиләк кебек яшь. Шуның өчен Шәехгали сине алырга теләмәс. Һәр эш падишаһның ирегендә, ул нәрсә теләсә, сиңа шуны кылыр. Син ул хакта кайгыртма, сагышланма!» – дип, Сөен-бикәне юатырга тырышты.

Сөен-бикәне озатып калыр өчен, Казан халкының барчасы урамга чыккан, ир, хатын, егет, кыз, зур, кечкенәләрнең берсе дә өйдә калмаган иде. Сөен-бикәне руслар кулына тапшыру башта кыен саналмаган иде исә дә, соңыннан чиктән тыш кыен булып чыкты. Таш кебек каты күңелләр дә йомшарып, кызгану яше күрмәгән күзләрдән дә яшьләр агар булды. Сөен-бикә үзенә билгеләнгән арбага утырып, Казан елгасының тамагына таба китә башлады. Озак та үтмәстән, арба яр кырыена килеп туктады. Сөен-бикәнең арбадан төшәрлек хәле калмаганга күрә, аны култыгыннан күтәреп төшерделәр. Сөен-бикәне алып китәчәк көймә яр кырыенда көтеп торадыр иде. Бу көймә төрле бизәкләр илә бизәкләнгән, уртасында, Сөен-бикәгә утырыр өчен, бизәкле бер бүлмәсе бар иде. Сөен-бикәнең арбадан төшәргә хәле булмадыгы кеби, көймәгә керергә дә хәле юк иде. Шуңа күрә аны көймәгә күтәреп кертергә тиешле булды.

Сөен-бикә көймәгә керер алдыннан озатырга җыелган халык илә сагълыклашты. Халык та

аның илә чын күңелдән хушлашып, Сөен-бикәне кызганган идеген белдерде. Теге көймәдән башка тагын да ничәләп көймәләр яр кырыенда торалар иде. Шуларның берсе Петр Серебряныйга, башкалары исә Сөен-бикәне саклап барачак рус гаскәренә билгеләнгәннәр иде.

Озак та тормаенча көймәләр кузгалып китте. Казан халкы елганың ике ягыннан Сөен-бикәне озатып барды. Сөен-бикә чиктән тыш акыллы вә шуның илә бәрабәр бик юмарт, шулай ук халыкның һәр кайсына мәрхәмәтле булганлыгы өчен, аны Казаннан җибәрү халыкка бик кыен тоелды. Көймәләр күздән югалганга чаклы халык аны карап калды. Сөен-бикә утырган көймәнең алдында һәм артта сугыш көймәләре булып, боларның эчендә коралланган рус гаскәре Сөен-бикәне саклап барадыр иде. Казан халкына Сөен-бикәне озату ничаклы кыен булса, аны рус кулына тапшырып, өйләренә кайту да шулчаклы кыен булды. Озатканда күпме яшь коелды исә, кайтканда коелганы да аннан ким булмады. Сөен-бикәнең Казаннан китүе 1551 елның 11 августында, Зөягә җитүе шул көннең кичендә булды. Аны озатыр өчен Казаннан байтак кеше Зөягә килгән иде. Шуларның кайсылары елап Казанга кайтты, кайсылары исә Зөядә калды.

Сөен-бикә Зөя каласында бер кич кундыктан соңра августның 12 нче көнендә Волга буенча Мәскәүгә озатылды. Аны саклап барыр өчен Петр Серебряный җибәрелде. Петрың янында бояр балалары, укчылар, шулай ук Казан олугъларыннан Костров илә Галимәрдан хаҗи бар иде. Сөен-бикә Зөядән киткәч, Казанга таба карап: «Кызганыч син, канлы, кайгылы шәһәр! Синең башыңнан таҗың төште. Син хәзерендә тол хатын кебек булып калдың. Син хуҗа түгел, инде кол булдың. Синең атаклылыгың барысы да китте. Син, башсыз арыслан кебек, хәлсез калып, беттең, һәрбер падишаһлык акыллы падишаһ илә идарә ителә, көчле гаскәр илә сакланыла. Шулар булмагач, кем синнән падишаһлыгыңны алмас? Синең көчле ханың үлде, башлыкларың көчсезләнде, кешеләрең боекты, башка падишаһлыклар сине якламады, аз булса да сиңа ярдәм бирмәде, шуңа күрә син җиңелдең. Менә хәзерендә син үткәндәге атаклыларыңны, андагы бәйрәмнәрне, андагы җыеннарны, андагы кәеф-сафаларны сагынып, минем илә бергә ела! Кайда синең борынгыдагы ханлык бәйрәмнәрең, андагы шатлыкларың? Кайда синдәге угъланнарның, бәкләрнең, мирзаларның мактану вә олугъланулары? Кайда синең яшь хатыннарың, матур кызларың? Аларның бию вә җырлары? Болар барысы да югалды, бетте. Хәзерендә синең ул урыныңда халыкның ыңгырашуы, уфылдавы, елавы, үксүе генә калды. Синдә бал елгалары, эчемлек чишмәләре аккан чаклар бар иде. Хәзерендә анда синең кешеләреңнең каннары агадыр, ачы яшьләре коеладыр, рус кылычы аларны бетергәнчегә чаклы кипмидер. Әй Алла! Минем башыма килгән вакыйганы атам илә анама барып хәбәр бирүче, кеше теле илә сөйләүче, тиз очучан кош кайдан алыйм икән? Әй Алла! Безнең көнчебез һәм азгын дошманыбыз булган Шәехгалине үзең хөкем ит, үзең җәзасын бир! Мине дошманым кулына биргәнлекләре өчен, миңа килгән кайгылар Шәехгали илә казанлылар башына да килсен. Аларның теләве, Иванны алдаулары буенча мин шулай булдым. Мин тоткынны (Шәехгали) үзенә алырга теләмәде. Мине зур хатын итәсе килмәде. Ул миннән башка, үзенең хатыннары исә генә Казанда падишаһлык итмәкче булды. Ул миңа олугъ князьне ачуландырып, аның боерыгы буенча, безне, һич гөнаһсыз, үзебезнең падишаһыбыздан кудырды. Ни өчен безне үзебезнең җиребездән куалар, ни өчен безне тоткын итәләр? Ул миңа Казанда кечкенә бер өлеш жир бирсә, мин шуннан артык нәрсә теләмәс, үлгәнчегә чаклы шунда торыр идем. Яисә мине үземнең утрагым булган Нугай урдасына, Җаек артына, аның олугъ бәге булган атам Йосыф янына җибәрсә иде, мин анда атамның өендә тереклек итәр, үземнең үксез һәм тол калуыма үлгәнчегә чаклы елар идем. Мәскәүгә баруга, рус йортында мыскылланып, көлке ителеп яшәүгә караганда, миңа ирем янында булу артыграк, ачы үлемне тату яхшырак булыр иде...» – диде.

Сөен-бикә Зөядән Нижний Новгородка, аннан Муромга, Муромнан Владимир аркылы Мәскәүгә килде. Аның Зөя илә Нижний арасында, шулай ук Нижний илә Муром арасында булган сәфәре көймәләрдә булып, боларның беренчесе Волга буенча, икенчесе Ока буенча иде. Башкалары арба илә булды. Сентябрьнең 5 нче көнендә Сөен-бикә Мәскәүгә килеп җитте. Ул көн шимбә иде.

Сөен-бикәнең Зөядән китүеннән бер көн соң Шәехгали Казанга китте. Казан елгасының тамагында көймәдән төшеп, Бишбалта янында урын тотты. Августның 14 нче көнендә Казаннан Колшәриф мулла, Мөхәммәтсәед, Ходайкол угълан, Мурали бәкләр Шәехгали янына килделәр. Болар Шәехгалине Казан ханлыгына билгеләр, руслар илә ике арада булачак эшләрне сөйләшер өчен килгәннәр иде. Августның 16 нчы көнендә Шәехгали Казанга кереп ханлык итә башлады. Шулай итеп, Казан ханлыгы яңадан Шәехгали кулына күчте. Шәехгали тыштан караганда Казан ханы булып күренсә дә, ханлыкны башкаручы рус князе Иван иде. Казан ханлыгын башкаруда Шәехгали үзлегеннән бер эш эшли алмаенча, аның бар эшләгән эше Иван боерыгы буенча иде. Моннан элек Шәехгали Казанда тынычлап ханлык итә алмадыгы кеби, бу юлы да тынычлап тора алмады. Аны казанлылар яратмыйлар, аңа ханлыкның алга китүе өчен тырышучан җитәкче дип карамыйлар иде.

1552 ел гыйнварында Мурали, Костров бәкләр, шулай ук Галимәрдан хаҗи Иванга багынып, Шәехгалине Казаннан алуын, аның урынына бер калгай җибәрүен үтенделер. Болар ул чагында Мәскәүдә торалар иде. Тегеләрнең сүзләре Иванга ошады. Шул елның февралендә Алексей Адашевны Казанга җибәреп, аңа Шәехгалине ханлыктан төшерергә боерды.

Мартның 6 нчы көнендә Шәехгали Казаннан китте.

Әдип белән Саҗидә. Саҗидә Сөләйманова һәм Әдип Маликов. Алар икесе дә әдәбиятыбызда тирән эз калдырган зур талант ияләре. Шагыйрә Саҗидә Сөләйманова диюгә, әлбәттә инде, аның ире, язучы һәм шагыйрь Әдип Маликовны искә төшерәбез. Бер-берсенә терәк булып, бер-берсен тулыландырып, «Бездән дә бәхетле кем бар бу дөньяда» дип, иҗатны, тормышны сөеп яшәгән бу ике зур шәхеснең бергә яшәгән еллары легендаларга торырлык. Журналист Әнвәр Маликов әтисе Әдип абый, әнисе Саҗидә апа турында менә ничек искә төшерә: «Әтием белән әнием матур пар гына түгел, коллегалар да, бер-берсенең тәүге укучылары, беренче тәнкыйтьчеләре дә иде. Ул – игелекле, тыныч, гадел, бераз сүлпәнрәк. Әнием, киресенчә, һәр эшкә җиңел алына, хискә бирелүчән, җырларга ярата... Йортыбызда һәрчак иҗади атмосфера, шигърият рухы... Бөтен сөйләшүләр шул темага гына... аларның миңа нинди зур байлык калдырып киткәнен үсеп җиткәч кенә аңладым...»
Быел аларның икесенең дә юбилей елы. Августта Әдип Маликовның тууына 100 ел булды. Бу көннәрдә исә Саҗидә Сөләймановага 95 ел тулуны билгеләп үтәбез. Ә укучылар өчен Саҗидә белән Әдипнең бер-берсенә язган хатларын уку, яшерен яну-көюләрен тою үзе бер табыш булыр. Ике яшь йөрәкне кавыштырган хатларның кайберләрен сез дә укып карагыз әле.


Саумысыз, Әдип!
Ике хатыгызга бер юлы җавап язам. Өченче хатыгызны
да көтәргә уйламаган идем дә, сезне китеп барыр дип,
шакка булдым. Мин бит сезгә бер көнне ике хат җибәргән
идем, сез аның берсен генә алмагансыз икән.
Бүген миңа шундый күңелле. Просто
на. Беренчедән, балалар килеп үткән
Мин аларны кисәтермәскә тырышам, ә алар кисәләр.
Сезгә авыр бит, апай, – диешеп булалар. Авыр икәне
кайн белмәгәндер инде, әйткәнем дә юк. Бигерәк тә

«СӨЕКЛЕМ» ДИП ЯЗАРГА ЯРЫЙМЫ?


Сәлам!
Сез бәлки мине белмисездер дә. Мин
исә Аксаит мәктәбенең 1-классында
укып йөргән көнне генә Саҗидәне
яхшы хәтерлим.
14-августта ахыры, Куедага кайтып
төштем. Әти каршы алды һәм шул
ук поезд белән сезнең китеп барганлыгыз-
ны хәбәр итте. Берничә көннән
соң Тәтешледә булдым, урамда
әтиегезне очраттым, сөйләшеп тор-

Әдип Маликов истәлекләреннән:

...Мин аны беренче тапкыр 1933 елның җәендә Аксәет авылы клубында очраттым. Сәхнәдә оча-куна биегән сары чәчле кызга гөрләтеп кул чаптылар...

Сентябрь җиткәч, бер кулына – чәчәкләр, икенчесенә сумка тоткан кечкенә буйлы горур кызны мәктәп юлында күрдем... Физкультура түгәрәгенә йөрүләр...

Икенче тапкыр Саҗидәне, һич уйламаганда-көтмәгәндә, Тәтешле мәктәбендә очраттым. Мин – педучилище тәмамлаган укытучы. Ә ул – алтынчы сыйныф укучысы, икенче рәттә утыра. Шунда бер-беребезне танып алдык...

Берничә көннән армиягә китәргә военкоматтан чакыру килде. Тарантасларга төялгән такыр башлы егетләрне бөтен Тәтешле озата чыкты. Мәктәп укучылары арасынла Саҗидә дә бар иде. Ул, һаваны йомшак кына сыйпаган

сыман итеп, кул болгап калды. Миңа булгандыр дип уйладым. 1939 елның көзе иде бу.

Җиде елга сузылган солдат тормышы. Рәхимсез сугыш... Кайда да шул кыз күз алдымнан китмәде...

...1946 елның җәендә Кораллы көчләр сафыннан Аксаеткә кайткач, әти бер арада Сөләймановлар турында сүз чыгарды, Саҗидә исемен телгә алды: «Уфа techinstitutyна керергә җыена икән...» 10 яшьлек сеңлем Лена да сүзгә кушылды: «И чибәрлеге аның, абый...»

1950 елда Мәскәүдә Әдәбият институтында беренче курсны тәмамлап, каникулга кайтканда Куеда станцасында мине әти каршы алды. Вагоннан төшүгә үк поездым кузгалып та китте. Ике генә минут торганын белә идем.

– Китте шул, – диде әти, уфтанган сыман. – Сөләйманов кызы Урал ягына эшкә китте. Институтны тәмамлаган. Яңа адресын сорап алдым...

Әдәбият институтының икенче курсына укырга килүгә, Әдип Маликов Башкортстан чигендәге Әбҗәлил районы Аскар урта мәктәбенә Саҗидәгә хат юллый. Ике арада хатлар йөри башлый.

«Саҗидә!

Мин сезне, Аксәет мәктәбендә укып йөргән нәни биюче кызны, бик ачык хәтерлим... Куедага кайтып төштем. Әти каршы алды һәм шул ук поезд белән сезнең китеп баруыгызны хәбәр итте... Уфа techinstitutyн тәмамлагансыз икән, эшли дә башлагансыз, уңышлар телим!

Мин әле студент булып йөрим. Безнең уку йорты «Язучылар союзы каршындагы Әдәбият институты» дип атала. Биредә үзбәк, поляк, грузин, татар, румын, кытай, болгар һ. б. милләт егетләрен очратасың...

Саҗидә, сез нык үзгәргәнсездер, очрашканда, бәлки, бер-беребезне танымас та идек. Тормышыгызда нинди яңалыклар бар? Эшкә күнегеп буламы? Җәйге каникул ничек үтте? Барын да әйтеп хат язуыгызны үтенәм.

Сәлам белән, Әдип. 11.09.50.»

«Исәнмесез, Әдип!

Учительскийга керсәм, укытучылар шау-гөр килеп каршы алдылар: «Саҗидә, бие, сиңа хат бар, – диләр. – Әле кайдан гына – Мәскәүнең үзеннән!» Хатадыр дип уйладым башта, Мәскәүдә бит минем беркемем дә юк. Хатны ачып, соңгы юлга игътибар иттем һәм кемнән икәнен дә белдем. Әйе, Уфа педагогия институтын тәмамлап, эшли башладым. Туганнар һәм дуслар ризасызлык белдерүгә карамастан, Башкортстанның иң ерак районын сайладым. Минем аз булса да сәяхәт итәсем, ят җирләрне, яңа кешеләрне күрәсем, элек күчмә халык булып саналган башкортлар белән танышасым килде. Магнитогорск 35 километр гына булуга карамастан, Аскар шактый караңгы, аулак почмак икән. Әле Уфада чакта ук бу яклар күлгә бай дип ишеткәнем бар иде. Шул күңелемне тартып китерде, ахрысы. Мин бит йөзәргә бик яратам. Имтиханнар җитсә, Агыйдел буеннан кайтып керми идем.

Монда чын башкортлар яши. Җәй башыннан ук ишегалдында казан асалар, ачык һавада табын әзерлиләр. Авылның тирә-ягында биек-биек кыя таулар. Гаҗәп матур күренешләр!

Хыялымнан сезне чыгарып ташласам, тормыш мәгънәсезгә әйләнер төсле.

Беләсезме, мин Сезне «Пионер Павлик Морозов» спектакле буенча хәтерлим. Бер бәләкәй генә рольдә мин дә катнаштым. Бу Аксәет мәктәбендә укыган чакта иде. Аннары байтак еллардан соң мин Сезне яңадан очраттым. Тәтешле урта мәктәбендә укыганда дәрескә яшь кенә җыр укытучысы керде. Бу Сез идегез... Әле дә хәтеремдә: ак чырайлы, ябык кына гәүдәле идегез. Сезнең китүегез миңа бик кызганыч булып тоелган иде. Хәзер очрашсак, Сезне обязательно танур идем. Теге вакытта, поезд каршыларга төшкән әтиегез Сезнең кунакка кайтасыгызны әйткәч, үзегезне бер күрәсем килгән иде. Ләкин мин утыруга, Сез кайткан поезд кузгалып та китте.

Көнләшәм мин Сездән. Әдәбият институтында укыйсыз... Мин монда укучыларга Мәскәү һәм Мәскәү дәүләте тарихы турында сөйлим, ә үземнең башкалада булганым да юк. Киләсе җәйгә бару турында хыялланам: музейларын, тарихи урыннарын карап йөрергә, Третьяков галереясы белән танышырга, «Иван Сусанин»ны тыңларга...

Сәлам белән, Саҗидә. 20 сентябрь, 1950 ел.»

«Исәнмесез, Саҗидә! Кайчакта шулай үткәнне хәтерлисең, һәм күз алдыннан, экрандагы шикелле, таныш йөзләр чагылып үтә. Менә шулар арасыннан бер кешегә – сезгә багышлап хат язуым булды. Нәрсә сәбәп булгандыр, үзем дә төшенеп җитә алмыйм. Бәлки, минем кайткан юлны дәвам итеп, сезнең шул поезд белән утырып китүегездер? Әллә әтиегез белән очрашумы?.. Һәрхәлдә, Куедада күрешә алмау бик пошындырды мине... Үземнең тормышлар бер көйгә, студентларча гомер үткәрәм. Лекцияләр тыңлыйбыз, күңелсезрәкләреннән качып чыгабыз да киногa китәбез (или шатаемся по Тверскому бульвару). Атна саен язучылар белән очрашу кичәләре булып тора. Үткән атнада Илья Эренбург белән очраштык. Нәрсәләр язуым белән кызыксынгансыз. Уфа газеталарына язышканым юк. Казанда чыккалый. 1948 елда «Сахалин язмалары» дигән кечкенә китабым да басылды. Янам, көям, эзләнәм – киләчәктә, бәлки, берәр рәте чыгар шунда. Хат көтәм үзегездән. Фоторәсемегезне җибәрегез, чынлап әйтәм, Саҗидә, ярыймы?..

Әдип. 30.09.50.»

«...Беләсезме, Әдип, монда хәзер гаҗәеп матур, күз явын алырдай алтын көз. Шундый тын, моңсу, сихри айлы төннәр. Агачлыклар арасында коры яфракларны кыштырдатып йөрергә яратам мин. Мондагы табигать бик ошый. Шулай да өйгә кайтасы килә. Биредә туганнарым, якыннарым юккадыр инде...

Миңа шунысы кызык булып китте. Әткәй белән ничек очраштыгыз соң? Башта кем кемне таныды? Неужели Сез? О, ул минем турыда сөйләмичә түзмәгәндер инде...

Безнең фикер-тойгылар еш кына бер-беребезне кабатлый.

Фотомны сорагансыз. Ни гаҗәп, район үзәгендә фотоателье юк. Үзегездән дә алу шарты белән, элекке фотомны җибәрергә туры килә инде. Тузгыган чәчләремә игътибар итмәссез тик.

Сәлам белән, Саҗидә. 12 октябрь, 1950 ел.»

«Исәнмесез, Саҗидә! Хатыгызны алдым. Дөресрәге, дару урынына кабул иттем. Мин ул көнне Мәскәү клиникасында ята идем. Операциядән соң тән уттай яна, башымда әллә нинди томанлы уйлар... Кемдер акрын гына басып, минем койка янына килә. Башны күтәрми генә сорыйм: «Сестра, дару китердегезме?» Миңа ир кеше җавап бирә: «Әйе, дару китердем сиңа. Менә ике хат», – дип, кулын суза. Карыйм, каршыда Габдулла Әхмәтшин басып тора (Уфада укыганда «Тальян гармун»ны карагансыздыр, бәлки, шуның авторы). Хатларның берсе – Сездән, икенчесе – Ерак Көнчыгыштагы энем Рәмзидән иде. Карточкагызны алып, элекке таныш чалымнарны эзли башлыйм. Русча әйткәндә, «те же чуть-чуть упрямые губы, немножко грустное, открытое лицо, доверчивый взгляд» и т. д.

Каникул көннәрен башлыча Татарстанда, Баулыда, нефть якларында уткәрдем. Фадеев үзе кул куеп биргән командирока белән Әлмәткә дә барып чыктым.

Менә Сезгә күптәнге карточкамны җибәрәм. Мәскәүгә килгәч әле рәсемгә төшкән дә булмады.

Сәлам белән, Әдип. 23.10.50.»

«Әдип, исәнмесез! Эшнең кайнар чагында язам – ыгызыгы киләбез, чабабыз, нервларны сыныйбыз. Бүген көне буе бишенче классларым белән бергә булдым. Лозунглар яздык, стена газетасы, фотогазета чыгардык. Карикатуралары – «Крокодил» көнләшерлек. Әдип, миңа мәктәп җене кагылды, ахры. Мин балалар белән саташып яшим... Карточкагызны алдым, рәхмәт! Дөресен әйткәндә, Сезне башкача күз алдына китергән идем. Соңгы тапкыр, мин – укучы, Сез укытучы чакта күргәндә, бераз оялчан, тыйнак, йомшак күңелле булып калгансыз хәтеремдә. Ә монда якын барырлык та түгел: горур, кырыс! Дөнья үзгәрткән, күрәсең. Сезнең өчен бүгенгесе юк, гүя киләчәк кенә яши шикелле. Бәлки, ялгышамдыр.

Бүген мәктәптә эшләр беткәч, биек таудан чана шудык. Кемнәр белән диегез – бишенче классларым белән! Ат җигә торган олы чанага утырып. Монда үгез җигәләр. Мин, мөгаен, акылдан язганмындыр. Кәефем шәп: котырып биисем, җырлыйсым, өзлексез сөйләшәсем килә.

Иртәгә радиодан Кызыл мәйдан сулышын тыңларбыз, һәм Сезне бәйрәм колоннасында итеп күз алдыма китерәчәкмен.

Саҗидә. 6.11.50.»

«Бу хат барып җиткәндә Сезнең Яңа елны каршы алган вакытларыгыз булыр. Яңа ел белән котлыйм, Әдип! Бәхетле, көчле, шат күңелле булыгыз!

Беләсезме, Әдип, бер яктан, укытучы булу әйбәт. Ә икенче яктан – бик начар. Укучылар һәр адымыңны, хәрәкәтеңне күзәтеп йөриләр. Урамнан берәр егет белән узганыңны сизсәләр, алар аны җинаятькә саный. Узган шимбәдә беренче мәртәбә танцыга бардым. Кич буе бер яшь егет белән биедек. Һәм соңыннан мине озатып та куйды ул. Менә бүген кайда гына күренсәм дә, пышылдап сөйләшкәннәрне ишетелә: «Ташбулат», «танцы» һәм башкалар. Ни дисең аларга? Укытучы неужели монашка яки «футлярдагы кеше» булырга тиеш?..» 25.12.50.»

«Мин сезне аңлыйм, Саҗидә. Ә сезнең «роман», бәлки, тәмамланып ук киләдер. Шулай да «аңа» булган тойгыларыгызны салкын баш белән тагын бер сынап карау артык булмас, минемчә. Йә, ни дип әйтим инде тагын? Ике мең километр ара һәм 12 ел вакыт аерып тора безне. Хәзер генә күрешеп сөйләшү мөмкинчелегебез юк. Әйе, берберебезне күрми торып, уртак фикергә килү читенрәк. Саҗидә! Әгәр Башкортстанның ерак бер почмагында сезнең язмышыгыз үзегез теләгәнчә матур хәл ителә икән, нигә куркып торырга! Ләкин, үз бәхетен эзләүче егет буларак, мин башкача да фикер йөртергә хаклы: җәй көне күрешербез, аңлашырбыз, көтә аласыз икән – көтегез. Алдымда сезнең ике хатыгыз ята. Икенче хатыгыз ничектер теләр-теләмәс кенә язылган шикелле. Ә беренчесен кат-кат укып чыктым. Анда билгесез борчылу, ачынып кычкырасы килү... һәм... чын мәхәббәткә сусау... Минем дә хәлем шундыйрак бит. Әле хужерак та...

Әдип. 19.01.51.»

«Әдип!

Минем сезгә бер хатны да теләр-теләмәс кенә язганым юк. Һәрвакыт якын кешегә язган тойгы белән һәм, артык нәрсә язып ташламагаем, дип сакланыбрак язам. «Тәмаланып килә торган роман» турында сез бераз арттырыбрак язгансыз. Чөнки мин ул «роман»га чын мәгънәсе белән башланып китәргә дә юл куймадым...

Сәлам белән, Саҗидә. 02.02.51.»

«Исәнмесез, Саҗидә! ...Бүген көне буе Мәскәү буйлап йөрдем. Ничектер эшкә кул бармый. Кызыл мәйдан бүген бигрәк тә җанлы. Кремльдә сессия бара, депутатларның кереп-чыгып йөргәне күренә. Күптән түгел генә Мәскәү янындагы Загорск шәһәренә экскурсиягә барып кайттык. Тарихи шәһәр... Мин анда Сезне уйлап йөрдем. «Менә тарих укытучысы өчен боларны күрү ничек кирәк булыр иде», – дип... Беләсезме, сезнең белән көннән-көн ныграк очрашасы килә башлады. Тик бер нәрсәдән куркам, сезнең каршыда мин малай гына булып күренермен төсле, бирдә бит москвичкалар бары да буйга озыннар, шуңа күнеккәч, сезне дә миннән озындыр дип шикләнә башладым (минем буем хәзер 163 см). Простите за такую наивность...

Иртәгә 8 Март. Котлыйм! 7.03.51.»

«Исәнмесез, Саҗидә! Мин хат язып утырганда, тышта кошлар сайраганы ишетелә, форточканы ачып куям. Бүлмәгә яз һавасы бәреп керә. Минем белән бергә торучы Леонид исемле егет хат язудан бүлдерә дә, яза башлаган шигыреннән төрле вариантлар укып күрсәтә. Менә шундый юллар хәтердә кала: Загрустил я с вечера... / Ночь летит бескрылая. / Где же вы, желанная, / Отзовитесь, милая! Язгы көн. Күңел ашкына. Яшьләрнең гашыйк була торган чагы...

Хушыгыз. Әдип. 17.03.51.»

«Беләсезме, Әдип, минем сезгә рәхмәт әйтәсем килә. Ни өчен дип әйтимме соң инде? Сезнең хатларыгыз миңа таяныч булып тора. Морально... Әдип, «бер-беребезгә терәк булыйк» дигән карарга килергә иртәрәк түгелме әле? Сез бит мине бөтенләй белмисез. Ә күрешкәч, башка тәэсир калыр, капма-каршы фикер туар. Беләсезме, минем характерым, мөгаен, бик чатаклыдыр. Ә Мәскәүдә очраша алсак, шулай да кызык булыр иде, әйе бит? Күз алдына китерегез: башкалага бер авыл кызы килә дә, биек башняларга, небоскрёбларга карап, адым саен сөрлегә, ә сез аны, адашып калмасын дип, кулыннан тотып йөртәсез. Аның театрларга да, музейларга да керәсе, көне буе шәһәр карыйсы да килә. Менә озак йөрүдән аяклары тубырлый яки туфли үкчәсе сынып чыга. Әле кунарга урнаштырырга да кирәк үзен. Икенче күренеш: сез аның белән театрга бардыгыз, ди. Анда москвичкалар, солидный дамалар озын бальный күлмәктән күз явын алып йөриләр, ә бу «кычыткан чыпчыгы»ның юбкасы тез башыннан гына. Һәм сезгә һәр адымда мәскәүлеләрнең шелтәле, мыскыллы карашлары белән очрашырга туры килә. Ох, тиз туярсыз бу галәмәтләрдән, ник чакырганыгызга үкенерсез. Шундый хәлләр булу ихтималына карамастан, бик барасым килә Мәскәүгә...

Саҗидә. 30 апрель, 1951 ел.»

«Исәнмесез, Әдип!

Китәсе иде күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга! Тизрәк сезнең белән күрешәсе иде! Чит-ят һәм беренче танышлар кебек кенә булмыйча, якын дусларча, туганнарча. Их теге вакытта Куеда станцасы ник күрештермәде икән безне?! Бу юлы инде без иң якын кешеләр булып очрашыр идек. Шушы минутта ни теләгәнемне белсәгез иде: иң якын кешенең күкрәгенә башым куеп елыйсы иде бер. Ә ул дәшми генә чәчләремне сыйпасын иде.

Сау булыгыз! 11 май, 1951 ел.»

«Соңгы хатыгызда язганча, андый халәт миндә дә була. Сөясе, сөеләсе килә... Әдип, мин сезнең янга барырга карар иттем, котәрсезме? Юк-бар турында уйламагыз, зинһар, барысы да нормально булыр. Имтиханнарга әзерләнегез. Поезддан төшеп, яныгызга килүгә, милиционер сыман: «Гражданин, документыгызны рөхсәт итегез!» – дип, зачёткагызга күз салырмын. 17 май, 1951 ел.»

«Әдип! Соңгы көннәрдә күбрәк сезнең турыда уйлыйм. Тиздән күрешүебезгә хәтта ышанмыйм да. Ә кинәт очраша алмасак? Килүемә сез китеп барган булсагыз? Нишләрмен? Шул турыда уйлап кайгырам хәзер. Уйларымда сезгә бик күнеккәнмен, ахры. Белмим, белмим – ни белән бетәр моның ахыры. Ә сез... «Бер минутка да чыдый алмам», – дип, алдан ук кисәтеп куясыз. Әле күрешмәс, яхшылап танышмас борын... Әдип, әгәр көтелмәгән сәбәпләр аркасында тоткарлана калсам, мине көтәрсезме, ә?» 28.05.51.»

«Әдип, хәтерегездәме, «Истребитель» фильмында Серёжа профессорга сорау бирә: «Ә телеграммада «сөеклем» дип язарга ярыймы?» – ди. Моны искә төшерүемнең сәбәбе сезгә ни өчендер шулай дип сүз кушарга теләгәннән булса кирәк... Тизрәк очрашасы килә. Нигә шулай микән?

Саҗидә. 29.05.51.»


«Саҗидә! Мин дә бит шундый кичерешләр, хыяллар белән янып яшим. Тормышта да, минемчә, без тиз арада уртак тел таба алыр идек... Кичә М. Горькийга һәйкәл ачылды. Татарстаннан безнең лауреатлар Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов катнашты. Һәйкәл бик матур урында – Белорус вокзалы каршында. Мәскәүгә килгәч, үзеңә күрсәтермен әле. Саҗидә, поездга билет алгач, вагон номерын күрсәтеп телеграмма бирергә онытма. Без тебя Москва скучает. Приезжай скорее! Хәерле юл, Саҗидә! Әдип. 11.06.51.»

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.



■ Яшьләрнең җылы хисләрен түкми-чәчми тапшырып торган бу хатлар – Саҗидә белән Әдипнең бөреләнеп килгән мәхәббәтләренең шаһиты. Хатлар аша җаннар инде бер-берсен табышкан, аңлашкан, язмышка буйсынасы гына калган... Аларны Мәскәү кавыштыра, көтелгән очрашу 1951 елның июль ахырында була.

Мөдәррис Әгъләмов... Аны «замана Тукае» дип йөртәләр... Шагыйрь Ркаил Зәйдулла исә «...ул – үзе шигырь» ди. «Шигырьләре тоташ янудан яратылган шикелле», – дип язып калдыра Саҗидә Сөләйманова. «Яшермим, кайбер шигырьләреңне укыганда аягүрә басасым килде», – дип бәя бирә Наҗар Нәҗми...
Мөдәррис Әгъләмов шигырьләрен укып, без дә шундый хисләр кичерәбез. Нечкә лирика, тирән фәлсәфә, уйлар ташкыны... Ул шигырьләр тансык безгә, тансык! Шагыйрьнең тууына 75 ел тулуны билгеләп үткәндә, кайта-кайта укыйк шуларны...



Мөдәррис ӘГЪЛӘМ

ДӘВАМ БЕЗДӘН ТОРА

Көзге авазлар

Көз килгәндә яфракларын сибеп,
Кара болытларны өстерәп,
Әнкәсеннән калган колын сыман
Чишмә аваз бирә челтерәп.

Сөргән җирдә башын сузып калган
Көзге курай – камыл сызгыра.
Кыр казлары сыман канат җилпеп,
Билчәннәре мамык туздыра.

Саубуллашу төсе киңлекләрдә,
Соңгы сәламме ул кошларга?
...Яз сурәте төшкән конверт алып,
Сәлам хаты салдым дусларга.

Ай яктыра, йолдызлар яна...

Сагышлы төн. Өстә – зәңгәр күктә
Ай яктыра, йолдызлар яна...
Һәм китәсе килә чиксезлеккә –
Иң ахыргы йолдызларга таба...

Сагышлы төн. Зәңгәр күктә – төптә
Ай яктыра, йолдызлар яна...
Сикерәсе килә мәңгелеккә –
Иң ахыргы йолдызга таба...

Без

Гафу итәбез без җиңелгәнне,
Ачы хыянәтне кичерәбез...
Алданабыз... Шуннан бабайларның
Ялгышларын искә төшерәбез.

Кайгылыны күрсәк – юатабыз,
Кеше бәхетенә куанабыз...
Алданабыз... Шуннан әниләрнең
Чыдамлыгын уйлап юанабыз.

Була вакыт: актарылып, яшьнәп,
Болыт сыман шашып бушанабыз.
Алдансак та, мәхшәр кичерсәк тә,

Илгә,
Киләчәккә
Ышанабыз!

Кил син миңа

Җиңел чагымда да кил син миңа,
Кил син миңа авыр чагымда да...
Бик бай чагымда да кил син миңа,
Кил син миңа ярлы чагымда да.
Кил син миңа буп-буш табынга да,
Кил син миңа төрле чагымда да.

Җиңел чагыңда да кил син миңа,
Кил син миңа авыр чагыңда да...
Бик бай чагыңда да кил син миңа,
Кил син миңа ярлы чагыңда да –
Кием сайлап азаплана күрмә,
Төрле кием киеп кил син миңа,
Бары янып-сөеп кил син миңа –
Гомерлеккә диеп кил син миңа.

Әгәр китәм дисәң, тотмам сине:
Сиңа начар булсам, кит син миннән,
Артык ярлы торсам, кит син миннән;
Йә хыянәт итсәм, кит син миннән, –
Тотмам сине китсәң, бары куркам
Синең соңгы юлга китүеңнән.

Аздан тора

Яздан тора дәвам,
Яздан тора,
Илгә кайтып безнең табигатьтә
Яши алыр киек каздан тора –
Дәвам яздан тора.

Көчтән тора дәвам,
Көчтән тора,
Үткән белән бүген җитәкләшеп
Бара торган үзгәрештән тора –
Дәвам эштән тора.

Сүздән тора дәвам,
Сүздән тора,
Кеше заты синең сүзең белән
Китеп бәхет тапкан эздән тора –
Дәвам бездән тора.

Хистән тора дәвам,
Хистән тора –
Туган телең дигән Ана йортка
Җыелып килә алыр күчтән тора.

...Ә чын язмыш
Үзең язган гына...
Аздан тора дәвам,
Аздан тора...

Үзе шагыйрь (мәхәббәт лирикасын гына укып карагыз!), үзе профессор (ветеринария хирургы, фән докторы ул!), үзе спортчы (штанга күтәрү буенча Татарстан чемпионы булсын да!), үзе чәчәкләр үстерүче (бакчасында әле дә розалар, кашкарыйлар, хризантемалар ямь биреп утыра!)... Һади Такташ, Шәйхи Маннур исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал турында сүзебез. Бу көннәрдә күркәм юбилеен билгеләп үтүче шагыйрьне гомер бәйрәме белән котлыйбыз! Игътибарыгызга сөю, ярату тулы шигырьләрен тәкъдим итәбез.



Рифат ҖАМАЛ

СИН ГЕНӘ КҮҢЕЛДӘ

* * *

Бу тормышның, бәлки, минем өчен
Хатын-кызлар – иң зур бизәге!
Бер көн күрми торсам мин аларны,
Бу дөньядан бик тиз бизәмен.
Алар юкта – күкне болыт каплый,
Көн сүрелә. Кояш тотыла.
Һични уйлый алмый газиз башым,
Салкын котып җиле йортымда...
Болыннарда чәчәкләр дә шиңә,
Тулы Ай да күзгә күренми.
...Сез булганда, бары сез булганда
Күзләремнең нуры сүрелми!

Син генә күңелдә

Син генә, син генә күңелдә,
Йөрәгем гөлләргә күмелә.
Яратсаң, күтәр син күкләргә
Бу бәхет тимәгән күпләргә.

Юк икән, сал мине утларга,
Үлсәм дә килешмәм юк-барга.
Син генә, мин генә дөньяда –
Мәхәббәт көн яна, төн яна.

Ул сүнсә, бу гомер ник кирәк,
Сусыз бит үсмидер гөл-тирәк.
Кемнәрдер әйткәннәр бик зирәк –
Миңа – син, сиңа мин тик кирәк.

* * *

Мин килермен иртән кояш булып,
Мин килермен кичен ай булып.
Мин килермен өзелеп сагынганда
Йөрәгеңә синең май булып.
Мин килермен сиңа яңгыр булып,
Керфегеңнән яшең юармын.
Җилләр булып исеп, кайгыларың
Ярсып таратырмын, куармын.
Мин килермен күктә йолдыз булып,
Серләреңне аңа сөйләрсең.
Мин килермен сиңа җырым булып,
Син җырымда мине сөярсең.
Мин китәмен.

* * *

Бу поездлар ничә тапкыр китте
Сине алып, мине калдырып.
Ничә тапкыр карап калдым инде,
Күзләремне алмый талдырып.
Ничә тапкыр каршыладым сине,
Түзә алмыйча килеп җиткәнең.
Үбәр өчен синең иреннәрең,
Бөрлегәнең синең, җиләгең.
Бүтән килмәс инде синең поезд,
Ул юлларга төшәр ак томан.
Перроннарда кемнәр очрашырлар.
Син булмассың анда, мин булмам.

* * *

Син теләмә миңа ак бәхетләр.
Бәхет булмый аклы-каралы.
Ап-ак карлар күмеп китте инде
Сукмакларны – безнең араны.
Син теләмә миңа ак бәхетләр.
Ниндие бар, шунысы минеке.
Таудай ишелгәндер сиңа бәхет –
Минсез бәхет, бары синеке.
Син теләмә миңа ак бәхетләр.
Бәхет – бәхет түгел ул синсез.
Сөюне дә үзең белән алдың,
Дисәләр дә, сөю үлемсез.

* * *

Син киткәндә шундый горур идең,
Әйтерсең лә сиңа мин тездән.
Шуңадырмы, җаның тоймады күк
Сагынасыңны мине бик тиздән.
Сагынырсың әле якты көндә
Минем чәчәкләрнең исләрен.
Кара төндә сине җылытырлар
Сиңа булган кайнар хисләрем.
Сагынырсың минем кочагымны,
Җаның эргән татлы назымны.
Сагынырсың минем белән булган
Һәр көнеңне, көзең, языңны.
Сагынырсың. Мин беләмен синең
Кайтасыңны киткән юлыңнан.
Кире кайтып мине эзләрсең дә,
Сагынырсың, җаным.
Мин булмам!

* * *

Көн буе кулда – кул йөредек...
Уяндым. Караңгы төн икән.
Шулай да син минем җанымда.
Булсаң да, булмасаң янымда,
Барыбер син минем өн икән.





Нәбирә
ГЫЙМАТДИНОВА

Аның әсәрләрен бик яраталар. Геройларын да, телен дә, кузгаткан темаларын да... Китап кибетләрендә повесть, романнары шундук юкка чыга. «Сихерче», «Үзем генә беләм», «Сөйлим, тыңла...», «Бер тамчы ярату», «Болын патшасы», «Уйламаган көнем юк», «Синдә минем хакым бар»... Бер генә китабының исемен әйтү дә җитә – сүз Нәбирә Гыйматдиновага күчә. Туфан Миңнуллинның: «Нәбирә – талантлы язучы. Кеше ышанмастай нәрсәләрне дә ышандырып яза ул», – дигән сүзләре язучы иҗатына зур бәя булып яңгырый.
«Бал корты чәчәктән чәчәккә кунып бал җыйган кебек, «язмышлар» җыям. Күбрәк кешене тыңлыйм. Әсәр язганчы геройларым бөтен булмышы белән күз алдымда басып тора», – ди ул үзе.
Бүген сезне Нәбирә Гыйматдинованың яңа геройлары белән очрашу көтә. «Фәрештәләр» әсәреннән өзек тәкъдим итәбез.

ГӨЛ АПА

(Әсәрдән өзек)

...Күптән, бик күптән фәрештәләр тавышын ишетәм. Беренче тапкыр тыңлаганда, акылдан яздым, ахры дип, авылга йөгергән идем. Анам ишегалдында сыер сава иде, мин, аякларымны туктата алмыйча, тыпыр-тыпыр аның янында биеп:

– Анда... анда... – дип, басудагы хикмәтле хәлләрне әйтә башлагач, ул:

– И Ходайның җәзасы, – диде һәм атама кычкырды: – Акмал, дим, Акмал! Нишләп кенә бетәрбез икән?! Бу баланың чире азган саен аза ла! Әнә, фәрештәләр дип саташа инде. Кешеләрдән хурлык, валлаһи!

Атам үз чиратында элеккеге кебек авыр көрсенмәде.

– Безгә авылдан ни-нәрсә яшерергә, Ләбибә? Исәр дигән исеме белән байтактан бирле авыз чайкыйлар, – диде.

– Әллә соң, дим, психлар брачына күрсәтикме, Акмал? Дару-фәлән язарлар иде, ичмасам.

Анам һаман сусыз гына тегермән ташын әйләндерә иде. Болар шулай бәхәсләшә торгач уртак фикергә килделәр дә мине Казанга ияртеп киттеләр. Зәңгәр коймалы бакча эчендәге бина өч катлы иде. Санамадым, җидеме, тугызмы тимер ишекләр аша үттек без. Ишекләр шап итеп артыбыздан ябылып кала. Әйтерсең төрмә, әйтерсең без тоткыннар!

Ак сакаллы карт кына табиб миңа бер генә күз ташлады да:

– Кысыр хәсрәт белән йөрмәгез! Әгәр алар (ягъни минем ишеләр) дөньяда күбрәк, ә без азрак булсак, алар безне, сез җүләрләр дип, урамда аулап, «сары йорт»ка ябарлар иде, – диде. – Тимәгез, иректә үзенчә яшәсен, – диде.

Газиз кешеләрем шушы сәяхәттән соң язмышларына күнде шикелле. Шөкер, атам белән анамның юанычка өч акыллы баласы бар иде. Кем дә түгел, миңа анам кызганыч иде. Мин бит аның бәгыреннән өзелгән җан идем! Шуңа күрә аны: «Көймә-янма, мин камил акыллы

бала», – дип ышандырасым килә, ләкин аның күзләрендә өмет уты сүнгәнен күреп, үзалдымда тотлыга башлый идем. Хәер, анамны ышандыруы бик-бик авыр булыр, һәм, ни кызганыч, мин «савытым тулы» икәнлеген һич кенә дә дәлилли алмыйм, чөнки көн саен нәрсәдер уйлап табып туганнарымның кәефен кыра идем. Соңгысы – фәрештәләр – моңа мисал иде.

Анам минем кимчелегемдә үзен гаепле санап та өзгәләнә иде. Ә ул ялгыша иде. Әйе, мин карында чакта бичара явыз уй кора. Ләкин Аллаһы Тәгалә өнәмәгән ният, ничек кенә теләсәң дә, тормышка ашмый. Бөек Илаһтан башка яфрак та селкенми. Илле яшендә Ләбибә дигән хатын балага уза... Бу хакта ни кайнанасына, ни иренә белгертми, качып кына өч чакрымдагы күрше авыл табибына көмәнен алдырырга китә. Алда – урман. Моңарчы хәвеф-хәтәрсез генә йөрелгән сукмак очында күзләрен ялтыратып өч бүре утырганын күреп, анам җан-фәрманга кире Фумасына элдерә. Иртәгәсен, куркуы басылгач, ул яңадан тәвәккәлли. Тик бу юлысы да уңмый, тип-тигез урында җир убылып, юлы киселә. Өченче тапкыр анамның аягына яшен сугып, көчкә өенә кайтып егыла... Инде син кара уй-ниятеңнән тыйлык, күкләр тарафыннан сиңа өч тапкыр кисәтү ясалды! Юк, хатын бу хәлләрдән сабак алмый, авыл халкы, шул исәптән, атам да сизмәсен дип, корсагын буып бәйләп куя. Янәсе, сулышка буылып, көмәне үзалдына төшә. Мин, билгеле, агачта эленеп калган сары яфрак, әз генә җил какса да, куагымнан өзелергә әзер торам. Бер төнне алар атам белән хуҗалык печәненә бара. Әрҗәсенә төяп, кузгалабыз дигәндә генә, машина ватыла. «Вәлиҗанны йокысыннан уятып, сөйрәтергә тракторын сорыйм, – ди атам. – Син кабинада гына утыр. Бүреләр өркетмәсен».

Сәнәк белән печән ыргыта-ыргыта көч килгәндер, күрәсең, кисәк кенә бичараның эче авыртырга тотына. Басылмасмы дип ул болын янәшәсендәге арыш басуына табан үрмәли. И айның тум-тулы чагы! Баш түбәсеннән дүрт бармак югарылыгында гына ябалаклар оча... Аларның ай нурына манчылып кызарган канатлары шом тарата... Шунда җиде кат йозак белән бикләнгән сер капкасы шартлап ачыла: вакытлы-вакытсыз анамның тулгагы башлана, һәм җиһанга мин туам! Кычкырмыйм, бары тик өзек-өзек кенә ыңгырашам...

Атам, билгеле, алъяпкычка төрелгән нәни генә төргәкне күреп, аркан ава. Аннары шашып:

– Җен баласы бу, каян тапсаң, шунда ыргыт! – дип акыра.

Ярым сукыр Фатыйма әби мине сиртмәле бишектә тирбәткәндә бармаклары белән капшый да:

– Бәй, сабый җитлекмәгән кана! Акмалетдиннең шикләре рас: җен кавеменнәндер бу, киленнеке түгелдер, – ди.

Авылда хәбәр тиз «аяклана». Халык: «Ләбибә кырда нindидер әкәмәткә юлыккан», – дигән сүзләрне бер авыздан икенче авызга ташый. Ни хикмәт, мин еламыйм. Әзрәк исәйгәч, исем куштырырга мулла чакырталар. Ул озак ялындыра. Имеш, кырдан табылган нindидер җан иясенә дога укып гөнаһка батса, кыямәт көнендә тәмуг утында яндыралар ди моны. Хуп, бәби туена күрше-күлән, туган-тумача җыела. Исем сайланган: Гашурә. Йодрык хәтле генә нарасыйны урындыктагы мендәргә салалар. Шунда барысын да шаккатырган хәл була: мулла абзый колагыма исемемне пышылдап дога кылганда, мин дә учымны йөземә каратып, кунаклар белән бергә ике кулымны өскә күтәрәм...

...Бүген дә фәрештәләр арыш басуына төштеләр. Тирә-юнь тып-тын. Тулышкан башаклар гына берберсенә бәрелешеп зең-зең итә. Менә җил көчәер дә, алтын бөртекләр шыбыр-шыбыр җиргә коелыр төсле. Җәйме, язмы, кышмы – мин шушы урынга киләм. Кар яуса – карга бата-чума, яңгыр сибәләсә, пычракка буяла-буяла йөрим. Ник дигәндә, фәрештәләр бу уентыкка гына туктап ял ала. Ундүрт ел (туган көнемнән исәплим) мин аларны бер тапкыр да күрмәдем, нибарысы ефәк кебек йомшак, май җиле төсле ягымлы тавышларын гына тыңлый идем. Суларга да куркып. Кайчакта миндә фәрештәләргә кушылып сөйләшү теләге уяна, әмма иреннәрем, җилем сылагандай, берегеп ябыша иде. Аннан шикләндерә: әгәр тел тибрәтсәм, ачуланырлар кебек. Әр-битәрдән болай да гарык мин. Өйдә һәрберсе «ярамый» дип кисәтә. Шулай, миңа кагылганда берни ярамый. Ә мин үпкәләмим. Олылар белән бәхәсләшү файдасыз, аларның үз туксаны – туксан.

Фәрештәләрнең кыяфәтен мин хыялымда үземчә сурәтли идем. Ап-ак болытларда, керфекләренә кояш нуры сеңдергән көнбагарларда, чык тамчылары эчеп сусылланган җиләкләрдә, таҗларын ачкан чәчәкләрдә, ямь-яшел үләннәрдә аларның төсмере бардыр сыман миңа. Чишмә челтерәвендә, кошлар сайравында да шәйләнәләр кебек... Шуңа мин гаҗәеп гүзәл табигатькә биһуш булам. Аяк астындагы кырмыскаларга хәтле Аллаһы Тәгалә яраткан икәнлегенә инанган кеше бер мин генә түгелдер, мөгаен. Ләкин андыйлар берәнсәрән генә. Казандагы сакаллы табиб әйтмешли, безнең кебекләр ишәйсә, эш харап! Әмма шунысы бар: миндәйләр, ягъни дөньяны үз төсендә килеш кабул итүчеләр, ягъни ясалма кануннарга буйсынмаучылар очрашса, бер-берсен аңламаячаклар. Чөнки бездә «акыллы гавам»нан аермалы буларак, уртаклык юк, һәркайсыбыз үзгә зат. Бервакыт дуслаштыру нияте белән мине үз ишем – «сайсавыт» Зәйтүнәләргә илтте анам. Ул Галия әбинең каладагы оныгы иде. Җәй айларында авылга кайтаралар моны. Зәйтүнә тиктомалдан тамак төбен гырылдатып көлә, ә мин җитди, мин моңсу. Аның чәчендә, әтәч койрыгы кебек, аллыгөлле тасма-каптыргычлар, өстендә ялтыравык күлмәк. Ә минем озын җиңле сарафаным киндер тукымадан, капчыкны кисеп үзем тектем. Чәчләрем дә толымнарга үреп, яулык белән капланган. Нәтиҗәсе



шул: без килешмәдек, без бер-беребезне яратмадык! Ахырдан кыз миңа: «Син җүләр!» – диде, ә мин ләм-мим. Холкым шундый: нәрсә булса да ошамаса яки гайрәтемне чигерсә, сусыз гына йотам, дәшмим.

...Фәрештәләрнең тыныч, салмак тавышына изрәп йокыга талганмын икән, аска бөгелгән арыш башагы битемне чәнчеп уятты. Йә сансыз! Гөлмәрьям апа мине булышырга чакырган иде ләбаса! Ә мин көпә-көндез йокы бүсәм. Бак, кояш ничек кыздыра. Ник алай ялгыша ул, йә? Гөлмәрьям апа дим, ник үз куллары белән хата чүмәләсе өя?! Безнең Фума авылындагы мегафермага кайлардандыр Шакир исемле җитәкчене билгеләделәр. Чиста-пөхтә хуҗабикә дип, аны Гөл апага фатиргә урнаштырдылар. «Төнлә шикләндерә», – дип, ялгыз йокларга курыккан хатын гел мине кунарга китерә иде. Баласытмаган, иптәш санагандыр инде. Шакирга ул өйнең алгы бүлмәсен бирде, ә без икенче якта – эре чәчәкле чаршау артында йоклый идек. Ә беркөнне Гөлмәрьям апа минем «хезмәт»тән баш тартты.

– Хәзер мине җен-пәриләр өркетми, матурым. Өеңдә генә кун инде, яме? – диде. Ә үзенең күзләре оялган төсле аска карый иде. Ул, билгеле, алдаша иде. Өркә анысы, бик өркә!

Хуҗалыгындагы вак-төяк йомышларын Гөл апа миннән эшләттерә иде. Карлыган өлгергәч беренче булышчы кем? Мин! Шулай хуҗабикә белән икәү бакчада карлыган чүплибез. Шакир кайтты. Ул искиткеч чибәр иде. Каш-керфек, калын иреннәр кат-кат сызып ясалган төсле. Камиллекнең чиге юк, имеш. Ничек кенә бар! Моннан да матуррак итеп ир-атны тудырып булмастыр ул. Тик егет салкын чибәр, аңа карагач күз өши иде. Өстәвенә, ул һавалы адәм иде.

Шакир кимсетепме, көлепме, миңа:

– Дегеткә буялган убыр мәллә син? – диде.

– Әй Шакир, син инде бигрәк тагын! Кояшта каралган безнең Гашурә. Иеме, матурым? – диде Гөл апа. Каты итеп, бастырып сөйләшкән хатынның бу юлы тавышы ясалма, нәзек иде. – Ай! – Кинәт кенә ул кулыннан савытын төшереп җибәрде.

Шунда Шакир:

– Нишләдең, бәгырем? – дип, аның беләгеннән сыйпады.

Гөл апаның йөзе көл кебек агарды. «Бәгырем...» Бу сүзне мин ишетмәмешкә салыштым. Тик инде ул балык сыман кармак очына эләккән, акыл аны эшкәртеп маташа иде. Бәгырем, димәк... Җен-пәридән ышык җилкә – төн сакчысы Шакир, димәк. Бәхет телим дияр идем, теләмим, чөнки бу бәхет түгел, бу – фаҗига. Мәхәббәтеннән исергән хатынның айныйсылары алда әле...

Шакир ашап-эчкәч фермага китте. Карлыган җыяҗыя әлсерәп куак төбенә аугач, Гөлмәрьям апа:

– Яртысы синеке, әниең кайнатма ясар, – диде.

– Үзебездә дә күп.

– Кешенеке тәмлерәк.

– Син беләсеңдер, Гөл апа.

– Җә инде, матурым, төрттермә. Һай, синең түбән тишек шу-ул. Сиздең син, ә? Авызыңа су кап, зинһар, Гашурә!

– Йотам бит инде мин аны барыбер...

– Әй усал да инде үзең!

Гөл апаның юкка гына йөрәге тырнала, мин ни, мин мондый очракларда телсез һәм чукрак идем. Шакир белән икесенең гыйшык-мыйшыкларын җил урлап авыл урамнарына чәчмәсен менә!

Көлеп-шаярган «кәләш» көннәрдән бер көнне боекты. Күз төпләренә кара ягылып, йөзе суырылды. Иртәкич мин аларга сугыла идем, бүген көтү куганда апам нигәдер сыерын капкадан чыгармады. Өенә кердем. Шакир төн кунмаган, ахрысы, Гөл апаның күмер самавыры гөжләми. Ул аны, чәе тәмле дип, иртән үк кияү егете өчен кайната иде. Алгы бүлмә ишегеннән башымны тыксам – шаккаттым: хуҗа хатын тезләнгән дә, идәнгә маңгаен ора-ора:

– Синең каршыңа барып басасылар бар бит, – дип тәкрарлый иде. Мине күргәч, ул, акланып: – Син, Гөл, ычкынган, ахрысы, димә берүк! Мин Аллага ялварам, – диде. – И-и, гөнаһлы инде без, матурым! Шакир белән никахсыз яшибез бит. Ничекләр Алла каршына барып басып торырмын кыямәт көннәрендә?! Никах укытыйк дисәм, чәчләре тырпая. Без – муллалар нәселе, әти белән әни, мәрхүмнәрем, бу хурлыктан каберләрендә әйләнеп ятадыр. Казандагы балаларымнан да оят!

Ничек шөрепләрен боргалагандыр, берзаман чибәр егет Гөл апаның үгетләренә күнә. Әмма никах икесе арасында гына калырга тиеш сер дигән шарт куя. «Мулласы да минем танышым булыр», – ди.

...Мин авылга очам, аякларым җиргә әллә тия, әллә юк. Гөлмәрьям апа өен юган-җыйган, тәрәзә пәрдәләрен алмаштырган.

– Карале, матурым, – диде ул, минем мышнавыма игътибар да итмичә. – Кулларыңны чайка да караваттагы мендәрләрне кабарт. Бисмилләңны укып, яме? Самат абыең үлгәннән бирле шкаф башында басылып яталар, инде мамыклары укмашкандыр.

– Ул сине яратмый, Гөл апа.

– Абау, кемне әйтәсең син?!

– Шакирыңны. Азгын бәндә ул. Сезнең яшь аермагыз да зур...

Гөлмәрьям апа яулыгын кашларына табан шудырды. Күзләрен яшерә!

– Әй, йөрәгемә кан саудыртмасана! Яратмый дип... Тәрәзә уеп күңеленә бактың мәллә? Син пычагым беләсеңме? Синең акыл җитәрлек эш түгел ул. Мендәрләр белән озак кайнашма, кил, бәлешкә дөге чистарт!

Дәрте ташыган хуҗабикә йөгерә-чаба табын әзерләде.

– Быел бакчада һәммә нәрсә егылып уңды, иеме, Гашурә? Карлыган дисеңме, чиясеме... Нәкыя апаң кайткандыр, шәт?

– Юк әле.

– Бәй, нәкъ җимеш вакыты ла! Нишләп тора икән түзеп!

– Аңа дигәннәре соңрак өлгерә.

– Хи-хи, Нәкыягә аерым чәчәләрмени, исәр! Сибгате көтәдер инде, зар-интизардыр. Тегесенең калада ире, монысының авылда хатыны... Ике Сак белән Сок!

– Бәлешеңнең төбе көйгән, – дидем мин усал гына. Туганымның гайбәтен сатарга кем соң син, Гөл?!

– Бәй, әле мичкә дә тыкмаган бәлеш ничек көяр икән?! Алдан ук каркылдамасана, матурым.

Каркылдаган идем инде: чынлап та бәлешнең асты каралып, табасына каткан иде.

– Кулың камырда, телең гайбәттә иде. Үзең гаепле, – дидем.

Никах мәҗлесе күңелсез узды. Мулла без танымаган ят бабай иде.

– Мәһәргә бүләккә ни бирәсең, улым? – диде ул яшь кияүгә.

Шакир кунакчадагы әтәч кебек түрдә кукраеп утыра иде, аптырап Гөл апага карады. Нинди бүләк, янәсе. Тәҗрибәле «кәләш» эшне аңлап алды да, шкаф тартмасыннан алтын чылбыр тартып чыгарды:

– Менә, хәзрәт абзый, менә кияүнең бүләге!

Уф, чеп-чи ялган! Гөл апа әлеге чылбырны биш былтыр ук муенына тага иде. Искереп, каптырмасы ашалган иде бит аның!

Шакир канәгать елмайды.

Күкләрдә кабул кылынды микән бу никах – зур сорау билгесе... Ул кичне мин арыш кырына бүтән бармадым. Башым сызлады. Иртән Гөл апаларга килсәм, мин тырыша-тырыша кабарткан мендәрләр шиңмәгән, урын-җир җәелгән килеш. «Яшь бикәч» исә елый-елый кызарган күз кабакларын чәйгә чылаткан мамык белән сөртә иде. Почтасына эшкә барасы ла.

– Җизнәң төнлә янымда кунмады, матурым. Йөз пешереп тә бәлешемнең төбе каралмас иде. Хәерлегә булмаган икән.

Гөл апаның «минем акыл җитмәслек эше» тоташ ялгышлардан гыйбарәт иде. «Сез – елганың ике яры, син шуны аңла!» – дисәм, кызган ташка су гына сибәр идем. Мескенкәемнең болай да ярасыннан кан саркый иде. Күз яшьләренең әүвәлгесе-актыккысы тамса икән әле!


Рәсем: Наталья Васильева

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

СССРда туган балаларның күпчелеге җәйләрне авылда әби-бабалары янында үткәрә иде. Дөрес, бабай янында җәй үткәрү бәхете бөтенесенә дә тәтемәде дә әле: сугыштан соңгы елларда күп әбиләр тол калган иде.

Мин ул яктан бик бәхетле булдым. Әбиләрем, бабам, аларның сеңелләре өчен бик кадерле бала идем бит. Җәйгә авылга кайту – ул әле ирек, үзенә күрә әти-әнинең артык «кайгыртуыннан» котылып тору да. Монда сине яраталар, иркәлиләр. Өйдә булышу, кош-корт карау, бакчада эшләп керүне эшкә дә чутламыйсың. Ул эшләр, киресенчә, җаваплылык өсти.

Энем белән без җәй саен бер-ике айга Сабага кайта идек. Әни ягыннан бөтен туганнар Татарстанның Саба районында яши безнең. Бабай белән әби гомер буе колхозда эшләде. Алты баласының 14 оныгы гел бергә җыелып ята идек. Җыеныбыз бер тирә, җитмәсә. Бөтен эшне күмәкләшеп башкарабыз. Чишмәдән су да алып кайтабыз, чүп тә утыйбыз, бабай белән утын да кисәбез.

Әбинең Тимершыкта яшәүче апасы Мөшәррәф тәтәне без гел Тимершык тәтә дип йөртә идек. Кайчакларда аңа кунакка барып, мичтә пешкән каз коймагы белән дә сыйланып кайтабыз. Тимершык тәтә Бөек Ватан сугышы вакытында тол калган. Хәдичә әби белән Шәфигулла бабайның өч кызының иң өлкәне, ул сеңелләренә бөтенләй охшамаган: озын буйлы, какча гәүдәле, эре сөякле, сипкелле битле... Хәтеремдә ул шулай калган. Сеңелләре Мөкәррәмә белән Мөгаллимә, әнә, кара кашлы, алсу йөзле чибәрләр. Көлгәндә битләре чокырланып китә... Тимершык тәтәнең ике кечкенә кызы да шуларга охшаган.

Сугыш вакытында ук тол калгач (ирен сугышка озатканда өченче баласына авырлы була, 1943 елда җизнинең Прага тирәсендә һәлак булу хәбәрен ала), Тимершык тәтә бөтен эшне үзе җигелеп тарта, беркемнән ярдәм көтми. Әнисе Хәдичә әбинең дә булышыр җае булмаган: өй тулы берсеннән-берсе кечкенә балалар, урын өстендә ятучы авыру кайнана... Хезмәт көне өчен колхозда эшләргә кирәк... Тимершык тәтәнең өч кызы да үзе кебек: алны-ялны белми эшлиләр иде. Аларга кунакка баргач, хәлдән тайганчы эшләүләрен күреп, шаккатып кайта идем. Сыер, сарыклар, тавык-казлар, бакча, бәрәңге, шәл бәйләү, печән чабу – ел әйләнә тик торганнары юк аларның. Урманда чикләвек җыеп та саталар, шәлләр бәйләп тә саталар, йомырка, ит, сөт, каймак сатып та акча эшлиләр... Тәтә сату эшләренә һәвәс иде: һәрнәрсәдән акча ясый белә.

Әбигә ияреп, Тимершык тәтәгә кунакка барырга ярата идек. Бер баруда тәтәләрдә матур кечкенә көянтәләр күреп хәйран калдым. Ул аларны онычкларына дип алган икән. Шундый җайлы үзләре: йөгерә-йөгерә су ташымалы. «Миңа да шундый көянтә кирәк!» – дип, өйгә кайткач бабайны тинтерәтә башладым. Кызганыч, андый көянтәләр сатуда юк икән... «Сез мине яратмыйсыз!» – дип, үпкәләп еладым да әле. Шундый матур, уңайлы көянтә асып, чишмәдән су ташый алмыйм дип кайгырдым.

Без – бала-чаганың әти-әниләре дә Тимершыкка барырга ярата торган булган. Ә тәтә һәркайсына эшен дә табып торган. Бервакыт уртанчы абый Мөхәммәтнур Тимершык тәтәгә кунакка барасы килүен әйткән. Аңа ул чакта 10–12 яшьләр тирәсе икән. Тәтә чәй эчергән дә, кунакны сыер көтүен көтәргә җибәргән, көтү чираты килеп җиткән чакка туры килгән бит Мөхәммәтнур. Гөнаһ шомлыгына каршы, икенче көнне сарык көтүе чираты ди. Тәтә тагын Мөхәммәтнурны эшкә җиккән. Малайның бик тә су буена төшеп балык тотып утырасы килгән дә соң... Нишләмәк кирәк! Ә тәтәнең эше һич бетә торган түгел икән: кайтуына, хәйләкәр елмаеп, каз көтүенә чыгарга җайлый башлаган. Мөхәммәтнурның бик ачуы килгән, сикереп торган да әйберләрен җыя башлаган. «Карга көтүегез дә юкмы тагын?!» – дип үпкәләп, җәяүләп өйләренә кайтырга чыккан. Безнең гаиләдә «карга көтүе» турындагы кыйссаны көлә-көлә еш искә төшерәләр.

Балачакта туганнарга кунакка барулар матур хатирәләр булып күңелдә яңара...

Рәмзия КАШАПОВА.
Казан шәһәре.

Фото: www.pixabay.com



Мин 1956 елда туган авылымның җидееллык мәктәбен бик яхшы билгеләр белән тәмамладым. Белем алуымны дәвам итәсем килә, каядыр китеп уку мөмкин түгел, минем физик мәмкинлекләрем чикле...

Ул елларда урта мәктәптә укулар түләүле иде. Хәсрәтле башны кая куярга белмәгән бер мәлдә, туганым Фәния апа сөенечле хәбәр китерде. «Хафаланма, сеңлем, бу уку елында мәктәпне урта мәктәп итеп үзгәртәчәкләр», – дип, күңелне күтәреп китте. «Яңа укытучылар киләчәк, араларында минем белән кайчандыр Кояново педагогика училищесында бергә укыган кыз да бар», – дип тә өстәп куйды.

1958 елның 1 сентябре – көтеп алган көнем. Хәзер мин Фәния апаның танышын көтәм. Кыңгырау шалтырый. Сыйныфташларымның күзләре – ишектә. Сораулы караш: кем керер икән? Бик сөйкемле кыз белән завуч кереп, таныштырып куйды. Исеме моңарчы ишетелмәгән яңа исем икән. «Миңа Рева Хановна дип эндәшерсез», – диде үзе.

Матур кыздан күзләрне алалмыйбыз, зифа буена ятып торган затлы зәңгәр күлмәге кызның зәңгәр күзләренең зәңгәрлеген тагын да көчәйтеп күрсәтә, ә чәчләре килешле итеп баш түбәсенә өеп куелган, тавышы да җылы һәм ягымлы, укытучы түгел, нәкъ фәрештәнең үзе инде. Барлык укучы кызлар читтә булган буйдак абыйларына хатлар язалар: «Абый, тиз генә кайт! Матурдан-матур укытучы кызлар килде мәктәпкә».

Язылган хатларның нәтиҗәсе булды. Егетләр авылга кайттылар. Араларыннан берсенең чәче Рева апаның чәчләре белән бәйләнгән булып чыкты. Ул егет Кунгур шәһәрендә укып, һөнәр мәктәбе биргән юллама белән Красноярск шәһәренең бер заводында хезмәт юлын башлап җибәрә. Танышлык дуслыкка әверелә. Альберт абый Гәбделбәров шул ук мәктәпкә эшкә килә, бер-берсенә арка терәге булып эшләп китәләр. Альберт абый читтән торып Пермь педагогика институтының физкультура бүлеген тәмамлап, туган мәктәбендә 44 ел укытты. Алар икесе дә «Мәгариф отличнигы» һәм «Методист-укытучы» исемнәренә лаек булдылар. Ихлас хезмәт итеп, Чайкада гына түгел, район, өлкә күләмендә абруй казандылар. Рева апабыз, укытудан тыш, авылның мәдәниятен үстерүгә дә күп көч куйды. Кирәк икән – рус биюләрен башкарды, гармунда, баянда уйнады. Рева апаның сәхнәдәге чыгышлары һәрчак алкышларга күмелә иде.

Альберт абый үзен физкультура һәм спортка фидакарьләрчә багышлады. 44 ел укытты дип әйтүе генә ансат ул, ә сөйләсәң... Мәктәп иске, кечкенә һәм тар иде, уңайлыклар юк, спортзал турында хыялланырга гына кала иде. Кышларын физкультура дәресләре ак карда уза. Остазның тәҗрибәсен район күләмендә тарату өчен мәгариф җитәкчеләре ачык дәресләрне, чаңгы ярышларын, эстафеталарны, кроссларны Чайка мәктәбе базасында үткәрә. «Пионерская правда» газетасы призына уздырылган район ярышларында Чайка мәктәбе спортчылары 18 ел рәттән беренчелекне беркемгә дә бирмәде. Остаз укытучы: «Өлкә күләмендә узган авыл мәктәпләре ярышларында без йөзү буенча Усть-Качка мәктәбе укучыларыннан гына калыша идек, чөнки алар кыш көннәрендә дә Пермь бассейннарында йөзү күнегүләрен камилләштерәләр иде. Ә безнең авыл балалары җәй көннәрендә генә йөзделәр, ә спортның башка төрләре буенча алдынгылыкны беркемгә дә бирмәде», – диде.

Альберт Гафият улы хәзер лаеклы ялда булса да, формасын югалтмый: төз, таза һәм көләч, яхшы кәефтә. Хуҗалыктагы эшләрен теләп башкара, ул сугыш чоры баласы, балачагыннан эшләп үскән әтисе дә укытучы булган. Һәрвакыт хәрәкәттә булгангамы, үз гомерендә бер дару төймәсен капмаган, бер укол кадамаган һәм бер генә көнгә дә авырыйм дип авыру кәгазе алмаган.

Рева апабызның да гомер юлы шома гына узмый. Гаиләләренә фаҗига килгәндә 3 яшен генә тутырган була ул. «Халык дошманы» баласы дигән сүзләрне күп мәртәбәләр ишетеп нәфрәтләнгәнен үзе генә беләдер. Әтисе Нәҗемхан абыйны кулга алгач, әнисе Зәкия апага билен җиде кат буып, бөтен егәрен туплап, балаларын һөнәрле, белемле, намуслы чын кешеләр итеп үстерүгә юнәлтергә туры килә. Укытучы Нәҗемхан абый белән Зәкия апа Нәбиевларның балалары да укытучы һөнәрен сайлап, данлыклы әби-бабайларының эшләренә, идеалларына тугры калып хезмәт итәләр.

Укытучыларым тугызынчы дистәләрен ваклап барсалар да, аларга үз яшьләрен биреп булмый, икесе дә һаман хәрәкәттә. Альберт абый хуҗалыгын да тәртиптә тота, һәр җирдә пөхтәлек, хәтта аларның бәрәңге бакчалары да гөлләр түтәле белән чолгап алынган. Рева апаның аш бүлмәсеннән һәрчак тәмле бәлеш исләре килеп тора. Килен кайнана туфрагыннан ярала диюләре дә дөрестер ахры. Альберт абыйның әнисе Бибиханә апаның туй бәлешләрен пешерү остасы дигән даны таралган иде, урыны җәннәттә булсын. Бу гаилә яшәешнең кай ягыннан карасаң да шаккатмалы. Үзара мөнәсәбәтләрен генә алыйк: һәр сүзләреннән бер-берсенә карата җылылык, хөрмәт, наз бөркелә.

Шундый тәрбияле авылдашларыма сокланам, алар белән горурланам, үрнәк гаилә булып авылга ямь өстәп бик озак яшәүләрен теләп калам.

Алия НӘҖИПОВА.
Пермь крае.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

ФИДАКАРЬЛЕК

Әфганстан – аның язмышында аерым тарих. Анда сугыш барганда: «Кан коюны туктатыгыз! Аналар теләге бу!» дип хатлар, петицияләр язды. Чечнядагы хәлләргә протест белдерүче дә татар журналисты, хатын-кыз Әлмира апа булды түгелме?! Үткен каләме, җылы сүзе, киңәше белән яралы йөрәкләргә шифа булырлык күп гамәлләр кылды. Хәтер көннәрендә ялкынлы чыгышлар ясап, ак яулыклы ханым милләт байрагын күтәреп йөрер иде. Милләт язмышы өчен борчылып янды-көйде ул.



Күптәнге хакыйкать: үз илендә пәйгамбәр булмый. Ләкин үзен мөэмин-мөселман дип санаган адәм өчен пәйгамбәребез кушканнарны үтәү фарыз.

Әлмира апа Әдиатуллина «Азат хатын» журналында йөгерек каләмле язучы-журналистлар Диләрә Зөбәерова, Кояш Тимбикова, Мәдинә Маликова ут уйнаткан чорда, алар белән бергә эшли башлаган иде. Ул техник редактор вазыйфасында, булачак журналны калыплау – версткалау, бастыру эшләре өчен җаваплы. Интернет, компьютерлар заманына ерак әле. Ачык йөзле, җиңел сөякле, теләсә кем белән уртак тел табарга сәләтле Әлмира апаның типография белән редакция арасын бер итеп, йөгереп йөрүе табигый тоела. Әмма тормышта, бигрәк тә журналистикада, үз сукмагыңны, үзең эшкәртәсе кишәрлегеңне табу җиңел түгел. Әлмира апа да табачак иде үз темасын. Тапты да. Ни аяныч, югалтулар аша. Сулышы-тыны белән тартып алырдай булып, өзелеп көткән улы – Мараты Сахалин кыяларын кичеп, солдат хезмәтен тутырып кайтты. Ә Газраил аны Казанда – туган җирендә көтеп торган. Газизенең фаҗигале үлеме Ананы аяктан егарлык иде. Шашардай булып йөргәндә дингә, Ходай Тәгаләгә якынаюы саклап калды аны, дисәм...

Баш мөхәррир Роза Туфитуллова «Азат хатын»га (соңрак «Сөембикә») язылучыларга бүләк – журналга кушымта рәвешендә «Иртәнге намаз» дигән китапчык өзерләргә ният итте. Заманы өчен зирәклек һәм кыюлык сорый торган бу эшне оештыруны ул җаваплы сәркатип Әлмира апага тапшырды. Халык дин гыйлеменә сусаган, намазниязга тартыла. Әлмира апа үзенә хас җитезлек, хәтта ки дуамаллык белән эшкә алынды. Рәшидә абыстайга сабакка йөрүе, соңрак «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керүе дә шул нисбәттән булгандыр, шәт? Нәни генә китапчык, ә мәгънәсе нинди олы! Шул кулланма-китапны иптәш, юлдаш итеп ничә мең милләттәш намазга баскандыр! Ярты миллион тираж белән таралган басмага кушымта икәнен истә тотсак! Савабы насыйп булсын. Читада, Казакъстанда, үзбәк, кыргыз якларында яшәүче милләттәшләребездән рәхмәт хатлары яуды. Ә берничә елдан «Намаз – җәннәт ачкычы» дигән нәни китапның икенчесе дә дөнья күрде. Өйлә намазын уку тәртибе белән таныштырган ул басма янә зур сөенечкә әйләнде. «Кулыма тоткан «Азат хатын» миңа Әфганстан чиген үтеп чыгарга пропуск булды. Беләләр иде безне, журналның ответсекретаре, ягъни җаваплы сәркатибе идем бит», – дип сөйли иде ул.

Утыз елга якын «Сөембикә»дә эшләп лаеклы ялга чыккач, гомеренең дәвамын Аллаһ фарыз иткән юлдан тайпылмый барырга ният итүе дә хак иде. Үзе оештырып, 20 ел буе «Мөслимә» газетасын нәшер итте. Күп вакыт – үз акчасына. Соңрак «Ярдәм» мәчете, аның җитәкчеләре Илдар хәзрәт Баязитов, Мәликә ханым Гыйльметдиновалар «Мөслимә»не үзләренә сыендырдылар – Әлмира апага хәерхаһлы булдылар.

Бер генә эштән дә курыкмый торган, көчле, чыдам, эшсөяр авыл баласы иде Әлмира апа. Милли мәнфәгатьләрне кайгыртып, ул башлап йөргән эшләр өчен саллы кәнәфидә утырган берәү дә бер тиен акча бирергә җыенмый. «Милләтнең киләчәге – иманлы, тәрбияле, динле яшь буын кулында. Әдәп-әхлаклы алмаш тәрбиялик. Сабый чактан салына аның оеткысы бала күңеленә», – дип ничә

Исемен «Планетаның иң яхшы 100 хатын-кызы» арасында күрергә теләделәр.

кабатласаң да, җиң сызганып үзең тотынмасаң, урыныннан кузгалмый йөк, ягъни изге ният. 60 елга сузылган динсезлектән, җаһилияттән соң уянып килә бит татар. «Әгәр мин янмасам...» дип, Әлмира апа башлаган бәйге-конкурслар... Мәчетләрдә дин сабаклары алган, дөрес итеп Коръән уку серләренә төшенергә омтылган балалар – тәүгә шытымнарны барлау, аралаштыру теләге ярыш дәртен кузгатып җибәрдеме, Татарстан мөселман хатын-кызларының «Мөслимә» иҗтимагый оешмасы рәисе, «Мөслимә» газетасы мөхәррире Лотфулла кызы Әлмира апа «Сөембикә сеңелләре» дип аталган бәйгегә егерме ел элек үк сукмак салды. Бәйге бүләксез булмый. Ул бәләкәй кул арбасы тартып, кибет саен кереп, арзанрак хакка юньлерәк бүләк җыеп йөрде. Ә сәмәнен... «Хәер акчасы бу. Ашка баргач, таратканнар иде. Савабы булсын!» – дип, үзе ише әби-абыстайлар җыешты аңа бүләкләрне. Бүләк алган балаларның куануын... моны бизмәннәргә салып кем үлчи ала.

Киләчәк буыннар аны Татарстан, Россия мөселманнарының хокуклары өчен җан атып йөргән көрәшче итеп хәтерләр. Элгәрләребез башына яулык, шәл бөркәнми кеше арасына чыгуны белмәгән. Дәһрилек чәчәк аткан чорда гореф-гадәт онытылды, халыкның яшәү рәвеше сансызланды. Мөселман хатын-кызларының паспорттагы рәсеменә баш киеме белән төшүен яклап, яулыкны законлаштыру хокукы өчен көрәшнең башында торучыларның берсе булды Әлмира ханым. Түбән Кама мөслимәләре белән бергә ул да суд юлларын күп таптады. Башта Түбән Кама, аннан Казанның Вахитов районы, аннары Татарстанның Югары судында каралган бу мәсьәлә, чынлыкта, ил буенча калкып чыккан була. Безнең кызлар, апалар мәхкәмәгә мөрәҗәгать итеп, башкалардан өлгеррәк булып чыга. Әмма судлар татар хатыннарының таләбенә каршы карар чыгара. Оттыралар... Әлмира апа – журналист бит, оештыру эшләрен үз кулына ала. Матбугатта язмалар басыла. Мәскәүгә Югары судка барыр алдыннан баш казый Габделхак Саматовтан, Россия мөфтиләр шурасы рәисе Равил Гайнетдиннән нигә мөслимәләр яулыксыз фотога төшә алмый дигән аңлатма да яздырып ала. Мәскәүдә үткән ике утырыш та уңай җавап бирми. Адвокат Фәрит Заһидуллин Страсбургтагы Европа кеше хокуклары судына Россия мөселманнарының көрәше хакында хат юллый. Гаҗәп хәл – ул каралган. Хәтта утырыш та булган. Әгәр Әлмира Әдиатуллина татар-мөселман хатын-кызы паспортка яулык ябып төшәргә хокуклы булуын яклап сигез судта чыгыш ясамаса... бәлки безнең кызларыбыз борынгыларның гореф-гадәте, яшәү рәвешенең бер атрибуты булган йоланы санга да сукмаслар иде.

Теләктәшләр табып, «Колшәриф» мәчете каршындагы «Кысла» сыраханәсен алдырды, «Сотворение мира» дигән күңел ачу чарасын: «Дөнья яратылышына бер катнашы да юк, шайтан туе бит бу! Изге көрәштә һәлак булган бабаларыбызның сөякләре яткан җирне мыскыллау, яшьләрне аздыру», – дип тавыш куптарды. Судларга йөри-йөри, хаклыгын расларга туры килде. Барыбер теләгенә ирешә. Көрәшче рухы, үҗәтлек, тәвәккәллек аның канында, җанында иде, күрәсең. «Гыйракта сугышны булдырмыйк!» дип, АКШның ул чактагы президенты Бушка хат язуы, изге Рамазан аенда хәмер сатуны чикләргә чакырып ил җитәкчеләренә мөрәҗәгать итүе... аңа гына килешә торган эш-гамәлләр үҗәтлек кенәме, җан халәте, күңел кушуы иде...



■ Совет гаскәрләре Әфганстаннан чыгар көн җиткәч, канлы бәрелешләрдә катнашкан хәрбиләрне чик буенда каршы алды. Термезга кадәр барып җитте.

Россия Ислам мирасы оешмасы 2005 елда Планетаның тынычлык өчен көрәшүче хатын-кызлары исемлегендә аны Нобель премиясенә тәкъдим итте. Әлбәттә, югары исем-бүләкләргә дә бик лаек иде ул. Ләкин...

Хәер, «Сөембикә» журналында эшләгәндә лаек булган Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, журналистика ветераны, Мөхлисә Бубый исемендәге бүләк иясе дигән исемнәре белән горурлана иде. Үзе өчен нәрсәдер даулап, соранып йөрү... башына да килмәгәндер. Кош оясы кебек тыгыз-нәни фатирында гомер итте. Аның да яхшы ягын күрә – «Ярдәм» мәчете якын булуына сөенә. Хезмәттәшләренең хәл белешеп торуына да риза-бәхил. Ә журналның «Сөембикә» беләзеген аңа да тәгаенләүләренә ифрат куанганы истә. Без аның белән әле журнал «Азат хатын» булып чыккан чактан, өч-дүрт еллап бергә эшләгән каләмдәшләр идек. Мөхлисә Бубый якташы булуыма, Иж-Бубый мәктәбендә белем алуыма үзенчә олы мәгънә сала, «син – бәхетле», дия иде ул миңа. 20 еллап дәвам иткән «Сөембикә сеңелләре һәм энеләре» бәйге-ярышларына чакыра, хата-кимчелекләре хакында фикер белдерүемне көтә. «Булдырасыз, афәрин!» дигәнгә балалардан ким шатланмый.

Гомерләр аккан су кебек сиздермичә, салмак кына агып ятканда уйланам: аның сыман карусыз, эшкә зарур, тынгысыз, кайчакта бик тә йомшак күңелле, вакыт-вакыт кискен, үткен телле милләтпәрвәр Әлмира апалар белән бер сафта атлау, милли мәгърифәткә көчтән килгәнчә өлеш кертергә омтылып, янып-ялкынланып йөрүләребезне бәхетле чак дими ни дисең?!

Әлмира апа юк инде. Урыны җәннәттә булсын.

Роза КАМАЛЕТДИНОВА



«БУ – МӘХӘББӘТТЕР...»

Гөлнур
САФИУЛЛИНА



«Сау булсаң, ирең сөяр», ди халык мәкале. Ә булмасаң? Көннәрнең бер көнендә кинәт авырып китсәң... Урынга ук калсаң... Тормышның нинди генә сынавы юк лабаса. Берәү дә чирне сорап алмый – ул үзе килә. Һәм кайвакыт, кызганыч, китмәскә дип килә. Хатын кешегә килгән чир һәрвакыт ике өлешкә бүленәдер: аның үзенә һәм иренә. Язмыш аларның кайсын күбрәк сыный – билгесез: хаста булып, кеше күзенә карап яту да җиңел түгел, авыру карау да... Күреп-ишетеп торабыз: чирле хатынын ташлап, өйдән чыгып киткәннәр бар. «Бер генә тапкыр яшим, бәхетле булырга, сау-сәламәт хатын белән яшәргә хакым бар», – дип аңлата андый ирләр бу адымнарын. Әмма ирләрнең икенчеләре дә бар. Татарстанның атказанган артисты НУРЗАДӘнең әнисе Рәмзия ханымга язмыш бик авыр сынау җибәрә. Әмма сынаудан алда инде бәхетен дә юллаган була. Ирен – Фирдинантын. Ачыктан-ачык сөйләшәбез.

– Атагыз! Ул гына исән булсын! Аңардан алданрак китсәм генә ярар иде...

Бу сүзләрне әни соңгы елларда ничәмә-ничә тапкырлар кабатлады икән?! Ә теләге чынга ашты аның – ихлас булгандыр.

Арыган чаклары әтинең дә булгандыр, әмма ялгыш бер тапкыр ул «уф» димәде.

Әнинең ничә ел авырганын төгәл генә әйтә дә алмам – бер көн эчендә генә урынга калмады ул. Егерме еллар элек сызлый башлады аның сөякләре. «Ревматоидный полиартрит», диделәр. Ул чакта бик сирәк очрый иде әле бу чир. Бер табибтан икенчесенә бик күп йөрде, сөякләренә ниндидер уколларга кадәр ясатып карады – файда тапмады. «Балачакта яки үсмерчактa салкын тидергәнмендер, мөгаен», – дия иде үзе. Тик бөтен авыртулар да – нервлардан, диләр бит. Әнигә дә тормышта стрессларны байтак кичерергә туры килгән. Берсе бик истә. Безнең Яңа Кенәр авылында Мәдәният йорты директоры иде әни. Белеме буенча режиссер ул – Казан мәдәният һәм сәнгать институтын тәмамлаган. Халит абый Кумысниковта укыган. Халит аганы хәтерлим әле – әни белән укырга икәү барган чаклар да күп булды: мәктәпкә кергәнче үк институт тәмамлаган кеше мин. Эше өчен янып-көеп йөри иде әни. Халык театры оештырырга хыялланды. Спектакльләр белән өчәр көнгә Казанга гастрольләргә барган чаклары булды. Мәдәният йортыбыз зур иде безнең: дүрт йөз кешелек залы, Мәскәүләргә кадәр барып чыгыш ясаган инструменталь ансамбле, үз хореографы... Янәшәдә үк китапханәсе. Әни ниндидер эш белән Казанга киткәч, төн уртасында Мәдәният йортыбыз янды. Костюмнарның берсен дә алып чыга алмадылар. Китапханәдән бераз китапларны чыгарырга гына өлгерделәр. Кара янган кисәүләр өеменә генә кайтып керде әни. Кайтты да егылды: директор буларак, бу аның өчен зур хәсрәт иде... Ә аннан ул яңа Мәдәният йорты салдыру артыннан йөри башлады. Татарстан мәдәният министрлыгын ул чакта Илдус Тарханов җитәкли иде. «Министрлык ишек төбенә аның үзеннән дә иртәрәк барып басам», – дип көлеп сөйли иде әни... Шулай йөри торгач, ике катлы Мәдәният йортын төзетеп бетерде. Хатын-кыз өчен җиңел эш булмагандыр бу... Лаеклы ялга әни китапханәдән китте. Авырлык белән йөрсә дә, сызланса да, соңгы көнгә кадәр эш урынында булды.

Әти белән капма-каршы иде алар: әни, сәхнә кешеләренә хас булганча, янып-балкып тора, ә әти иҗат дөньясыннан бик ерак – ул җырламый да, биеми дә, бик аз сүзле. Әмма әти безнең гаиләдә иң төп кеше иде – әни шулай куя белде. Әти колхозда бухгалтер булып эшләде: ул эштән кайтмыйча табын янына утырганыбызны белмим. Ипине бездә әти кисә иде – бу да аны бер олылау, хөрмәтләү билгесе булгандыр. Ә клубка чыгыйм дисәң, өйдә тамаша башлана! «Бүген дискотекага барыйм әле!» – дим әнигә. Ә ул, әтинең безнең үтенечләргә беркайчан каршы килмәгәнен бик яхшы белеп торса да, аның янына җибәрә: «Бар, атаңнан сора, ул рөхсәт итсә, чыгарсың!» Хәзерге акылым белән аңлыйм: әни тормышта үзе лидер булса да, әтинең дәрәҗәсен шулай безнең алда күтәргән – аның сүзен һәрвакыт соңгы итеп калдырган.

Кинәт искә төште әле менә. Берсендә әнинең яшь чакта үзе тегеп кигән күлмәген табып алдым. Кыска гына шундый матур күлмәк! Әни – бик оста тегүче иде, кечкенә чакта миңа да кибет күлмәге беркайчан кидермәде. Бик оста бәйли дә иде... Теге күлмәкне кидем дә, дискотекага җыенам. Әни пыр туза: «Шундый кыска күлмәктән барасыңмы?» – ди. Әти шунда тыныч кына әйтеп куйды: «Үз күлмәгең түгелме соң? Сиңа яраган нигә аңа ярамасын ди?!» Тормыш бит – төрле хәлләр була. Кайчак шулай нәрсәгәдер сүзгә киләләр икәү: әни хатын-кызларча чәпчи, ә әти дәшми. Аннан: «Ярар, булды инде, җитте, аңладым», – дип куя. Һәм өйдә тынычлык урнаша...

Мин авылдан киткәндә, әни үз аякларында йөри иде әле. Әмма мәкерле чир астыртын эшен эшли торды: әнинең куллары деформацияләнеп, ул инде әйберләрне тота алмый башлады. Әти аның кулларына әйләнде.

Бөтен эшне икәү эшлиләр иде алар. Камырга кадәр куялар, бәлешләр пешерәләр. Эшлиләр дип... Әни: «Менә хәзер монысын саласың, аннары болай итәсең», – дип өйрәтеп тора, ә әти җиренә җиткереп үти.

Ә аннары әнигә инфаркт булды, һәм ул инде коляскага калды. Әмма дүрт стена эчендә генә яшәмәде – иҗат кешесе өчен диварлар арасында калу һавасыз калу белән бер булыр иде. Әти моны, әлбәттә, белә иде. Шуңа да ул әнинең аякларына әйләнде.

Берсендә санаторийга киттеләр шулай. Мин һәрвакыттагыча шалтыратып, гел хәлләрен белешеп торам. Беркөнне әни кич белән телефонны алмый. Эчемдә ут: әни телефонга җавап бирмәсә, димәк, аңа нәрсәдер булган дигән уй безнең инде аңга сеңгән... Соң гына, ниһаять, үзе шалтыратты. «Без атаң белән дискотекага барган идек», – ди. «Нинди дискотека, әни?! – дим. – Нишләдегез инде сез анда?» «Утырып тордык», – диде ул берни булмагандай. Әтинең гомердә уртага чыгып биемәячәген беләм – әнинең күңелен күреп йөрүе...

Һәр көнне иртән уянып күзне ачуга, беренче эш итеп өйгә шалтырата идем. Хәер, хәзер дә шулай... Бер көнне иртән сөйләшеп хәлләр белештек әни белән. Берничә сәгатьтән кабат җыям: әни «недоступен», әти алмый. Нәрсә уйларга да белмим... «Кызым, эзләгәнсең

Әнинең коляскага каласын белгәч тә, нишләрләр дигән паника булмады – **эти өйдәге бөтен эшне эшли иде.**



икән... Атаң телефонын өйдә онытып калдырган, ә минеке тотмады. Без гөмбәгә бардык!» – ди әни шат тавыш белән. Колясказа утырган кешенең гөмбәгә баруын күз алдына китерәсезме? Мин юк... «Ничек итеп җыйдыгыз инде гөмбәне?» – дим аптырап. «Атаң бит гөмбә танымый: ул җыеп китереп торды, мин – сайладым...»

«Кызым, югалтма, мин бүген клубта жюрида булам. Без киттек...»

«Атаң белән Вятские Поляныга барып кайтабыз әле...»

«Эзләмә, безне бүген кунакка чакырдылар...»

Колясканы машинага салалар да, утырып чыгып китәләр: әле страус фермасына, әле райондагы нинди дә булса берәр музейга – кеше арасында борчулар да, авыртулар да онытылып тора бит. Әни, гомумән, оптимист кеше иде ул: «Тереләм! Бар да әйбәт була!» – дип яшәде. «Мин чирле» дип иркәләнеп ятмады. Кәефен төшермәде: коляскада утырганда да иннек сөртмичә, пудра ягынмыйча, хушбуй сөртенмичә урамга чыкмады.

Ялларда мин дә, энем дә гел авылга кайтырга тырыша идек – этине аз булса да ял иттерәсе, булышасы килә. Ә әнинең телендә эти генә: «Фирдинант, әйдә, болай итәбез!», «Фирдинант, моны эшләмәдек бит әле!» «Нигә һаман этине чакырасың, без бит монда – үзебез эшлибез», – дибез. «Юк, юк, атагыз аны яхшырак белә! – дип шунда ук каршы төшә әни. – Без иялләнгән инде. Ә син әнә башка эшкә тотын».

Әни урында ятмаска тырыша иде – эти аны торгыза, коляскага күтәреп утырта. Календула белән әнинең авызын чайката, комган, ләгән алып килеп, битен юдырта... Бертуктамый әнинең исенә төшереп тора: «Син әле бу даруыңны эчтеңме? Ә тегесен?» Нинди китап укырга тели – янына шуларны китереп куя. Сценарий язарга утырса – ә әнигә мондый үтенеч белән еш мөрәҗәгать итәләр иде – алдына кәгазен китереп сала... Киендерә, чишендерә, кулы күтәрелмәгәндә чәчләрен тарый. Без бакчага эшләргә чыксак, аны да безнең янга алып чыгып утырта, аннан алып керә. Рәмзиягә күңелсез булмасын дип, чәйгә кадәр аның янында эчә. Әни төнлә борылып ятса да уяна иде ул: «Су кирәк түгелме? Торгызмыйммы?» Кайвакыт төнлә әнигә начар булганын белми дә калабыз – эти аны безгә иртән генә әйтә. Әйе, әнине бик карады ул. Бик! Югыйсә үзе дә яшь түгел иде инде.

Икенче инфаркт булгач, әнине Казанда, Республика клиник хастаханәсендә саклап ятам. Ул чакта өйдә терлекләр дә бар әле: эти аларны күршеләргә калдырып, өч көнгә бер мине ял иттерергә килеп китә. Әни телендә гел ул: «Син мине атаң кебек торгыза белмисең...», «Атаң миңа чәйне башкача ясый...», «Син аркамны авыртырып уасың, атаң алай итми...» Эти бер көн калмыйча (!) әнинең кулларын, аркаларын, аякларын уа иде! Андый ир-атлар тагын бармы икән?! Мунчага да әнине гел үзе кертте ул. «Сине үзем юындырыйм әле?» – дисәм дә, әни беркайчан ризалашмады: «Атаң мине ничек юарга икәнен яхшырак белә!» Көчем җитмәс дип куркуы да булгандыр инде: ничә еллар буе гормоннар кабул иткәч, әнинең гәүдә авырлыгы да арткан иде. Даруларны азрак киметергә тырышып та карады, әмма «отек Квинке» булып, көчкә исән калды... Әнине юындырырга җайлырак булсын дип, эти өйгә терәп яңа мунча салды. Гомумән, бөтен нәрсәне әнигә җайлаштырды: веранда ишекләрен, бусагаларны – коляска белән кереп-чыгып йөрү көйләнгән булганга күрә дә алар өйдә генә утырмадылар.

Ә аннан әнигә тагын бер инфаркт булды... Ул икенчесеннән соң ук: «Больницага башка барып йөрмим», – дип кайткан иде. Сүзендә каты торды: «Кузгатмагыз, китсәм – өйдән китәрмен». Алданрак операция ясарга да тәкъдим иткәннәр иде аңа, ризалашмады: «Атаң белән инде сөйләштек... Наркозны күтәрә алмаячакмын», – диде.

Табиблар бу юлы безне баштан ук кисәттеләр: «Ундүрт көн эчендә барысы да хәл ителәчәк: йә кала, йә юк... Мондый очракта йөрәкнең инде өченче өлеше үлә». Ун көн система алганнан соң, әни рәтләнеп китте! «Маркиз ун көн буе йөрәк ягымнан кочаклап ятты, бүген менә ул да янымнан чыкты. Димәк, иң авыры инде артта – тереләм!» – дип куанды әни. Маркиз – минем песи, җәйгә авылга кайтарып куйган идем. Әни аны бик яратты: «Алып китмә, яше бар – ул да инде картлар рәтендә, өч пенсионер монда рәхәтләнеп яшәрбез», – диде.

Минем Казан дәүләт филармониясендә узачак концертыма әзерләнеп йөргән көннәр иде бу. «Туйга чакыра Нурзадә» дигән бу тамашага сценарийны әни үзе язды. Хәле азрак көйләнүгә, телебездә шул кон-

церт кына булды: сөйләшәбез, киңәшләшәбез, үзгәрешләр кертәбез.... «Ике-өч көн кала, авылда куярсың, ул сиңа репетиция кебек булыр», – ди әни. Мәдәният йорты директоры белән инде көнен дә билгеләргә өлгергән. Үзе дә концертка барырга җыена. Әти аптырый: «Ничек инде?» – ди. «Миңа ул концертка барыбер барырга кирәк! Нәрсә җитешми – әйтергә!» – ди әни, кире какмаслык итеп.

Әнинең хәле бер авыраеп, аннары җиңеләеп киткән чаклар алдан да күп булды. Бу юлы да шулай булыр дип уйладык – авылдан тыныч күңел белән киттем. Туй алып барырга тиеш идем, юлда аңа шалтыраттым. «Ярар, кызым, исән-сау эшләп кайт!» – диде ул. Бу – аның миңа әйткән соңгы сүзләре...

Икенче көнне иртән уяндым. Нигәдер күңел урын тапмый... Телефонны әти алды. Беләм: әни урынына ул җавап бирә икән, димәк, әнинең хәле әйбәт түгел... «Кызым, кайта алсаң, кайт әле син», – ди. «Хәзер эшләремне җайлыйм да, әти», – дим. Бераздан кабат шалтырата: «Нәрсә уйладың, кызым, юлга чыгасыңмы?» – ди. Ишекне ябып ята идем инде. Энем белән сөйләшеп алдык – аның Ханты-Мансига эшкә киткән чагы иде. Әти аңа да: «Эштән сора да, кайтырга тырыш әле – анаңның хәле авырайды», – дигән. Начар уйларны куарга тырышып, юлга кузгалдым. Ә эч поша... Дөбъязларны узгач, нигәдер әнинең абыйсына шалтыратып алырга уйладым. «Син юлдамы? – диде ул исәнләшүгә. – Без иртәгә генә кузгалырбыз инде – җирләргә генә кайтабыз». Башта бернәрсә дә аңламадым. «Әниең үлде», – диюче юк бит әле миңа. Артта барган машина кычкырта башлагач, юл читенә чыгып туктадым... Әти үзе шалтыратканда ук әни өзелгән булган икән инде, ә ул мине кызганган, әйтмәгән. «Йөз чакрым кайтасың бар иде бит әле, кызым», – диде соңыннан...

Ул көннәр томан эчендәге кебек... Әнине юарга үзем булышуларым, «Соңгы тапкыр күреп кал», – дип, халык арасыннан энемне табып, җитәкләп диярлек әни янына алып килүем. Ленар – миннән дә нечкә күңелле, әнинең мәете янына бөтенләй керә алмады...

Әнине озаткач, әтигә: «Миңа нишләргә икән хәзер?» – дим. Концерт ноябрь башына билгеләнгән иде – нибары ун көн калып бара. «Куярга кирәк. Шулкадәр әзерләнгәннән соң баш тартсаң, анаң риза булмас иде», – диде ул...

Миңа әле күлмәк тегүчем шалтырата – аның янына барырга кирәк, әле биючеләр белән репетиция ясарга, әле... «Кирәк»нең очы-кырые юк! Ә миндә җырлыйсы түгел, елыйсы гына килгән халәт...

Азат Зарипов – тамашаның режиссеры иде. Ул – әнинең укучысы, аны яхшы белә. Концерт башланыр алдыннан пәрдә артында басып торабыз. «Рәмзия апа хакына эшләп чыгарга тиеш син бу концертыңны, Нурзадә!» – дип, ул мине аркамнан этеп, сәхнәгә чыгарып җибәрде.

Әти концертка килде. Аның кайда утырганын белә идем – ул якка карамаска тырыштым. Филармониядә алдагы алты рәттә тамашачы бик әйбәт күренә, туганнан туганнарыма да әйтеп куйдым: «Мин чыккач еламагыз, югыйсә концертны өзүем бар». Залга килгән халык та яңа гына нинди хәсрәт кичергәнемне белә иде... Иң ахырда әтигә рәхмәт сүзләре әйткәндә күз яшьләремне инде тыя алмадым. «Әгәр дөньяда бөтен ир-атлар да безнең әти кебек булса, хатын-кызларга яшәргә күпкә җиңелрәк булыр иде», – дидем. Ул концертның язмасын әле дә карый алганым юк – йөрәгем җитми...

Әнинең китүен әти бик авыр кичерде. Хәер, аңа әле хәзер дә – биш ел узгач та җиңел түгел... Шалтыраткан саен: «Мин хәзер нишләргә, нәрсә белән шөгыльләнергә белмим», – диде. Ничә еллар буе бөтен тормышы әни тирәсендә әйләнде бит... «Китап та укыйсым килми, телевизор карарга да теләмим. Бакчада да эш бетте – чыгам да әйләнеп керәм», – ди... Әнине җирләгәч, энем: «Апа, Маркизны әти янында калдырып тор әле, ул аңа иптәш булыр», – дигән иде. Дөрес киңәш бирде. «Без Маркиз белән шуны эшләдек, моны эшләдек, – дип сөйли башлады әти. – Икәү утырып чәй эчтек әле менә...»

Теге вакыт, бер минут китмичә ун көн буе әни янында ятканнан соң, торып чыкты да, соңгы ике көндә Маркиз ул бүлмәгә якын да килмәде. Әни моны үзенең терелүенә юраган иде.. Әни вафат булгач исә мәете янына менеп, янә аны кочаклап ятты – куып карасак та төшмәде. Аптырагач, мунчага илтеп ябып куйдым. Ә иң гаҗәбе соңрак булды: әниләрнең йокы бүлмәсенә ярты ел буе аяк басмады ул. Бусагага кадәр килә дә, мияулап, әтине чакырып тик тора иде...

Әти янына еш кайтып йөрим. Башкалар кебек ялгыз калган әтиләренә булышыр өчен түгел, күрешергә, хәл белергә, утырып бер сөйләшергә – әнине сагынып елап алырга... Безнең әтинең өен җыясы юк аның – бар җирендә тәртип: тузаннары сөртелгән, тәрәз төбендә гөлләре чәчәк ата. Гөлләр дигәннән. Әнинең вафатыннан соң ике-өч ай узгач, берсендә әти шалтырата: «Гөлләр үлеп бетә инде, нәрсә эшләп карарга да белмим», – ди. «Әллә суны күбрәк сибәсеңме икән?» – дим. Аннан исемә төште – әни бит гөлләре белән бертуктаусыз сөйләшә иде. Өй эчендә култык таяклары белән акрын гына йөри алганда бер тәрәзәдән икенчесенә бара – яраннарына гел нидер пышылдый иде... Әтинең дә гөлләре гөрләп утыра хәзер.

...Узган ел җәй коронавирус белән авырдым. Янымда беркем юк. Күңелгә курку үрмәли – күзләремне йомсам да, беркем белмәячәк бит... Үзәгемне өзеп әти турында уйлыйм – ул да бит үзе генә. «Әти, бәлки сиңа кемнедер димләргәдер? Үзеңә генә кыен бит инде», – дим шалтыратып. «Әниеңне беркем дә алыштыра алмый», – диде ул миңа шунда.

Бу мәхәббәттер инде.

Фотолар: җырчының шәхси архивыннан.

КҮҢЕЛЕБЕЗГӘ АК НУР СИПКӘНСЕЗ...

Иң гүзәл кеше икәнсез

Килгән чакта башка авырлык,
Җитми калса көч йә сабырлык,
Сиздермичә ярдәм иткәнсез –
Сез иң күркәм кеше икәнсез.

Балаларның теле — кыңгырау,
Гел чыңгылдый, ява мең сорау.
Барысына да җавап биргәнсез –
Сез иң галим кеше икәнсез.

Укып чыгып, дөнья тануны,
Бәхетебезне эзләп табуны
Зур ышаныч белән көткәнсез –
Сез иң сабыр кеше икәнсез.

Мактагансыз тиеш урында,
Яклагансыз тиеш урында.
Күңелебезгә ак нур сипкәнсез –
Сез иң гүзәл кеше икәнсез!



Алсу ШАКИРОВА

Мәктәптә укыган еллар искә төшә... Октябрь аеның беренче якшәмбесе. Укытучылар көне! Бу көнгә алдан хәстәрләнә идек без. Һәр сыйныфның иң оста шигырь сөйләүчеләре, җырлаучылары, биючеләре бәйрәм программасы төзеп, укытучыларны котларга әзерләнә... Иртән директорыбыз «киңәшмә» дигән сәбәп белән укытучылар коллективын җыя. Ул арада барлык укучылар спорт залына җыелып, сюрприз әзерли. Менә «киңәшмә» тәмам, балалар әзер... Укытучылар кабинеты ишеген ачып, абый-апаларны коридор буйлап бәйрәм буласы бүлмәгә озатабыз. Анда килеп керүгә ике йөз бала берьюлы «Ко-о-от-лы-ы-ый-бы-ыыз!» дип шау итә, укытучыларны алкышларга күмәләр. Йөзләрендә елмаю балкыган тыйнак укытучыларыбыз урындыкларга барып утыралар. Җыр башлана. Укытучыларга дан җырлана... Сез – иң гүзәл кеше икәнсез... Сез иң күркәм, иң галим, иң сабыр, иң гадел кеше икәнсез... Җырны башкарган егет-кызларның тавышлары калтырап куя. Һәммәсе үзенең яраткан укытучысына багышлый җырны. Күңелләр тула...

Халкыбыз яратып җырлый торган җырлар исемлегенә «Иң гүзәл кеше икәнсез» җырын күптән язып куйган идек. Аның тарихын да барлар көн җитте. Укытучылар көне – халыкчан бәйрәм. Җир йөзендәге һәр кеше билгеләп үтәргә хаклы аны. Һәммәбезнең котлар кешесе, рәхмәт сүзләре җиткерер остазы бар тормышта... «Иң гүзәл кеше икәнсез» җырын иң беренче булып башкарган җырчы-мөгаллим янына барганны белсә, укытучы әнием дә куаныр дип уйлап, Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев яшәгән йортка ашыгам. Һәр кешене мәктәп елларына алып кайтырга, хатирәләрне яңартырга этәрүче бу җырны ничек дөрес җырларга кирәклеген фәкать Миңгол абый гына беләдер... Нәрсәсе бар, барыбыз да җырлап үстек ул җырны, димәгез... Уильям Шекспир трагедиясе буенча куелган «Ромео һәм Джульетта» операсы аһәңе кергән бу җырга!

Ләкин иң беренче чиратта сүзне җырның авторыннан башларга кирәктер. Хәрби хезмәттән җәрәхәт алып кайткан Фәнис Яруллин укуын Казанның 18 нче номерлы кичке мәктәбендә дәвам итә. Гомерлеккә йөри алмас хәлдә калган егетне укытучылар өенә килеп укыта. Наилә Гарифулла кызы Гатауллина, Гөлчәчәк Кәрим кызы Галиева, Виктория Михайловна, шагыйрьнең яраткан укытучысы Вәли Хаҗи улы... «Кайберләренең фамилияләре онытылса да, исемнәре Фәнис Яруллинның хәтеренә мәңгегә уелып калды», – ди шагыйрьнең хатыны Нурсия ханым. Урын өстенә калган Фәнис өчен белем илен киңәйткән, яңа офыклар ачкан, иңнәренә канат куйган, яшәү көчен, тормыш тәмен табарга ярдәм иткән остазларга шагыйрьнең бөтен хөрмәте шигырь юллары булып кәгазьгә төшә:

Килгән чакта башка авырлык,
Җитми калса көч йә сабырлык...

Бу сүзләргә, әлбәттә, лаек булырга кирәк. Моны дәлилләп, мөхтәрәм укытучылар – Наилә ханым, Гөлчәчәк ханым лаеклы ялга чыкканнан соң да Фәнис Яруллин янына барып йөрүләреннән туктамыйлар. Игътибар күрсәтеп, ел саен туган көне белән котларга да килә алар шагыйрь янына... Гади укытучы дип кенә әйтеп буламы соң мондый кешеләргә?!

...Ә Миңгол Галиевнең консерваториядә укуын тәмамлап йөргән чагы. Укытучыларга багышлап язылган җырны беренче тапкыр газета битендә күрә ул.

– Авторлары да кем бит әле! Гаҗәеп язмышлы шагыйрь Фәнис Яруллин, ачык күңелле, юмор хисле, талантлы, атаклы композитор Әхмәт абый Хәйретдинов! Җырны иң беренче булып мин башкардым. Аңа кадәр шагыйрь Зөлфәт сүзләренә Фәрит Хатипов иҗат иткән искиткеч «Һаман яратам» җырын башкарып, халыкка танылган идем. «Иң гүзәл кеше икәнсез» җырын башкара башлагач, «Бу теге «Һаман яратам» егет бит!» дип таный торганнар иде. Берничә елдан соң җырны укытучылар көне уңаеннан 1978 елда радиода яздырдык. Баянда Фәнис Гыйльметдиов уйнады. Фәнис аны шулкадәр матур уйный иде, гүя җырның беренче аккордларыннан ук укытучыларга хөрмәт яңгырый... – дип искә ала Миңгол абый.

Укытучылар турында – укытучы... Бәлки, үзе дә остазлык юлыннан атлап барганга, бу җырны бер күрүдә ошаткандыр Миңгол Галиев. Үзен дә бу һөнәргә этәрүче укытучысын да, аңа әйткән һәр сүзен дә ачык хәтерли:

– 10 нчы сыйныфта укыган вакытта тәнәфестә чабып йөргән җиремнән укытучым туктатып: «Миңгол, кем булырга уйлыйсың?» – дип сорады. Уйлап та тормыйча: «Укытучы!» – дип җавап бирдем. «И-и-и, ну түлке әйтмәде дип әйтмә аннары», – дигән иде. Еллар узгач кына бу сүзләрдә никадәр мәгънә барын аңладым...

Уильям Шекспир трагедиясенең ни катнашы бар бу җырга, дисезме? «Ромео һәм Джульетта» операсын тыңлаган Миңгол Галиев Монтекки һәм Капулетти гаиләләре арасындагы низаг аркасында һәлак булган ике яшь йөрәк трагедиясен күңеле аша үткәрә. Ике гашыйкның тормыш белән саубуллашкан мизгелендә яңгыраган йөрәк өзгеч бормалы ноталарны Миңгол Галиев «Иң гүзәл кеше икәнсез» җырына кушып җибәрә. Әйе! «Күңелебезгә ак нур сипкәнсе-е-е-ез» дип җырлаган вакытта Италия авазлары кушылып, гүя үзәк өзгеч тирән мәхәббәт хисләре чыгарга тиеш! Җырның бу өлешенә әнә шулай Миңгол абый үзенең укытучыларына карата тирән хөрмәтен салып башкара... Диләрә Юнысовнаны, Сания апаны, Шәмсенур апаны күз алдына китерә ул җырның шушы урынында...

Һәр авазга әһәмият сала Миңгол Галиев. Калын, ачу тоташ көр тавыш белән җырлаучыларны ишетсә: «Нигә укытучыңа ачуланган кебек җырлыйсың?» – дип шелтәли. Ә үзе гомере буе яшьлек авазы белән башкара ул җырны. Фәнис Яруллин да авыр халәтендә йөрәгеннән чыккан рәхмәтен салган бит бу сүзләргә! Укытучыларга багышланган җырны фәкать шулай башкарырга кирәк!

Укытучыларга мәдхия булып яңгыраган бу җырдан Миңгол абыйның методикасын бөтен дөньяга таныткан аваз барлыкка килүе аерым игътибарга лаек. «Италия һәм рус вокал мәктәбенең камилләшкән юлы буларак, авызны зур ачмый гына иң яраткан кешең белән сөйләшкән хистә җырлау», – дип атый аны Миңгол Галиев үзе. Төрле илләрдә чыгыш ясаган вакытта аның бу осталыгына таң калалар. Бу – «Иң гүзәл кеше икәнсез» җырыннан башланган тәҗрибәнең дәвамы була.

– Укытучылар конференцияләрендә дә еш булырга туры килә. Кая гына барсам да, «Иң гүзәл кеше икәнсез» җырын башкарыгыз әле, дип үтенәләр. Укытучыларга әйтәм, без иң бәхетле кешеләр бит, дим. Алар моңсу гына елмаялар... Гомеребезне балалар тәрбияләүгә багышлап, күпме вакытыбызны, күңел җылыбызны, игътибарыбызны аларга бирәбез. Укып чыгып, кеше булгач та укучыларыбыз безне һәрвакыт рәхмәт белән искә ала. Без шуның белән бәхетле!

Җырны тыңлар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.



Фото: Зөфәр Бәшировның «Онытылмас йөзләр» фотоальбомыннан

УРАЛ ТАУ УРТАСЫНДА



Лилия
ФӘТТАХОВА

Бу сәфәргә очраклы гына чыгып киттем мин. Хәер, бу тормышта бер генә очраклылык та очраклы түгел, диләр анысы... Узган ел Урал таулары башланган якларда йөреп кайткан идем, быел Урта Урал–Көңгер маршрутын тәкъдим итүче турны күреп алдым. Икенче көнне инде биштәрне тутыру эшенә дә керештем. Кыска вакытлы сәяхәт бит: җомга көн кич китәсе – дүшәмбе иртән кайтасы. Хәзер андый «ял көннәре турлары» дип аталган турлар күп икән. Түләү, поход өчен кирәкле әйберләрне арендага алып тору – шулай ук биш минутта хәл ителде. Рәхмәт, интернет! Шунда ук сәяхәткә җыенучы ватсап төркемгә керттеләр: Чаллыдан баручы юлдашлар белән танышырга да өлгердек.

Шул рәвешле 36 кешелек зур гына төркем белән Пермь якларына юнәлдек. Дөресен әйтим, ялның «актив туризм» дигән форматын беренче тапкыр сайлавым иде. Безне – Чаллы, Алабуга, Түбән Камадан баручыларны – Казаннан килүче автобус кичтән юл уңае алып китте. Иртән инде Көнгер шәһәрендә идек.

Туристларны дөньяның төрле якларыннан үзенә җәлеп иткән бозлы мәгарә – без күрергә теләгән төп табигый һәйкәл иде. Дөньяның дим, чөнки Виктория Руффо кебек танылган шәхесләр дә булган биредә. Ә кайчандыр маршал Жуковның килүе мәгарәне утлы иткән. Чын мәгънәсендә. Сөртенеп егыла язгач: «Сугышта җиңдек, ә үзебезнең хәерчелекне һаман җиңә алмыйбыз», – дип әйткән, имеш.

Көнгер мәгарәсенә керер алдыннан гына «Ермак авылы» дигән юлкүрсәткечне күреп аптырап калдым. Баксаң, Себер ханлыгын яулаучы данын алган Ермак, легендалар буенча, биредә кышлаган. Сылва белән Чусовая елгаларын бутаган, имеш. Бер мәгарәдә табылган ике зур ядрәне шул заманнан калган, диләр.

Ә мәгарә бик үзенчәлекле. Аны дөньяга танытырга тырышкан Александр Хлебниковның да язмышы кызыклы гына. Яшьтән сәяхәтләр турында хыялланган егет Япония, Америкаларга барып җиткән. Америкадагы Мамонтлар мәгарәсен күргәннән соң, үз ягының Көнгер мәгарәсен дә кешеләр өчен ачасы килгән. 1914 елда аны унике елга арендага алгач, бөтен гомерен шуңа багышлаган: юллар салдырган, тау куышларын чистарттырган, кайвакыт үзе үк юл күрсәтүче булып та йөргән. 70 яшендә үзеннән 45 яшькә яшьрәк кызга өйләнеп, өч бала атасы булгач та, мәгарәне таныту эшен тормышының төп миссиясе дип саный ул. Без яктыртылган тау куышлары аша үттек. Кайчандыр утлы кисәүләр, шәмнәр яктырткан бу юлны. Кайвакыт Хлебников шаярткалап та алырга яраткан: утларны сүндергән. Безгә дә бер генә минутка дөм караңгыда калырга туры килде. Дөм караңгының нинди икәнлеген

Пандемиядән соң мондый сәяхәтләргә гаилә белән йөрүчеләр күбәйгән икән.

әлегәчә белмәгәнмен икән... Яктылык нурының әсәре дә булмаган җирдә озаграк торсаң, вакыт төшенчәсе юкка чыга, ди гидыбыз. Аеруча тәвәккәл кешеләр өчен махсус «Караңгылык белән сынау» дип аталган экскурсия дә бар икән биредә. Караңгылык, тынлык һәм син! Кеше үз-үзен ишетә башлый, хәтта комплексларыннан да котыла икән. Онытылмаслык кичерешләрдер, мөгаен.

Данте тау куышы, Романтиклар тау куышы, Җәһәннәм уты тау куышы... Биредә 48 тау куышы бар. Аларның кайберләренә шундый сәер исемнәрне Хлебников үзе биргән.

Куышлар төрле. Өч төрле климат шартлары булган сирәк мәгарәләрнең берсе икән Көнгернең боз мәгарәсе. Кышкы бәсле иртә кебек челтәр-челтәр кар бөртекләре белән капланган өлеше дә, тып-тып тамчы тамып торган куышлары да, хәтта тереклек булган өлеше дә бар аның.

Ярыклардан агып кергән су мәгарә эчендә нечкә генә боз сөңгесе булып та, зур-зур колонналар рәвешендә дә катып калган. Сталагмитлар, сталактит, сталагнатлар – биредә сезонлы күренешләр.

Быел гына Абхазиядәге Яңа Афон мәгарәсен күрергә туры килгәнгә, аерма бик тиз күзгә ташланды: анда алар минераллардан ясалган – кальцитлар, биредә исә барлык сыннар да катып калган судан хасил булган.

Һәр тау куышы турында диярлек риваять-легендалар бар.

Хәрабәләр тау куышы уңаеннан да шундый тарих бар. Имеш, җир астында күз күрмәгән җанвар яши. Мамонт! Ул үткән юлларда өем-өем булып ташлар, чокырлар кала. Халык телендә йөргән бу сүзләрне ишетеп алган тарихчы Василий Татищев (Пермь, Екатеринбург шәһәрләренә нигез салучы да, диде гидыбыз) бирегә килә һәм бу табышмакның җавабын әйтә. Тау токымнарының суда эрүеннән барлыкка килгән алар: карст дип атала бу күренеш. Унике мең еллар элек Сылва елгасының сулары тау эченә үк үтеп кергән һәм мондагы гипсны эреткән – тау куышларын барлыкка китергән. Хәзер дә ел саен язгы агымсулар 600–800 куб. метр эрегән гипсны агызып китә, шуңа күрә мәгарәләр һаман да әле кыяфәтләрен үзгәртеп тора икән.

Тереклек дигәннән, Хлебников крангониксы дигән сирәк җан иясе дә яши биредәге күлләрдә. Бәпбәләкәй, 20–25 миллиграммлы, үтә күренмәле диярлек кыслачык икән ул. Пермь өлкәсенең «Кызыл китаб»ына кертелгән бу реликт бары тотрыклы салкын мәгарәләрдә, минералларга бай җир асты күлләрендә генә яши ала. Әлбәттә, без аны күрә алмадык.

Шулай ук биредәге җитмеш күлне дә күрмәдек. Туристлар өчен мәгарәнең өчтән береннән дә азрак өлеше генә ачык. Болай да җир асты патшалыгы өчен һич кирәксез яктылык белән җылылыкны алып керәбез без.

Күлләрнең дә кызыклы гына атамалары бар. Иң истә калганы – «Кызлар күз яше» күле. Асылташлар бүләк итүчегә генә кияүгә чыгачакмын дип сайланып утырган кызга нисбәтле ди бу исем. Ахырда бер яшь кенә, чибәр генә сәүдәгәр егет килеп чыккан да, бүләккә күмгән кызны. Ә никахны җир астында укырга булганнар. Ләкин... Ләкин... Яшь егетебез мәгарә эчендә карт һәм ямьсез мәгарә рухына әйләнмәсенме?! Ә ул бүләк иткән асылташлар гап-гади ташларга әверелгән дә куйган. Шуннан бирле яшь коя икән якты дөньяны күрүдән мәхрүм калган бу комсыз кыз. Тын калып тыңлап торсаң, чынлап та тып-тып шул яшьләр тамган кебек анда. Җир астында әкият тыңлау рәхәт икән ул...

Мәгарә эчендә шактый салкын. Бу хакта алдан ук кат-кат кисәткәннәр иде. Тауларда һава торышы

Моннан 300 миллион еллар элек бу таш кыялар диңгез төбендә булган.



■ Куркаклардан булмасам да, сукмак читендә үк – 120–150 метр түбәндә агып яткан елганы күргәч, аяклар бер мәлгә калтырап алды. Өстән караганда башлар әйләнеп китәрлек биеклек һәм... матурлык!



■ 70 метрлы Шайтан бармагы да шундый якын-да гына шикелле – мәгъруур гына кыя-таштан аерылып басып тора.

үзгәрүчән, җылы киемнәр, алмаш киемнәр турында онытмагыз, дип искәртеп торганга, әллә ни өшемәсәк тә, сәгать ярым минус ике градус чамасы салкында йөргәч, эчкә суык үтә башлады үзе. Әле бит фотога да төшерәсе килә, кул кесәдә генә тормый.

Ә урамда 27 градус эссе! Чыккач, биш минуттан кызыл борыннар үз хәленә кайтты, куртка, башлыклар салынды. Бәхетебезгә, сәяхәт дәвамында кояшлы матур көннәр торды. Яңгырлар башланса, без үтәсе юлларның яртысы да үтелмәс иде, мөгаен.


Юллар дигәннән... Соңгы тапкыр кайчан бу кадәр күп йөрдем икән? Искә төшерә алмадым. Актив туризм шул бу! Ярый әле озаклап уйларга вакытым булмаган, тәвәккәлләгән булыр идемме икән?

Көңгердән соң юлыбыз Усьва бистәсе тирәсендәрәк тукталды. Биредә палаткалар кордык. Түбән Кама кызы Катя да, мин дә гомеребездә бер тапкыр палатка корып карамаган кешеләр булсак та, бераз як-якка карангалап торгач, ул эшнең дә җаена төшендек. Урнашып алгач, өй салуның ние бар, мүклисе дә чүтлыйсы кебегрәк булды ул. Хәер, теләсә кайсы вакытта булышырга әзер сәфәрдәшләр кыен хәлдә калдырмас иде анысы – моңа һич тә шигебез булмады. «Общак» әйберләрен ташыганда ук күренде инде ул.


Учакта, зур казанда пешкән тәмле пылауны сыпыртып куйгач, кашык-тәлинкәләрне елгага төшеп юып менгәч (цивилизация шәһәрдә калды!), Усьва баганалары дигән җиргә җыена башладык. Бигрәк тә Шайтан бармагы дигәнен күрәсе килә иде.

Биш чакрымлап барасы һәм тауга күтәреләсе, диде инструкторларыбыз. Нәрсә инде ул биш чакрым, диештек без. Нәрсә икәнлеген соңрак аңладык үзе... Яр буеннан, тармакланып беткән тамырлар чыгып торган сукмактан атлыйсы икән ул биш километрны. Сул якта ярты метрда гына елга ага. Дөрес, аның шаулавы гына ишетелә. Ул кайдадыр бик-бик түбәндә. Шуңа да шактый сак барырга кирәк. Аннары сукмак тигез яр буена алып төшә. Урыны-урыны белән чуерташлы, урыны-урыны белән тигез юлдан атлап барасың. Синең алда гаҗәеп пейзаж. Усьва баганалары, Шайтан бармагы!

«Время первых» кебек фильмның бер эпизоды ул, тагын шактый киноэпизодлар төшерелгән монда. Ә тау, үч иткәндәй, менгән саен биегәйгән кебек. Инде туктап-туктап ял итүчеләр дә күбәя бара. Мин юл башында ук «Колһуаллаһу»ны укый башлаган идем, тауга үрмәләгән саен, аны ешрак кабатлата башлады. Шушында хәтле килгәч, кире борылып булмый бит инде. Әнә алтмышны тутырып килгән Светлана ханым да калышмый әле. Ире белән Венециягә һәм Көңгергә барырга хыялланган булганнар. Ире яман чирдән китеп барган да ул берүзе генә уртак хыялларын чынга ашырып йөри... Шул рәвешле бер-берсебезне куәтли-куәтли, биштәрдәге суны ешрак йота-йота күтәрелә торгач, тигезрәк мәйданчыкка менеп җиттек. Тик бу әле безнең юлның ахыры түгел икән. Бераздан кыяга терәлеп үк салынган сукмактан бара башладык. Менә монысы экстрим, ичмасам! Бу куркыныч аралыкны да исән-имин узгач, тагын бер мәйданчыкка күтәрелдек. Ах та ух килеп тирә-ягыбызны күзәттек, фотоларга төштек. Ә Шайтан бармагына кадәр тагын ике чакрым бар икән әле! Ул арада эңгер-меңгер җитте, күз бәйләнә башлады. Шайтан бармагына кадәр барып тормаска булдык: куркыныч. Тауларда кояш баешын күзәттек. Шул ук юлдан ничек төшәсе булыр дип кот очып торганда, инструкторыбыз безне бераз әйләнечрәк, ләкин упкыннан ераграк, куркынычсызрак сукмак белән алып китте. Һәрберебезнең



■ Шайтан каласын хәзер күбрәк Таш кала (Каменный город), диләр. Халык телендә Ташбакалар дигән атамасы да бар икән. Таш калада узган өч сәгать – сизелми узган вакыт булды. Әллә нинди рәвешләрдә катып калган зурзур ташлар арасыннан тар урамнар уза, тыкрыклар, хәтта шәһәр үзәге дә бар кебек.



маңгаенда фонарь. Светлана безне беренче мәйданчыкта каршы алды (ул тар сукмактан өскә үк менеп тормаган: һәркем үз мөмкинлекләрен чамалый монда).

Кайту юлында, шулай ук кыр казлары кебек тезелешеп, бер-беребездән калышмый атларга тырыштык. Шактый юлны тар сукмактан узасы бар бит әле! Мәскәүдән үк килеп кушылган Оля җырлар кушып җибәрде. Арып-талып, ниндидер зур эш башкаргандай, канәгать калып кайтып аудык лагерьга. Анда инде учак янында тәмле сый көтә, теләүчеләргә – мунча. Поход мунчасы! Ул яр буена ук куелган палатка эчендә. Чыгу белән елгага чумасың. Ә аннары учак тирәсендә гәпләшеп утыру, гитара, җырлар... Дөрес, монысына бөтен кешенең дә хәле калмаган иде инде.

Ә берничә сәгатьтән иң-иң түземнәр шул ук Усьва баганаларына, кичтән барып җитә алмаган, ләкин кызыктырып торган Шайтан бармагына таң каршыларга кузгалды. Мактана алмыйм: мин алар арасында юк идем.

Бу сәфәргә чаклы трекингның нәрсә икәнлеген дә белмәгән кеше идем. Усьва аша асылмалы күпердә, «Бәхет монда» дигән язу торган тауларда җәяү йөреп кайткач, көннең икенче яртысында Шайтан каласына юл тоттык. Моннан 300 миллион еллар элек бу таш кыялар диңгез төбендә булган. Ул кыялар Зур Ташбака, Канатлы Сакчы кебегрәк шагыйранә исемнәр белән аталган. Нәкъ шул кыяларга менеп фотога төшәсе килә туристларның. Куркыныч, әлбәттә, ләкин бик матур.

Һәм тагын бер риваять. Кайчандыр биредә гаҗәеп бер шәһәр булган. Ләкин бу матурлыкны идарәченең бердәнбер сукыр кызы гына күрә алмаган, ди. Кызны терелтәм, дип ышандырган сихерче явыз булып чыккан. Кызның күзләре ачылуга, башка кешеләр һәм йортлар ташка әйләнгән, имеш. Берьялгызы шул мәхәббәт һәм кырыс матурлык янында калган ул.

Биредә үзенә бер аура бар кебек. Монда таш кыялар өстендә үскән агачларны, аларның ташларны кочып шуышкан тамырларын күреп шаккатасың. Шул кырыс матурлык әллә кай ягы белән үзенә тарта. Бигрәк тә август, сентябрь айларында килүчеләр күп икән.

«Иң ошаганы нәрсә булды?» – дигән сорауга безнекеләрнең 62 проценты нәкъ шул урынны атады. Безнекеләр, дим, чөнки шул берничә көндә дуслашып, тату командага әйләндек. «Мондый турларга әйбәт кешеләр генә йөри», – дип көлә инструкторыбыз. Арада кемнәр генә юк: провизор, аудитор-программист, укытучы, акушер-гинеколог, инженер, редактор, эшмәкәр, студент...

Автобуста минем белән янәшә утырып барган Диана ханым – марафончы. Сәяхәт барышында гаҗәеп фотолар гына төшереп калмады, акварель карандашлар белән картиналар ясарга да өлгерде ул. Актив туризмны күптәннән яратып өлгергән кешеләр арасында Чаллы кызы Резеда да бар. Таганай, Зураткүл... Ул инде Уралның төрле табигый һәйкәлләрен күреп өлгергән. Шуңа күрә ял көннәре турларында булып, дүшәмбе иртән эшкә чыгу аның өчен дә яңа күренеш түгел икән. Казан асып, безне тәмле ризыклар белән сыйлаучы инструкторыбыз Диләрәнең дә банк хезмәткәре булуын белеп гаҗәпләндем. Менә бит, дөньяга офис тәрәзәсеннән генә карамыйча яшәүнең матур үрнәге! Гаҗәеп зур, чиксез матур дөнья бит ул! Күреп, сокланып, башкаларны да шул матурлык белән таныштырып өлгерергә генә кирәк.

P. S. Тагын шундый турларга барыр идемме? Әйе! Ару-талчыгу, куркулар узды, ә эмоцияләр – һаман да бихисап! Димәк, алда әле Төньяк Урал, Алтай, Байкал...

«МӨЛАЕМЛЫК – ХАТЫН-КЫЗНЫҢ ИҢ ЗУР ӨСТЕНЛЕГЕ»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

Марсель ӘХМӘДУЛЛИН,
тамада;
гаилә стажы – 13 ел;
өч бала әтисе.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Соңгы арада хатын-кыз өчен бик тә дефицит булган бер сыйфатка игътибар итә башладым – ул да булса аның мөлаемлыгы. Хәзер хатын-кызлар аеруча да мөстәкыйльлеккә омтыла: ирләрдән дә уздырып, алардан да ашыгып дөнья көтә. Һәм шуңа күрә үзләренә табигать тарафыннан бирелгән йомшаклыкны, нәфислекне, табигый матурлыкны җуеп бара. Әмма ир-атны көч, гайрәт, лидерлык сыйфатлары белән гаҗәпләндереп тә, сокландырып та булмый. Безгә үзебездә булмаган сыйфатлар кадерлерәк. Менә шуның өчен дә хатын-кызның мөлаемлыгына, тыйнаклыгына, нәфислегенә моданы кайтарасы килә. Бу – аларның иң зур коралы.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Була гына түгел, аның үзенә генә хас бик күп үзенчәлекләрен гафу итәргә кирәк. Һәм шуларга күз йомган очракта гына уртак тел таба алабыз. Изге китапларда да язылган: хатын-кыз ир-атның кабыргасыннан яралган. Ә кабырганың кәкре булуын барыбыз да беләбез. Әгәр аны турайтырга теләсәң – сынганын да. Шуңа күрә ничек бар, шулай кабул итәргә тиешбез. Инде төгәлрәк тукталсам, хатын-кызның бераз нәрсәнедер уйламыйчарак әйтүен, ашыгыбрак сөйләвен, ашыгыбрак нәтиҗәләр чыгарып куюын, эмоцияләргә бирелеп, башта ярсып алуын... Шушыларга күз йомып сабыр итә алсаң, барысы да үз урынына басачак.

3 Ә нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Сорауның бу рәвешле куелышы күңелемә ятып бетми... Чөнки кайчак «менә шулай беркайчан булмам, эшләмәм», дип әйткән очракта, киресенчә, тормыш нәкъ шундый ситуацияне каршыңа чыгарып куя. «Сүзеңдә торырсыңмы, тикшереп карыйк алайса», – дигән кебек... Шуңадыр бу сорауга җавап бирәсем килми. Аннан кем инде без шулкадәр бер-беребезне гафу итмәскә?! Беребезгә дә мондый хак-дәрәҗәләр бирелмәгән. Алай уйлау тәкәбберлекне арттырадыр кебек тоела миңа.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Никахта ир белән хатынның дус булуы, миңа калса, тандем өчен бик кирәкле бер шарт. Ир-ат өчен хатын-кыз кем ул дигән исемлек шактый озын: партнер да, хатын да, хуҗалык эшләрен алып барырга ярдәм итүче дә... Һәм, әлбәттә, дус та. Дус булмаса, баланска бер хилафлык килер – нәрсәдер җитмәгән кебек булыр иде. Хатыным белән безнең дә бер-беребездән яшерен серләр юк. Арабызда дуска хас булган бөтен сыйфатлар да бар.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Энҗе белән уртак танышыбыз таныштырды. Бу минем кызлар белән беренче чын-чынлап очрашуым, кыз белән егет булып беренче йөрүем иде... Әйе, тәкъдим ясаган көнемне хәтерлим. Туган көнем иде ул. Әллә нәрсә уйлап чыгармадым – мин андый романтик кеше түгел. Кремльнең Спас манарасы янына алып бардым да, бөтен Казан күренеп торган калкулыкта аңа роза чәчәге бүләк иттем. Ә чәчкәнең таҗына йөзек куйдым... Ул: «Мин риза!» – дип җавап бирде. Туган көнемә иң зур бүләк шушы булгандыр. Моннан да зур бүләк алганым юк иде әле. Хәер, аннан соң кызларыбыз, улыбыз туды, аларны да бүләк итеп кабул иттем. Әмма яхшы хатын барыбер зуррак бүләктер: балалар үсә дә тарала, ә гомернең уртасын да, көзен дә җәмәгатең белән уздырасың.

Никахыбыз Колшәриф мәчетендә узды. Кыз сорарга барганчы, әтисе белән күрешеп сөйләшкән идем инде: кыз бала өчен ата кеше җаваплы икәнен белә идем. Ә туебызны хәзер шаяртып: «Китапханәдә булды», – дим. «Казан» милли-мәдәният үзәгендә узган иде ул. Хәзер бит анда Милли китапханә. Зур залда, купшы итеп үткәрдек – яшь чакта күңел пафослык та тели. Хәмерсез узды – шул ягы белән ул чакта үзенчәлекле булды. Хәер, ун ел алдан апаларның туе да эчемлексез булган иде инде безнең. Туйны Данир Сабиров алып барды. Эштән «Татарстан–Яңа гасыр» телевидениесе җитәкчеләре, дуслар, туганнар килде. Матур хатирә булып әле дә күңелдә саклана ул. Туйлар алып баруга күчүемә дә

өлеш керткәндер. Өйгә кунак килгән саен, туебызның видеосын карый-карый Данирның текстын ятлап бетердем. Үзем алып бара башлагач, беренче мәлдә урыны-урыны белән аның шигырьләрен сөйли идем әле. Бүген булса, никахыбызны да, туебызны да бергә кушып кына уздырыр идем. Никахта мәгънәле, кирәк сүзләр күп әйтелә – аны күбрәк кешегә күрсәтер идем. Ә загска барып теркәлү – рәсмилек кенә, мин аны бәйрәм итүне әле дә бик аңлап бетермим.

6 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Дөнья, чыннан да, шундыйга китте. Әмма хатынның күбрәк акча алып кайтуы, миңа калса, табигый күренеш түгел инде. Зурлап сөйләшә торган тема да түгелдер. Тик шулай килеп чыга икән, нишләтәсең. Хатын-кызның өйдәге зур миссиясенә каршы килмәгән очракта гына риза булыр идем мин моңа. Ул бит өйдә ниндидер зарядка, аккумулятор функциясен үти: бөтен кешегә җылылык тарата. Өйнең микроклиматы булып тора. Акча эшләү аркасында бу вазыйфасына хилафлык китерә икән, ул тапкан малның кирәге ташка үлчим генә.

7 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Бераз сәеррәк хәл, күңелгә бик ятмый, әлбәттә... Әмма шулай кирәк дип тапкан икән, ул аны ачыктан-ачык белдермәскә тиеш инде. Турыдан ярып әйтсә, бөтен эшне бозачак кына. Хатын-кызлар безгә караганда күпкә иҗадирак, аларда зирәклек, хәйлә дә җитәрлек, шуңа күрә бу очракта да читтән, ерактан урап килеп, үзләренә генә хас тактиканы куллансалар дөресрәк булыр. Кызыклы итеп, сиздермичә генә. Һәм шуннан соң ир-атның да аңа карата ниндидер хисләре уянып, ул беренче адымны ясарга мөмкин. Һәм күп вакыт: «Беренче адым минеке булды!» – дип уйлаячак әле ул. Мин үзем күптән безне хатын-кызлар сайлый дигән фикердә. Ул бит үзенең ана булу вазыйфасын да күз алдында тотып сайлый. Үзе моны белмичә дә – аң төпкеле белән.

8 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Беренче чиратта төплелек, ышанычлы булу җәлеп итә торгандыр. Ир-атның саклаучы, терәк булуы кирәктер. Бездә әтиләр ягымлылыгын, әтиләр җылысын табуы да мөһимдер алар өчен. Ә йөз-кыяфәт икенче генә түгел, өченче, дүртенче урындадыр. Алда санаган шушы сыйфатлар теләсә кайсы хатын-кызны ир-ат артыннан барырлык һәм хәтта декабрист хатыны итәрлек сыйфатлардыр.

9 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Миңа калса, болар икесе ике төшенчә: артык чибәр – бер әйбер, артык көчле – икенче. Әлбәттә, болар бер үк хатын-кызда ук та булырга мөмкин. Артык чибәрлекне куркыта дип әйтмәс идем, әмма шүрләтә. Бу ир-ат өчен өстәмә йөктер. Артык кыйммәт машина кебек инде ул: сатып аласың икән, аны карарга, тотарга да әзер булырга кирәк. Ә хатын-кызның үзе өчен ул чибәрлек – бәхетле булырга бер киртә кайчак. Өстәмә сынау чыганагы. Иң мөһиме – күңел матурлыгы дип саныйм. Чибәрлеккә бит күз тиз иярә – күрми башлый. Ә күңел матурлыгы гел сине иркәләп торадыр шикелле. Андый кеше янында агач күләгәсендә торган шикелле тыныч, рәхәт... Ә артык көчле хатын-кыз, юк, куркытмый. Әмма бу сыйфаты белән ул үзеннән ир-атларны этәрергә мөмкин.

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Нигә хатыным нәкъ менә мине сайлады икән дип уйлап куям еш кына. Нәрсәм белән җәлеп иттем икән аны? Кайчак сүзгә килгәндә карыйсың: без аның белән шулкадәр төрле. Әйткәнемчә, ир-атны бит барыбер хатын-кыз сайлый: читтән караганда гына без сайлаган, без танышкан кебек.

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны-туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Коткыга бирелеп, үземнең хаклы икәнемне беркайчан расларга җыенмыйм: бераздан барыбер йә ул кем хаклы, ә кем хаксыз икәнен аңлаячак, йә – мин. Андый ситуациядә юл куясың икән, тормыш шулай китереп чыгара – монысында юл куйган өчен икенчесендә ул сине өстенрәк итә. Шуңа күрә ситуация патшасы булырга җыенмыйм, омтылмыйм, җиңеләм. Һәм моннан бер читем дә кителми.

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...

– Хатын-кыз өчен көн саен ашарга әзерләүнең бик авыр мәсьәлә икәнен аңлыйм мин. Физик ягы гына түгел, интеллектуаль ягы да бар бит әле: көн туган саен: «Нәрсә әзерлим икән?» – дигән сорауга җавап эзли ул. Бик зур йөк бит бу! Без бу ягын уйлап бетермибез. Ә уйласаң, әллә нигә бер нәрсәгәдер заказ бирергә дә мөмкин. Җайлы бит! Үзеңә дә төрлелек була. Һәрхәлдә, мондый ситуациядә үземнең ярсып китеп, хакыйкатьне табарга теләп, кискен рәвештә ниндидер гамәлләр кылганым юк. Хатын-кызның ашарга пешерү миссиясе – аңа бирелгән өстәмә вазыйфа. Әгәр ул аны эшли икән, без аңа рәхмәт әйтәбез, юк икән, башка юлларны эзлибез. Ә үзем нәрсәдер әзерләргә? Авыррак сорау. Мин гомер буе хатын-кызлар янәшәсендә яшәдем. Әти гел эштә, өйдә әни, ике апа, әбиләрем бар иде. Мине аш-су тирәсенә якын җибәрмәделәр, шулай итеп, пешерергә өйрәнмичә калдым. Бик кирәк булса, башыңа төшсә, тотынасыңдыр, тик андый ихтыяҗ туганы юк әле. Инде ике кызым үсеп килә менә.

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Хатын-кыз дөньяга чыга башласа, подиумга чыккан кебек җыена, әзерләнә, шуңа соңга кала бит ул. Америкалылар бу мәсьәләгә бик җиңел карый әнә: анда хатын-кызлар кроссовки, джинсы чалбардан, бизәнмичә дә үзен рәхәт хис итә. Ә бездә хатын-кызларга – өстәмә таләпләр, өстәмә йөк. Һәм мин моны дөрес дип санамыйм: урамга ауга чыккан кебек артык киенеп-ясанып, бизәнеп чыккан хатын-кызга башка ирләрнең дә күңеле, күзе төшәргә мөмкин. Өендә иске халаттан йөргән хатыны ир-атка икенче сорт булып күренүе, ә урамдагылар өчен матур булып тоелуы бу очракта гаҗәп түгел. Хатын-кыз беренче чиратта ире өчен чибәрләнергә тиеш дип саныйм.

Тулысынча укыгыз »





Көз җитсә, без – ата-аналар «сезон башланды» дип уфтанучан. Кояшлы җәйдән соң салкын көзләрдә вирус ешрак йөри башлый. Ә алар күп һәм төрле инфекцион авыруларга сәбәпче. Шуларның берсе – мононуклеоз авыруы. Аны Эпштейн-Барр вирусы китереп чыгара. Беренче карашка ул салкын тиюгә охшаган. Шулай ук тән температурасы күтәрелә, тамак ялкынсына. Әмма мононуклеоз салкын тиюгә караганда мәкерлерәк. Әлеге авыру турында Республика балалар клиник хастаханәсенең изоляция-диагностика бүлеге мөдире, табиб-педиатр Лилия ЗЫЯТДИНОВА белән сөйләшәбез.

МӘКЕРЛЕ ВИРУС

Герпесвируслар киң таралган. Алар тын юллары аша организмга керә һәм гомерлеккә шунда кала. Гадәттә, лимфа, арка мие нерв төеннәрендә яшиләр. Ә лимфа системасы организмда төрле җирдә бар: борын-йоткылык, муен, корсак куышлыгында. Мононуклеоз кискен инфекция авыруын теләсә кайда йоктырырга була. Вирус һава буенча күчә. Бала организмында авыруга каршы тору үзенчәлеге кимесә, ул «баш калкытырга» мөмкин. Әлеге авыру бизгәк тоту, лимфа төеннәренең зарарлануы, һәм кан составының үзгәрүе, тонзиллит, бавыр һәм талак зураюы белән характерлана. Вирус канда циркуляцияләнүче В-лимфоцитларны зарарлый һәм шул рәвешле күзәнәк һәм гумораль иммунитетны боза. Статистика буенча, малайлар, кызларга караганда, ике тапкыр күбрәк авырый. Инкубация чоры – 4 көннән 15 көнгә кадәр, хәтта бер айга сузылырга мөмкин. Бала кечерәк яшьтә авыруны җиңелрәк кичерә. Мононуклеоз белән гадәттә кышкыязгы чорда авырыйлар, бу – әлеге чорда иммунитет кимү белән бәйле.

Беренче ярдәм – тән температурасын төшерү, су күп эчертү, төрле антисептиклар белән тамакны чайкау. Кичекмәстән табиб чакыртырга кирәк. Төгәл диагнозны бары тик белгеч кенә куя ала. Моның өчен берничә диагностика алымы бар: мононуклеарларны билгеләү өчен, гомум кан анализы, ПЦР, ИФА тапшырырга кирәк. Табиб клиник билгеләрне дә караячак. Мононуклеоз вирусы яман шеш авыруларын китереп чыгара торган активлыкка ия. Шуңа күрә тикшеренүләр вакытында кан күрсәткечләренә үтә игътибарлы булу зарур.
Онколог консультациясе кирәк булырга мөмкин. Бу авыруны дәвалаганда вируска, бактериягә каршы терапия кулланыла. Шулай ук табиб сулыш алуны җиңеләйтә торган препаратлар киңәш итәр. Авыру, нигездә, җиңел уза. Өзлегү бик сирәк очракта гына була. Кискен фаза ике атнага сузыла. Берничә атна хәлсезлек сакланырга мөмкин. Мононуклеоз белән авырган бала алты ай буена табиб күзәтүенә алына.

✓

Профилактика

- Вируслы инфекция авырулары таралган вакытта җәмәгать урыннарында йөрүне кичектерергә.
- Кулны еш юарга.
- Битлек киеп йөрергә.
- Бүлмәне еш җилләтергә.
- Саф һавада йөрергә.
- Ашауны витаминнар белән баетырга.





МОНЫ БЕЛҮ МӨҺИМ

Җирдә яшәүчеләрнең 90 проценты 25 яшенә җиткәндә Эпштейн-Барр вирусын йоктыра. Авыру үзен сиздертмәскә дә мөмкин.

Фото: www.pexels.com



Авыру билгеләре:
- температура күтәрелү;
- тамак ялкынсыну;
- лимфа төеннәре зураю;
- тын алганда гырылдау;
- борын-йоткылык миндаль сыман бизе зураю;
- тәнгә тимгелләр чыгу;
- эч авырту;
- кайбер чакта укшыту.





Эч мускуллары диастазы диагнозы белән бик күп хатын-кызлар очраша, бигрәк тә авырлы вакытта. Ул корсак куышлыгындагы вертикаль мускулларының аерылуыннан гыйбарәт. Эстетик яктан ямьсез булудан битәр, бу сәламәтлек өчен дә зыянлы. Казан федераль университеты клиникасының хирургия бүлеге табиб-хирургы Илфат ГАЛИЕВ диастазга китергән сәбәпләр, профилактика турында сөйли.

МУСКУЛЛАР АЕРЫЛУ

Диастазның төп билгесе – эч чыгып тору. Ул кешенең мускул-бәйләү аппараты анатомиясендә үзгәрешләр булу белән бәйле. Алгы корсак стенасы мускул җепселләре бәйләменнән тора. Корсактагы пресс әнә шул инде ул. Кендекнең сул һәм уң якларыннан ике вертикаль мускул сузылган. Алар үзара сеңер ярдәмендә бәйләнгән. Аны корсакның ак линиясе дип йөртәләр. Ул җепселләр бик яхшы сузыла. Әмма билгеле бер факторлар аркасында алар бик нык нечкәрә һәм тартылу үзенчәлекләрен югалта. Авырлы хатыннарның 60 проценты диастаздан җәфалана. Моңа хатын-кызның артык таза булуы, корсак мускулларының сәлперәюе, физик күнегүләр белән шөгыльләнмәве, яше, баланың зурлыгы, плацентада бала суы күп булуы сәбәпче. Корсакта туры мускуллар йөклелекнең 14 нче атнасында аерыла башлый һәм бала туганчыга кадәр дәвам итә. Гадәттә, бу үзгәрешләр физиологик дип санала һәм махсус дәвалау таләп итми. Статистика буенча, корсактагы ак линия бала тапканнан соң бер ел эчендә гадәти хәленә кире кайта. Әгәр дә инде диастаз һаман саклана икән, белгечкә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Табиб диагнозы корсакны капшап һәм УЗИдан карап куя. Моның өчен гади генә тест та бар. Каты өслеккә ятыгыз һәм аякларыгызны тездән бөкләгез. Бер кулны баш астына, икенчесен кендектән бераз гына өстәрәк – ак линиягә куярга кирәк. Корсак мускулларын киерелдерми генә күкрәк куышлыгын күтәрегез. Шул вакытта бармак очлары белән мускуллар арасындагы аерылган урынны табарга кирәк. Мускулларның аерылуы кендек белән түш сөяге очы арасында нык сизелә. Әгәр дә анда ике бармак сыярлык урын була икән, димәк, сездә диастаз. Вакытында дәваламасаң, бүсер чыгу, эч катып, эчәклек үткәрмәүчәнлеккә әйләнү, умыртка баганасы кәкрәю куркынычы бар. Әгәр дә мускуллар арасындагы аерылу 8 сантиметрдан артса, операция юлы белән генә дәваланырга мөмкин.

Диастазга китергән сәбәпләр

- йөклелек һәм бала табу;
- яшь үзгәрешләре;
- тазару;
- аз хәрәкәтләнү;
- һәрвакыт утырып эшләү;
- авыр атлетика белән мавыгу;
- корсакның эчке басымын арттырган хроник авырулар.

Клиник билгеләре

- прессны киергәндә кендек тирәсендә эч ярым түгәрәк булып калка;
- корсак куышлыгы авырта, бигрәк тә хәрәкәтләнгәннән соң;
- органнар урыныннан күчә;
- корсакның алгы стена тукымасы нечкәрә;
- укшыта, эч газлана. эч ката.

Диастазны коррекцияләү өчен махсус күнегүләр

1. «Дүрт аяклап» басабыз. Сулыш алганда арканы өскә таба түгәрәкләндерәбез, башны аска иябез. Сулышны чыгарганда – киресенчә.
2. Аркага ятабыз. Аяклар тездән бөгелгән. Оча сөяге тирәсен күтәрәбез һәм төшерәбез.
3. Шул ук күнегүгә аякларны да кушабыз. Оча сөяген күтәргәндә сул һәм уң аякларны да чиратлаштырып өскә таба күтәрәбез.
4. «Дүрт аяклап» баскан килеш чиратлаштырып аякларны күтәрәбез.

Профилактика

- авыр әйберләр күтәрмәгез һәм ташымагыз;
- урыныгыздан кузгалганда кулыгызга гына таянып торыгыз;
- утырганда һәм басып торганда нагрузканы дөрес бүлегез;
- корсакның ян мускулларын ныгыту өчен, күнегүләр комплексы эшләгез.

Ә диастаз булганда мускуллар өчен физик күнегүләр ясау тыела;
- ортопедик пояслар йә тейп-лента кулланыгыз.



БАКЧАНЫ КЫШКА ӘЗЕРЛИБЕЗ

Октябрь – бакчаларның бушап калган мәле. Кишер-чөгендерләр алынган, куаклар киселгән, алмалар җыелган. Шулай да эш бетте дияргә иртәрәк. Бакчаны кышка әзерләп куярга кирәк хәзер: җир эшкәртергә, сарымсак утыртырга, виноград ботакларын кисәргә...

Җирне кышка әзерлибез

Яз көне бакчагызның яңа сезон ачып җибәрәсе бар. Кышын хәл җыеп, тукланып, дөрес ял итсен дисәгез, җирне эшкәртеп калдырырга ашыгыгыз. Җирне 15–20 сантиметр тирәнлектә казып чыгыгыз. Бу эшне көздән башкару зыян салучы бөҗәкләрнең кыш чыгуларына комачаулый, чүп үләннәренең тамырлары алына, орлыклары тирән күмелә. Казыган вакытта ашлама кертсәгез, тагын да яхшы булыр. Кыш буена ашлама җирдә тигез таралып, үсемлекләр өчен тагын да күбрәк файда китерәчәк.

Яз көне утыртасы үсемлекләрне төрле авырулардан саклар өчен, туфракны көздән үк эшкәртергә кирәк. Җәй көне яшелчәләрегез зыян күрмәгән булса да, барыбер профилактика үткәрү зарур. Моның өчен составына бакыр кергән препаратлар кулланалар – җир казыган вакытта сибеп калдыралар. Ашлама кебек, ул да кыш буена файдасын китерер, яңа бакча сезонында әҗерен күрерсез.



Сарымсак утыртабыз

Сарымсак утыртуның төгәл вакыты юк. Моның өчен сентябрь ае да, октябрь дә кулай. Барысы да һава торышына бәйле. Температура 10 градус җылылык билгесендә тотрыклылануга, сарымсакны утыртырга кирәк. Җир туңганчы ике-өч атна вакыт калырга тиешлеген дә исәпкә алыгыз. Шундый шартларда утыртылган сарымсак тамыр җибәрергә өлгерә, ләкин шытып чыга алмый кала.

Сарымсакны борчак, томат, татлы борыч, кыяр, кабак үскән түтәлләргә утырту яхшы. Алардан соң җир сарымсак өчен кирәкле матдәләргә, дымга бай булып кала. Ә менә суган, бәрәңге, кишер, чөгендер үскән җир сарымсак өчен бөтенләй туры килми.

Сарымсакны биегрәк җиргә утыртып калдырырга тырышыгыз. Чөнки яз көне кар эрегәннән соң су эчендә утырып калган түтәлдә сарымсак черергә мөмкин.

Җирне бер ай алдан әзерләп куегыз. Яңа казыган түтәлгә утырткан сарымсак, җир утыргач, тирәндә калачак. Тишелеп чыгу вакыты да сузылачак.



Виноградны көздән киссәгез...

Виноградның яшь ботакларын кисеп тормасагыз, куакның бөтен көче шуларга китәчәк. Әлбәттә, уңыш бирүгә дә зыян килә. Виноград кыргыйланачак, җимешләре вак һәм ачы булып өлгерәчәк.

Виноград куагын яз көне дә, көз көне дә кисәләр. Көзен салкынайту сәбәпле, файдалы матдәләр тамырдан яфракларга таба түгел, киресенчә, яфраклардан, ботак очыннан аска таба төшә. Шуңа күрә көздән ботакларны кисеп алу нәтиҗәсендә куак файдалы матдәләр алырга өлгерми, дип саный кайбер белгечләр. Бу, үз чиратында, куакның кыш чыгуына йогынты ясарга, киләсе уңышка комачауларга мөмкин. Шушы сәбәпләрне исәпкә алып, куакны яздан кисүчеләр дә бар.

Виноград ботакларын көздән кисәргә уйласагыз, барлык нечкәлекләрен дә исәпкә алып эшләгез. Беренче чиратта, эшкә тотынганчы, виноград куагының барлык яфраклары коелып беткәнен көтегез. Сезнең төбәктә һава температурасы бер атна дәвамында 5 градустан күтәрелмәсә, виноградны кисәргә вакыт җиткән диган сүз. Әлеге эшне коры һава шартларында башкарыгыз. Киселгән ботаклар кибеп китәргә тиеш.

Фото: www.pexels.com

Бакчага йозак салганчы:

- Коегыз булса, аның суын тикшерегез. Суның тәме бозылган очракта аңа дезинфекция кирәк булачак.
- Бакча коралын – көрәк-сәнәкләрне, тырмаларны чистартып, кирәген майлап, сарайга җыеп куегыз.
- Барлык савытлардан, торбалардан, шланглардан суны агызыгыз. Бозланып каткан су пластик савытларны гына түгел, тимерне дә ярырга мөмкин.
- Өйнең, бакча йортының фундаментын тикшереп чыгыгыз. Ярылган җирләре булса, аларны ямарга кирәк, бу – йортны кимерүчеләр керүдән саклар.
- Янгын чыгуны кисәтер өчен, бакчаны яисә участокны яфраклардан, агач-ботак, утын калдыкларыннан чистартыгыз.
- Подвалда яшелчә, җиләк-җимеш сакларга уйласагыз, аларны яхшылап карап, бозыла башлаганнарын алып ташлагыз.



ГУАША МАССАЖЫ

Ташлар ярдәмендә массаж – борынгы кытай медицинасы методикасы. Ташларның табигый булуы мөһим, чөнки алар билгеле бер температураны озак саклый. Роллер белән массаж ясау биттәге шешенү билгеләрен бетерә. Шуңа күрә аны эш башлаганчы салкында тотып торырга кирәк. Ә мондый массажның файдасы бик күп. Беренчедән, кан һәм лимфа әйләнешен яхшырта. Икенчедән, пластик массаж булып та тора. Дөрес ясаган очракта, әкренләп вак җыерчыклар языла. Өченчедән, ул – рефлекс терапиясе. Арганлык билгеләрен бетерә. Гуаша массажы техникасын матурлык буенча даими экспертыбыз, массажист Ләйсән САБИТОВА өйрәтә. Шунысын да онытмагыз, биттә бетчәләр йә зур миңнәр булса, аларга тияргә ярамый.

1

Массаж ясый башлаганчы умрау сөяге янындагы лимфа төеннәренә әкрен генә басабыз. Шул рәвешле лимфа агымын кузгатып җибәрәбез.





2

Массажлауны күкрәк өслегеннән башлыйбыз. Шәрә тәндә уртадан читкә таба роллер йөртәбез. Ике якка да 10–15 тапкыр ясарга кирәк.

3

Муенга ясаганда, калкансыман биз тирәсен читләтеп узыгыз. Роллерны муен кырыйларыннан, артыннан өстән аска йөртәбез.





4

Ияктән колакка таба йөртәбез. Биткә роллер белән артык басмагыз, һәм хәрәкәт тә бер якка гына булырга тиеш.

5

Шешенү күз тирәләрендә генә түгел, борын-авыз тирәсендә дә була. Чираттагы техника: бит тиресе тигез булсын өчен, авыз белән «О» хәрефе ясыйбыз да, роллерны борын тирәсеннән колакка таба йөртәбез.





6

Күз тирәсен массажлаганда исә каш астыннан – күзнең эчке почмагыннан тышкы почмакка, күз астында киресенчә йөртергә кирәк.

7

Каш арасын роллер белән астан өскә массажлыйбыз. Шуннан маңгайга күчәбез. Анда да хәрәкәтләр: астан – өскә һәм маңгай уртасыннан чигәгә таба.





8

Массажны роллер белән маңгайдан, биттән башлап умрау сөягенә кадәр йөртеп чыгу белән тәмамлыйбыз.



QR-код аша кереп, күнегүләрне видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Кабак кексы

Бу санybызның аш-су рубрикасына нәрсә әзерләргә кирәген көз үзе әйтеп бирде. Кемнән сорасаң да, бар кешедә дә бер җавап: кабактан уңдык быел! Машина арбасына төяп тә, көпчәк янына куеп чагыштырып та, өстенә утырып, арасына күмелеп төшкән фотолар да еш очрый. Шуңа күрә психосоматика буенча белгеч, сәләтле кондитер Ландыш МӨБАРӘКШИНА белән кабаклы сый әзерләргә булдык. Белгечлеге буенча инженер булса да, декрет ялында иҗатка тартылып, пешерү белән кызыксынып киткән ул. Үз пекарнясын ачкан хәтта. Хәзер Ландыш үз гаиләсе өчен генә иҗат итә. Еллар дәвамында берсеннән-берсе тәмле тортлар пешергәндә туплаган тәҗрибәсен үзенең шәхси инстаграм битендә укучылары белән дә бүлешә. Кабакны ничек сакларга кирәклеген дә Ландыштан өйрәник әле. Аннары кабак кексы пешерербез!



Кабак пюресы

- Кабакны кабыгыннан, эчендәге орлыкларыннан чистартып, шакмаклап турыйбыз.
- Табага салып, өстен фольга белән каплыйбыз да, 200 градуслы духовкага 50–60 минутка куябыз.
- Пешкән кабакны блендер белән изеп, әзер пюрены бәләкәй пакетларга салып туңдыргычта катырабыз. Соңыннан аны теләгәнчә кулланырга була.









Кирәк

Кремчиз өчен:

- 175 г каймаклы (сливочный) сыр;
- 1 йомырка;
- 30 г шикәр комы;
- 1/2 чәй кашыгы ваниль шикәре.

Камыр өчен:

- 175 г он;
- ярты чәй кашыгы сода;
- ярты чәй кашыгы камыр көпшәрткеч (разрыхлитель);
- 1/4 чәй кашыгы тоз;
- 1 чәй кашыгы дарчин (корица);
- 1/4 чәй кашыгы мөшкәт чикләвеге;
- 210 г кабак пюресы;
- 100 г көрән шикәр;
- 75 г шикәр комы;
- 120 г үсемлек мае;
- 2 йомырка;
- 1/2 чәй кашыгы ваниль шикәре.

Эш барышы

■ Кремчиз ясар өчен каймаклы сырны, шикәр комын (көрән шикәр кушсагыз да була), ваниль шикәрен бергә болгатабыз. Шикәре эреп беткәч йомырка салып туглыйбыз. Әзер кремны пакетка салып куябыз.

■ Йомырканы шикәр комы һәм көрән шикәр белән миксер ярдәмендә 3 минут тирәсе куе күбек барлыкка килгәнче күпертәбез. Калган ингредиентларны барысын да калак белән генә туглыйсы (бу мөһим!). Бисквит кабарып пешсен өчен шулай кирәк.

■ Ваниль шикәре кушабыз.

■ Кабак пюресы һәм үсемлек мае өстәп, барысын бергә калак белән болгатабыз.

■ Он, сода, камыр көпшәрткеч, тоз, дарчин, мөшкәт (мускат) чикләвеге порошогын берләштереп, камырга кушабыз. Барлык массаны яхшылап калак белән болгатабыз.

■ Кексны формалаштыра башлыйбыз. Камырның яртысын формага салабыз.

■ Пакетка салып куйган кремны ирекле рәвештә камыр өстенә салабыз.

■ Камырның икенче яртысын салып, кремны тулысынча каплыйбыз.

■ Кексны 170 градуслы мичтә 60 минут пешерәбез (фотодагы форманың диаметры 18 см). Кремы акмасын өчен, табынга суынгач кына бирәбез.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

PRESSA



Җәйге яшелчәле салатлардан соң көз көне организмга аларның туклыклырак төрләре кирәк була башлый. Алар организмны витаминнар, файдалы микроэлементлар белән баета, үзенә бер җылылык бирә. Дөрес туклану кагыйдәләренә битараф булмаганнар өчен гөмбәләр белән сыйланыр чак та бит әле ул көз. Соңарып өлгерә торган яшелчәләрне файдаланып, ит, балык кушып, күптөрле салатлар ясарга, көзне төрле төсләр белән сөендерергә була көз көне. Шуларны истә тотып, «Дөрес туклану» рубрикасында һәр кешенең күңеленә хуш килерлек берничә җиңел рецепт тәкъдим итәбез.

Салат белән... җылынабыз

Салатларга һәр кеше үзе яраткан тәмләткечләрне кушып болгата ала. Күп кенә рецептларга йогырт, лимон суы, горчица кушып ясаган соус туры килә. Моның өчен 4 аш кашыгы йогырт, 1 аш кашыгы горчица, 1 чәй кашыгы лимон суын болгатырга кирәк. Блендер ярдәмендә болгатсагыз, тагын да яхшырак булыр. Әлеге соус белән түбәндәге салатларны ясый аласыз:

- 1 банка консервланган кызыл фасоль;
- 1 банка консервланган кукуруз;
- 300 г пешкән тавык ите;
- 2 уртача кыяр;
- 100 г угычтан уылган сыр.

Кыяр белән тавык итен ирекле рәвештә турап, барлык ингредиентларны бергә соус белән болгатыгыз.

- 100 г «Айсберг» салаты;
- 100 г тавык ите;
- черри помидоры.

«Айсберг» салаты яфракларын өзгәләп, тавык итен эре итеп турап, черри помидорын урталай кисеп, соус белән болгатыгыз. Соус урынына зәйтүн мае куллансагыз да була.

- 1 консервланган тунец яки горбуша балыгы;
- 1 банка яшел борчак;
- ярты данә башлы суган;
- 1 йомырка;
- тәменчә тоз, борыч.

Консервланган балыкны чәнечке белән ваклагыз, суганны ярымбоҗралап нәзек итеп турагыз, йомырканы шулай ук шакмаклап турарга кирәк. Яшел борчак, тәменчә тоз, борыч өстәп, салатны соус белән болгатыгыз.

Октябрьдә гөреҗдә (грузди), ак гөмбә, әтәч гөмбәсе (лисички), нарат гөмбәсе (рыжик) үсә. Гөмбә җыярга яратучылар исемлегенә кермәсәгез дә, кибет киштәләрендә берничә төрле гөмбә табарга була. Аксымга бай булу сәбәпле, гөмбә салатта итне дә алыштырырга мөмкин.

- 1 йомырка;
- 5 черри помидоры;
- 100 г пешкән гөмбә;
- салат яфрагы.

Барлык ингредиентларны турап болгатырга кирәк. Бу гади генә салатта йомырка сарысы барлык ингредиенлар арасында бүленеп, тәмләткеч булып хезмәт итәчәк.



- 200 г пешкән тавык ите;
- 70 г салат яфрагы;
- 300 г шампиньон;
- 300 г помидор;
- 100 г «Моцарелла» сыры;
- 1 лимон;
- 2 аш кашыгы зәйтүн мае;
- тәменчә тоз.

Барлык ингредиентларны шакмаклап турап, гөмбәне табада бераз кыздырып, салатны зур яссы тәлинкәгә җыегыз. Астына ваклаган салат яфраклары салыгыз, аннары ирекле рәвештә помидор, сыр, тавык итен кушып, зәйтүн мае сибегез.

Фото: www.pixabay.com

бизмән хатын-кыз

Бизмән йолдызлыгы астында туган хатын-кызларны билгеләүче төп сыйфат – икеләнү. Теге яки бу фикергә килер өчен аларга еш кына кемнеңдер ярдәме кирәк була хәтта. Ләкин шул ук вакытта аналитик фикер йөртү, тирән мантыйк хас бизмәнгә. Башкалар фикеренә колак сала беләләр, матурлык яраталар. Бизмән ирләргә карата һәрвакыт югары таләпләр куя. Иҗат кешеләре белән җиңел аралаша. Гаилә тормышын һәм карьерасын берьюлы уңышлы алып барырга тырыша һәм күп вакытта моңа ирешә дә.

Мөнәсәбәтләр. Бизмәнгә тыныч, акыллы, тормыш зирәклегенә ия булган ир-ат туры килә. Үзеннән бераз олырак булса, тагын да яхшырак. Бизмән гашыйк булса, үзенең хисләрен яшереп тормаячак. Тикшерер өчен, сынап карарга да мөмкин. Әгәр дә ир кеше бу сынауны үтсә, ышанычлы, яратучан, бар яклап игътибар күрсәтүче тормыш иптәше табар үзенә.

Мәхәббәт. Бу өлкәдә Бизмән һәрвакыт үзен сокландыргыч хатын-кыз буларак күрсәтер, иратка ярарга тырышыр. Җавап итеп, үзенең таләпләренә игътибар сорар. Бизмәнгә үз сүзендә тора белүче, сабыр, үзе кебек аралашучан ир кирәк. Алар яшьтән үк таләпчән була, шуңа күрә бер тапкыр сайлаган яры гомерлек булачак.

Гаилә. Бизмән идеаль гаилә төзүгә омтыла. Аның өчен ире – һәрвакыт беренче урында. Хәтта балалар да икенче планга күчеп торырга мөмкин. Ире өчен чын бизәк, ышанычлы, тугры тормыш иптәше ул. Бизмән тәртип ярата, гармониягә, матурлыкка омтыла. Аның өендә һәрвакыт ял итәрлек мохит була. Балаларына карата катгый да, назлы да ул.

йолдызнамә ноябрь

Кучкар. Тормышыгызда яңа дулкын башлана. Бәлки, узган вакыйгаларны искә алып, ностальгиягә биреләсегез килеп китәр, ләкин моның белән мавыгырга кирәкми. Кайбер эшләрегез сез уйлаганча бармаса да, азагы барыбер сезнең файдага булыр.

Үгезбозау. Аралашу, мәхәббәт, шәхси тормыш беренче планга чыгар. Нәрсә теләгәнегезне ачыкламыйча бер эшкә дә тотынмагыз. Элек хыялланырга да курыккан максатларыгызга ирешергә мөмкинлек туар. Үзегезгә игътибар күрсәтегез, прическагызны, имиджны алыштырыр өчен кулай вакыт.

Игезәкләр. Үзегезне иң яхшы яктан күрсәтергә әзер булыгыз. Вазгыятьне үз ягыгызга борыр өчен үткер сүзлелек сәләтегезне эшкә җигәргә туры килер. Ташып торган энергиягезгә үзегез дә гаҗәпләнерсез. Шуңа күрә теләсә кайсы эшне җитез башкарып, ял итәргә дә вакытыгыз күп калыр.

Кысла. Кыюлык, тәвәккәллек, лидерлык сыйфатларын күрсәтә алсагыз, һәр эшегез дә шома гына барыр. Иң мөһиме – кирәкмәгән артык әйберләр хакында уйлап, фикерләрегезне бутамагыз. Шул вакытта уңыш сезнең якта булыр. Үз хаталарыгызны кабул итә белегез.

Арыслан. Илһам чыганагын һәм тормыш энергиясен гаиләдә табарсыз. Якыннарыгызга бәйрәм ясау, күңелләрен күрү теләге туар. Һәм ул сезгә төрле күңелсез хәлләрне җиңеп чыгарга ярдәм итәр. Китап укып, яраткан фильмнарны карап кич уздыру файдага булыр.

Сөмбелә. Сезнең өчен уңай мөмкинлекләр туачак, игътибарлы булсагыз, аларны кулдан ычкындырмассыз. Ничек кенә булмасын, теләсә нинди ситуациядә тәвәккәл һәм кыю эш итегез, чөнки үз шикләрегез үк алга барырга комачауларга мөмкин.

Бизмән. Вөҗданыгыз белән уртак фикергә килергә кирәк булыр. Чөнки үз принципларыгызны гына кайгырткан вакытта башкалар фикеренә колак саласыгыз килмәс. Ноябрьдә эшләгән эшләрегез буенча үзегез өчен нәтиҗә ясарга тырышыгыз.

Чаян. Тискәре эмоцияләргә бирелүчәнлек күзәтелер. Ләззәтләнеп вакыт уздыру турында кайгыртыгыз, үзегезне вакыт-вакыт «селкетеп» алыгыз. Айның беренче яртысындагы вак мәшәкатьләргә чумып, югалып калырсыз, бәлки. Җыелган эмоцияләрне якыннарыгызга чыгармас өчен, үзегезгә ял оештырыгыз.

Укчы. Эшегез күп, ә аларны хәл итәр өчен вакыт бик аз. Ләкин якыннарыгызның ярдәме барлык мәшәкатьләрне дә җиңеп чыгарга булышыр. Акча белән бәйле проектларга аеруча игътибар бирегез. Аларны башлау уңыш китерер.


Кәҗәмөгез. Үзегезне корбан итеп, бөтен кешегә юл куеп, керем китерә торган мөмкинлекләрдән колак кагуыгыз бар. Иң беренче чиратта үзегезне кайгыртыгыз. Бөтен кешегә дә ярап бетеп булмый, шуны истә тотыгыз. Яңа танышкан кешеләргә ачылып китмәгез, эчке дөньягызны саклагыз.

Сукояр. Тормышыгызны тиз арада төрләндермәсәгез, депрессиягә кереп китүегез дә бар. Гадәти тәртип-кагыйдәләрне үзгәртегез, яңалык кертегез. Төптән үзгәртү кирәкми, бераз төзәтмәләр кертү дә җитеп торыр. Тормыштан гел зарланучы дусларыгыз белән аралашуны чикләп торыгыз.

Балык. Ноябрь тәэсирләр, күңелле очрашулар һәм кичкенә шатлыклар ае булырга охшап тора. Мондый шартларда теләсә кайсы проблеманы бик тиз һәм җиңел хәл итеп була. Нәрсә дә булса эшләр алдыннан беренчел мәгълүмат туплагыз, үзегез һәм башкалар өчен тискәре нәтиҗәләрен дә истән чыгармагыз.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Алсу ШАКИРОВА, Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, әзерләде.










Әҗәүһәрләр

Даһи рәссам Николай Фешинның тууына быел – 140 ел. Бик кечкенә чагында менингит башланып, ике атна буе комада ятучы баланы ничек исән калдырырга белмәгән ата-ана чиркәүдән көчле икона китертә – малай терелә. Рәсем ясый башлый. 1895 елда Казан сәнгать мәктәбенә укырга керә, аннары белемне Санкт-Петербургның Сәнгать академиясенә караган Югары сынлы сәнгать училищесында туплый. Иван Репин укыткан остаханәдә дә сыный үзен. 1910 елда уңышлы дипломы өчен лаек булган стипендиясен Вена, Берлин, Мюнхен, Верона, Венеция, Милан, Падуя, Флоренция, Рим, Неаполь, Парижны күрүгә сарыф итә. 1909–1922 елларда Казан сәнгать мәктәбендәге укыту дәрәҗәсен бик югарыга күтәрә. Портретлар иҗат итә. Әсәрләрен чит илләргә сата. 1913 елны Александра Бельковичка өйләнә. Рәссамның 1912 елны хәләл җефетен язган «Александра Иделдә» портреты – остаының иң күркәм хезмәтләренең берсе! 1914 елны кызлары Ия туа. Рәссам бу чорда бер эскизын Россиянең Кызыл Хач оешмасына бүләк итеп, авыру, яралы сугышчыларга булыша. 1916 елны ук инде ул Император сынлы сәнгать академиясе академигы! Ләкин 1917 ел инкыйлабы иҗатчыны уйга калдыра… 1923 елның 1 августында Фешин гаиләсе белән Нью-Йоркка килеп җитә. Grand Central Galleries каршындагы Сәнгать академиясендә укыта, рәссамнар өчен осталык дәресләре бирә, портретлардагы экспрессия, үтә дә төгәллек һәм абстракцион фоннар берлеге күп сәнгать сөючеләрдә чиксез соклану хисе тудыра. «Гравер У. Дж. Уотт портреты» (1924) өчен аңа Томас Р. Проктор призы тапшырыла. 1925 елдан башлап АКШ арт-дилерлары мистер Фешинның һәрбер портретын сатып алырга әзер. Хатыны һәм кызы сурәтләнгән «Җәй» әсәре Филадельфиядә узган Халыкара күргәзмәнең зур көмеш медаленә лаек. Әмма 1925 елны рәссам туберкулез белән чирли башлый, һәм гаилә 1927 елны Таоска күченә. Бирелә ул студиясе дә булган үзенчәлекле йорт төзи. Гади индеецларны, мексиканнарны яратып сурәтли. 1931 елдан – Н. И. Фешин, ниһаять, АКШ гражданины. Әмма 1933 елда хатыны аның белән аерылыша. Александра язучы булып танылырга тели. Рәссам исә 19 яшьлек кызы Ия белән Нью-Йоркка китеп бара, әмма биредә картиналары тиз генә сатылмый. Нью-Йорктагы Н. Фешин – депрессиядә. Лос-Анджелеска күчкәч кенә, галерист Эрл Л. Стендальнең сынлы сәнгать классында укыта башлый. Аны бик тыйнак һәм шул ук вакытта борынгы һәм замана осталарының иң яхшы сыйфатларын үзендә туплаган дөнья сәнгате лидеры дип табалар. 1936, 1938 елларда рәссам Мексика, Бали, Ява, Японияне күрә. Гомере буе Александраны, Ияне сурәтли. Ия кияүгә чыккач, Санта-Моникага күчә. Шәхси дәресләр биреп, бөлгенлектә яши. Иҗаты АКШның бар энциклопедияләренә кертелсә дә, даһи рәссам һәрвакыттагыча тыйнак. Аның күмер белән ясалган рәсемнәреннән торган беренче альбомы нибары 1946 елда гына Калифорниядә басылып чыга. Бүгенге көндә Фешинның АКШ әсәрләре шәхси тупланмаларда, 30 дан артык музейда саклана. Рәссам, яза башлаган пейзажын тәмамлый алмыйча, 1955 елның 5 октябрендә вафат була. Н. Фешин әсәрләре – дөньяның иң мәшһүр аукционнарында гаять кыйммәт йөрүче әсәрләр. Картиналары Казан һәм башка шәһәрләрнең музей тупланмаларында да бар. Балерина, соңрак психиатр (арт-терапевт) булып киткән Ия Фешина-Брэнем 1976 елны әтисе җәсәден Ватанга алып кайтып, Казанның Арча зиратында җирли. 1983 елны Таостагы йортны төзекләндереп, шәхси музей ача, йорт-музейны АКШның Милли тарихи һәйкәлләре исемлегенә дә кертә. Ия Фешинаның җәсәде 2011 елны әтисе кабере янәшәсендә үк җирләнә. Рәссам гомере буе үз Ватанын, Казанны җирсеп яши. «Кешеләр үз илләреннән китәргә тиеш түгел», – ди ул. Тик шулай да планетадагы иң сәләтле рәссамнарның берсе булу дәрәҗәсенәирешү – иң яхшы язмыш.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА










НИКОЛАЙ ФЕШИН





Тәртип


Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!



tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar







Реклама 6+